ЯҢАШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№1 (372)
ГЫЙНВАР 2023

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ЧЫҢЛАСЫН ГАРМУН, ТЫНМАСЫН ГАРМУН!

2023 ЕЛ – МИЛЛИ МӘДӘНИЯТЛӘР ҺӘМ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР ЕЛЫ

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

РЕДАКЦИЯДӘН

БӘЙЛЕЛЕКТӘН ЧЫГАРГА ВАКЫТ

Бүген халык комментарийлар дөньясында яши, шунда аралаша. Социаль челтәрләрдә һәм мессенджерларда. Диванда кырын ятып, машинада барган килеш. Безнең белән эшкә килүче-китүче аз сүзле, төксерәк гражданнар үз телефоннарында бөтенләй башка тормыш алып бара. Аларча уйламаган кешеләргә һөҗүм итә, еш кына мыскыллау һәм яла ягуларга күчеп, бер-берсенә хәтта үлем һәм тәмуг газаплары белән яный. Кеше популяр блогерларның постларына ябышып, аларга бәйлелеккә эләгеп, тормышын андагы ызгыш-талашлардан башка күз алдына китерә алмый башлый. Ә ниндидер сәбәпләр аркасында телефонсыз яисә элемтәсез калганда исә чын-чынлап хафага төшә. Телефонын бертуктаусыз әйләндергәләп, бу тынгысыз виртуаль дөньяда тагын нәрсә эшләп булганын аңлый алмыйча газаплана.

«Татарстан» әлеге санын әзерләгәндә берниндә дә агрессия тудырмый, бары тик чын кызыксыну хисләре генә уята торган темалар табарга, материаллар язарга тырышты. Журналны укыганда имән бармагыгыз да ял итәр, чөнки аңа кемнеңдер ямьсез сүзләренә тиз арада җавап бирү өчен телефон экранына төрткәләргә туры килмәячәк.

Уңайлырак итеп утырыгыз.

Телефоныгызны читкәрәк куегыз.

Безнең журналны ачыгыз.

Һәм без ышандырып әйтә алабыз: сезгә беркем белән дә мөнәсәбәтләрне ачыкларга, әдәпсез сүзләр әйтешергә, хурланырга һәм газапланырга туры килмәячәк. Һәрхәлдә басмабызның соңгы битен япканчы!

Бәйлелектән чыгарга вакыт.

Рәхәтләнеп укыгыз!

Сезгә һәрвакыт игелек кенә теләүче редакциягез

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина, vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров, sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре: Олеся Бондаревская, Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Троицкая
Авторлар: Илдус Заһидуллин, Луиза Шарова
Фотографлар: Анна Арахамия, Александр Ефремов, Юлия Кузнецова, Алсу Шакирова
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Игорь Глушков, Анастасия Хатыйпова
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта Александр Ефремов фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: С–0075
Басарга кул куелды: 19.01.2023
Басмадан чыкты: 25.01.2023

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900
Коммерция директоры урынбасары:
Гөлназ Яруллина,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9655-826-037
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева, milyaushanb@tatmedia.com

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе: **1026 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 102 ЯШЬ

ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре

бары ТИК ТАТАРСТАНДА

РЕКОРДЛЫ САЛКЫННАР

Минус 52 градус. 1979 елның 1 гыйнварында Әгерҗе халкына шундый суыкка түзәргә туры килә. Хәтта 1942 елның гыйнварында Казанда кошлар өшеп беткәндә дә Татарстанда андый салкыннар булмый: минус 47. Шуңа күрә быелның 10 гыйнварында республиканың көнчыгыш районнарында булган минус 42 градусны җиңелчә суык дияргә була. Шулай да төгәллек өчен өстәп куйыйк: Казанда беренче метеостанция 1733 елда гына ачыла. Моңа Витус Берингның икенче Камчатка экспедициясе этәргеч була. Экспедициядә катнашучылар Казанга килә һәм, һава торышы турында мәгълүмат җыюны оештыру өчен иң яхшы урын биредә, дип билгели. Асылда бу, Санкт-Петербургтан кала, империянең икенче метеостанциясе була. Ә бүген ТР буенча гидрометеорология идарәсе структурасында гына да һава торышы турында мәгълүматны онлайн режимда таптырып тора торган 20 дән артык метеостанция бар.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

4. Гасырлар аша иңгән иман нуры
Мәскәүдә Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышланган елны ничек озаттылар

8. Туган батыр – ул син
Ничек милли легенданың бер өлеше булырга

10. Узганнар календаре
Вакыйгаларны ничек чагыштырырга һәм аларның үсешен күзәтергә

12. Очкычлы гыйнвар
1987 елда ТАССР авиация тармагы буенча нинди йөкләмәләр алган

14. Спорт феврале
Совет Татариясе спортчылары ничек бөтенсоюз дәрәҗәсенә күтәрелгән

16. Яшьләрчә март
2022 елда Казан ничек Ислам хезмәттәшлеге оешмасының яшьләр башкаласына әверелде

18. Энергия саклаучан апрель
ГОЭЛРО-1920 планы ничек ТЭФ-2022 форумына кадәр үстерелде

20. Ислам рухындагы май
Ни өчен Татарстанда ислам һәм православиенең тарихи мирасы бер үк вакытта торгызыла

22. Геймерлар июне
Киберспорт-2024 белән ребус-1925 арасында нинди уртаклык бар

24. Транспортлы июль
Ничә елдан соң трактор пилотсыз транспортка әверелде

26. Цифрлы август
Узганнар һәм киләчәк арасындагы сәяхәт

28. Шигъри сентябрь
Гадел Кутуй 1941 елда Лермонтов поэзиясе турында нинди фикер калдырган

30. Юллар сузган октябрь
Күркәм традицияләрне дәвам итеп…

32. Алдынгы рухлы ноябрь
Стахановчылар хәрәкәтен ничек ныгытырга

34. Мәдәни декабрь
Ни өчен үзгәрә барган дөньяда мәдәни кыйммәтләр үзгәрешсез кала

игелекле эшләр

46. Зарланмыйча эшләгән буын
Татарстанның төзелеш отрядлары Әстерханда күпме помидор җыйган

58. Агач остасы
Өй салуның ние бар…

62. Гаилә кыйммәтләре
Ни өчен игезәкләр бер-берсен сүзсез аңлый

мәңгелек кыйммәтләр

66. Тарих сәхифәләре
Милләт язучысы Гаяз Исхакый

70. СССРның чыршы уенчыклары дөньясы
Чук һәм Гек исемнәре нәрсәне аңлата

76. Китап киштәсендә
Яңа елда нинди китаплар укырга була

80. Татар авыллары
Балтач авылында нинди музей ачылды

Фото: tatar-inform.ru

Акыллы гамәлләр

31.12

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты, – татарстанлыларга Яңа ел мөрәҗәгатендә:

– 2023 ел Татарстанда Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы дип игълан ителде. Иманым камил, үткәреләчәк чаралар, һичшиксез, телләрне, мәдәният һәм традицияләрне саклау һәм үстерүгә, халыклар арасында дуслыкны, төрле диннәр, шулай ук гражданнар арасында татулыкны ныгытуга булышачак. Әлеге кыйммәтләр һәрвакыт игътибар үзәгендә булды, алар безнең бәһаләп бетергесез казанышыбыз санала.

Игелекле эшләр

21.12

Илсур Метшин, Казан мэры:

– Мобилизацияләнүчеләрнең гаиләләренә ярдәм итү штабы эшли башлагач, безнең чыгымнар артты, бюджеттан шактый акча бүленде. Әмма кыска гына вакыт эчендә без әле хәйриячеләрдән дә зур сумма җыя алдык. Битараф булмаган һәркемгә рәхмәт әйтәсем килә. Сүз сум-тиеннәр турында гына түгел, бәлки ярдәмчел һәм мәрхәмәтле кешеләр хакында да бара.

Мәңгелек кыйммәтләр

5.12

Лазар Элунду-Ассомо, ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы үзәге директоры, – Татарстанда Бөтендөнья мәдәни һәм табигый мирасны саклау турындагы конвенциянең 50 еллыгына багышлап үткәрелгән Халыкара форумда катнашучыларга видеомөрәҗәгатендә:

– Климатның үзгәрүе, мирасны саклау, цифрлы трансформация, тотрыклы туризм, COVID-19 белән авырганнан соң тернәкләнү – киләчәктә бөтен җирдә тикшереләчәк өстенлекле өлкәләр. Әлеге юнәлешләрдә барыбыз бергә тырышкан очракта якындагы илле ел эчендә югары нәтиҗәләр бирерлек ресурсларны булдыру һәм инновацияләрне тизләтү мөмкинлегебез бар.

Фото: ТР Президентының матбугат үзәге, tatar-inform, artguide.com

игелекле эшләр
акыллы гамәлләр /
мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Ничек милли легенданың бер өлеше булырга

Вакыйгаларны **ничек** чагыштырырга һәм аларның үсешен күзәтергә

1987 елда ТАССР авиация тармагы буенча **нинди** йөкләмәләр алган

Совет Татариясе спортчылары **ничек** бөтенсоюз дәрәҗәсенә күтәрелгән

Ни өчен Татарстанда ислам һәм православиенең тарихи мирасын бер үк вакытта торгызалар

Ничә елдан соң трактор пилотсыз транспортка әверелде



Фото: Салават Камалетдинов/tatar-inform.ru

922
2022

Идел буе
Болгар дәүләтендә
Ислам динен
кабул итүнең
1100 еллыгы

Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын Мәскәүдә бәйрәм итү йомгаклары

ГАСЫРЛАР АША

Идел буе Болгар дәүләтендә ислам

МАРАТ ХӨСНУЛЛИН, РФ ВИЦЕ-ПРЕМЬЕРЫ:
«Ил Президенты Владимир Владимирович Путин боерыгы буенча бу чараларны бәйрәм итү федераль дәрәҗәдә үткәрелде. Бу дәүләт башлыгының төрле дин вәкилләре арасында дуслык, үзара аңлашып һәм хөрмәтләшеп яшәү кебек күркәм традицияләрне ныгытуга аерым игътибарын раслый».

«Россия – Ислам дөньясы: KazanSummit» Халыкара икътисадый саммиты.
Уртак куллану икътисады һәм «хәләлнең гомуми файдасы» төп темага әйләнде.

Дөньяның **55** иленнән
һәм Россиянең **42** төбәгеннән
1600 катнашучы

«Изге Болгар җыены».
Исламны кабул итүнең 1100 еллыгына багышланган тантанага **Россиядән һәм 70 чит илдән дистәләрчә мең мөселман** җыелды. Бәйрәм чаралары 21 майда «Бөек Болгар» музей-тыюлыгы территориясендә узды.

Болгарлар тарафыннан исламны кабул итүнең 1100 еллыгына багышланган **почта маркасын** рәсмиләштерү тантанасы оештырылды.

РФнең **76** субъектыннан
һәм **7** чит илдән
1100 имам

Болгарга **дин эшлеклеләре форумына** җыелды.

Татарстан башкаласында «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеменең утырышы узды. Төп тема: «Этномәдәни төрлелек, милләтара, динара татулык буенча Россия тәҗрибәсе – гомумгражданлык тәңгәллеген ныгытуның нигезе».

Казанда, «Кырлай» паркының элеккеге территориясендә,
Җәмигъ мәчете нигезенең беренче ташы салынды.

Фото: president.tatarstan.ru, tatar-inform.ru

ИҢГӘН ИМАН НУРЫ

динен кабул итүнең 1100 еллыгы вакыйгаларда

«Ибне Фазлан» документаль-нәфис фильмының премьерасы. Съемкалар Казанда гына түгел, шулай ук Мәскәүдә, Санкт-Петербургта, Төмәндә, Әстерхан өлкәсендә, Үзбәкстанның Бохара һәм Хива шәһәрләрендә узды.

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ, ТАТАРСТАН ПРЕЗИДЕНТЫ:
«Безнең ил тарихында традицион рәвештә ислам динен тотучы халыклар вәкилләренең батырлыгы үрнәкләре күп. Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын бәйрәм итү безнең күпмилләтле илебез тарихында тагын бер якты сәхифә булыр, дип ышанам. Ислам дөньясында Россиянең абруен ныгытырга, җәмгыятьтә милләтара һәм динара тынычлыкны һәм татулыкны сакларга ярдәм итәчәк».

ТР Мөселманнарының Диния нәзарәте башлыгы мөселман дөньясында фәнни-дини яктан танылган беренче басма Коръән – **«Казан басмасы»ның яңартылган вариантын** тәкъдим итте.

Россия ислам институты галимнәре **күренекле татар дин эшлеклесе Шиһабетдин Мәрҗанинең** хезмәтләрен рус теленә тәрҗемә итте.

Татарстанда
14
яңа мәчет ачылды.

Мәскәүдә **XVIII халыкара мөселман форумы** узды,
анда **40** тан артык ил вәкиле катнашты.

Юбилей вакыйгаларына багышланган

федераль дәрәҗәдәге **71** чара

республика дәрәҗәсендәге **79** чара

оештырылды.
Географиясе – Калининградтан Сахалинга кадәр.

Союзлар йортының Колонналы залында декабрь аенда **Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышланган йомгаклау тантаналары** узды. Анда РФ Хөкүмәте рәисе урынбасары Марат Хөснуллин, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Россиянең төрле төбәкләре дәүләт хакимияте органнары вәкилләре катнашты.

МИЛЛИ ЛЕГЕНДА ТУДЫРУДА КАТНАШ!

«Туган Батыр» проекты авторлары 16 яшькә кадәрге малай һәм кызларга шундый мөмкинлек бирә. Аларның фотоларын эшкәртеп, нейрочелтәр Туган Батыр һәм аның сөйгәне Гөлчәчәк мажаралары турында бәянның баш геройлары сурәтен булдырачак. Киләчәктә исә әлеге геройлар китап битләреннән кино һәм телевизор экраннарына, компьютер уеннарына, үзләренең виртуаль галәменә дә күчәчәк.

Милли әдәбиятта моңарчы очрамаган татар героеның бердәм образын дөньяга тудыру идеясе бервакыт эшкуар, хәйрияче, «Туган авылым» милли комплексын оештыручы Радик Абдрахмановның башына килгән. Былтыр аның әлеге креатив идеясен Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм танылган язучы Зөлфәт Хәким хуплаган. Шул иҗади хезмәттәшлек нәтиҗәсендә «Туган Батыр» проекты дөнья күргән.

ТУГАН – УЛ СИН

Проектның нигезендә Зөлфәт Хәкимнең тылсымлы илдә яшәүче Туган исемле малай мажаралары хакындагы экият-бәяны ята. Герой туган авылын төрле явыз көчләрдән – урман юлбасарлары һөҗүменнән, җен-пәриләр сихереннән, дуамал хан ачуыннан якларга омтыла. Туган һәм аның сөйгәне Гөлчәчәк барлык сынауларны лаеклы үтә, бу юлда үз-үзләрен дә, дөньяны да һаман яхшырак аңлый бара.

– Без фантастик фильм һәм комиксларның бар җиһанга танылган персонажларыннан бер дә калышмаган батыр образын тудырырга ниятләдек. Шунлыктан герой сыйфатында гап-гади бер малайны сайлап алдык.

Фотолар «Туган авылым» милли комплексы матбугат хезмәтеннән алынды. 6+

Аның идеаллары – гаделлек, әдәплелек, мәхәббәт. Барысы да бик гади кебек тоела. Әмма Туган үз-үзенә тугры калу, намуслы яшәү, төрле коткыларга бирешмәү һәм явыз ниятләргә каршы тору өчен көч-куәт һәм тәвәккәллек кирәк булуын үз тәҗрибәсендә ачыклый, – ди Радик Абдрахманов.

ЯҢА ГАЛӘМГӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ

Туган батыр турында бәян китап кына түгел ул. Бу – милли мәдәният кодлары кертеп чигелгән мәгънәләр хәзинәсе дә. Туган Батырның символы – угы өскә юнәлгән җәя. Тикшеренүче галим Михаил Худяков фаразы буенча, бу – Казан татарларының гербы. Һәм мондый чын тарихка, ислам диненә, татар халкының гореф-гадәтләре һәм көнкүрешенә бәйле детальләр китапта бик күп.

– Китаплар – нигез генә. Без мәгълүм персонажлары, милли әчтәлеге һәм мохите булган бөтен бер галәм тудырырга телибез, геройлар гел популярлаша барырга тиеш. Балалар һәм үсмерләрнең фантазиясен кузгатасы, аларны да Туган Батыр яши торган дөнья мохитенә җәлеп итәсе килә. Балалар хәзер бик креатив, шуңа күрә аларның иҗади энергиясе традицион мәдәниятебезне искиткеч баетырга сәләтле, – ди Абдрахманов.

Идел Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын бәйрәм итү тантаналарында Туган маҗараларының беренче томы рус, татар һәм инглиз телләрендә басылган һәм чит ил делегацияләренә тәкъдим ителгән инде.

ТАРИХКА КЕРӘЧӘК ПОРТРЕТ

Хәзер үк теләсә кайсы бала яңа галәмне төзүдә катнаша ала. Проект авторлары игълан иткән конкурс нәтиҗәләренә нигезләнеп Туган Батыр һәм Гөлчәчәкнең сурәтләре ясалачак.

– Идея бик гади: балалар сайтка үз фотосын урнаштыра. Аннары әлеге фотобанкны нейрочелтәр эшкәртә һәм йөзләрчә фотосурәт нигезендә бер портрет хасил итә. Кызларның фотолары буенча – Гөлчәчәк, малайларныкы буенча Туган Батыр образы ясалачак. Әлеге портретларны без китапта һәм аңа нигезләнгән барлык мультфильм, уен, «мерч», комиксларда файдаланачакбыз, – дип аңлатты Радик Абдрахманов.

ПРОЕКТТА НИЧЕК КАТНАШЫРГА:

1 «Туган Батыр» китабының **kitap.tuganbatyr.ru** сайтына кереп, баланың БЕР фотосын урнаштырырга. Фотоны БАРЫ ТИК баланың ата-анасы яки законлы вәкилләре генә кертә ала.



2 **@tuganbatur** аккаунтына язылырга.

3 Конкурс турындагы пост астында комментарий язарга (аларның саны чикләнмәгән), дустыңны билгеләргә.

Конкурста катнашучылар тарихка кереп кенә калмаячак, бүләк оту мөмкинлеге дә алачак. Фото 2022 елның 15 декабреннән 2023 елның 5 февраленә кадәр кабул ителә. Конкурс турында тулырак – kitap.tuganbatyr.ru сайтында. Конкурс шартларын үтәгән барлык катнашучылар арасында бүләк уйнату 2023 елның 5 февралендә булачак. Җиңүчене һәм приз ияләрен очраклы саннар генераторы билгеләячәк.

КОНКУРС БҮЛӘКЛӘРЕ:

Sony PlayStation 5

iPad

AirPods комплекты

Казан үзәгендәге «Туган авылым» милли комплексына

5 әр мең сумлык 7 сертификат

Бонус:

Һәр катнашучы «Туган Батыр» китабының икенче өлешенең электрон версиясенә һәм оригиналь стикерпакка ия булачак.

Конкурста катнашу һәм аның бөтен нечкәлекләре белән танышу бирелә:

КАЗАН
АКТАНЫШ
ЯР ЧАЛЛЫ
АРЧА
ӘЛМӘТ
АЛАБУГА
МАМАДЫШ

ТАТАРСТАННЫҢ 2022 ЕЛДАГЫ ИГЕЛЕКЛЕ ГАМӘЛЛӘРЕ

КАЛЕНДАРЕ

Ел саен төгәлләнгән елга йомгак ясап, без бары тик яхшы нәрсәләрне – канәгатьлек китергән, яхшырак булырга ярдәм иткән, хәтердә/телефонда якты кадрлар булып калган, кәефебезне күтәргән гамәлләрне генә искә төшерергә тырышабыз. «Татарстан» үзенең 2022 елгы календарена узган елның иң истәлекле вакыйгаларын туплады. Һәм үзенең иске басмалары тупланмаларында да быел йомгак ясалган эшләрнең параллельләрен күреп гаҗәпләнде. 102 ел яшәү дәверендә басмабыз битләрендә мондый игелекле эшләр күп яктыртылган, алар турында шактый язылган икән: еллар-айлар буенча урнаштырылып, күп мәртәбәләр татарстанлыларны үзләренең күркәм эшләре, фидакарьлекләре белән горурланырга мәҗбүр иткән.

Без менә шундый «параллель» гамәлләр календарен эшләргә тырыштык – узган елның һәр вакыйгасына төрле елларда «Причал», «Татарстан большевигы», «Татарстан коммунисты» дип аталган басмабызның 1925, 1936, 1941, 1971, 1987 нче елгы саннарында яктыртылганнардан параллельләр китердек. Вакыйгаларны чагыштырырга, тормышыбызның никадәр үсеш кичерүен күзәтергә мөмкин: әйтик, ГОЭЛРО планын тормышка ашырудан алып ТЭФ-2022 Энергетика һәм энергия нәтиҗәлелеге буенча Татарстан халыкара форумына кадәр юл үтеп, безнең энергетика тармагы нинди биеклекләргә ирешкәнен күрергә була.

Рәхәтләнеп укыгыз һәм чагыштырыгыз!

очкычлы гыйнвар

2022

2022 елның 12 гыйнварында Казан авиация заводы («Туполев» ГАЖ филиалы) аэродромыннан беренче тапкыр Ту-160М ракета йөртүчесе – яңа стратегик бомбардировщик һавага күтәрелде. «Татарстан», 2022 ел.

Фото: uacrussia.ru

1987

ТРАНСПОРТТА ҺӘМ ЭЛЕМТӘДӘ

Фән-техника прогрессы казанышларын кертүне тизләтү, йөк ташуны планлаштыру һәм оештыруны яхшырту нигезендә транспорт средстволарын файдалануның нәтиҗәлелеген күтәрү исәбенә халык хуҗалыгының һәм халыкның йөк һәм пассажирлар ташуга булган ихтыяҗын үз вакытында, яхшы сыйфатлы итеп тулы канәгатьләндерүне тәэмин итәргә. Барлык төр транспорт белән планнан тыш кимендә 2 миллион тонна йөк, 1 миллион пассажир ташырга, заданиедән тыш халыкка 730 мең сумлык түләүле хезмәт күрсәтергә.

Тимер юл транспортында, Белоруссия тимер юлы коллективы тәҗрибәсен куллану нигезендә, йөк ташу күләменең бөтен үсешен хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү исәбенә тәэмин итәргә. Йөк поездының уртача авырлыгын 510 тоннага арттырырга.

Гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында бишьеллыкка договорлар буенча йөк ташу күләмен 6,5 миллион тоннага арттырырга. Хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү заданиесен 8 процентка, доходларның һәр сумына чыгымнар тотуны 15 процентка киметү заданиесен арттырып үтәргә. Автопаркны дизельләштерү һәм автомобильләрне газсыман ягулыкка күчерү исәбенә 8 мең тонна бензин экономияләргә. Пассажир автотранспортының сыйдырышын 10 процентка арттырырга.

Авиация транспортында планга өстәмә рәвештә 35 мең пассажир ташуны тәэмин итәргә. 70 мең гектар авыл хуҗалыгы мәйданында авиация-химия эшләре башкарырга.

Элемтә средстволарын үстерә баруны тәэмин итәргә. Халыкка күрсәтелә торган хезмәтләр күләмен 1,5 тапкыр арттырырга.

Республикада юллар төзү һәм реконструкцияләүне унберенче

«Татарстан коммунисты», 1987 ел.

2022 елның гыйнварында Казанда Ту-160М стратегик бомбардировщигы беренче тапкыр һавага күтәрелде. Самолёт төзү проектында катнашучылар бу вакыйганың ил өчен әһәмияте турында сөйләделәр.

ЯҢА БИЕКЛЕКЛӘР АВИАЦИЯСЕ

– 2022 елның 12 гыйнварында Казан авиация заводы («Туполев» ГАҖ филиалы) аэродромыннан беренче тапкыр Ту-160М ракета йөртүчесе – яңа стратегик бомбардировщик һавага күтәрелде. 600 метр биеклектәге очыш 30 минут тирәсе дәвам итте.

– Без Ту-160 җитештерүенең тулы циклын торгыздык, әмма М модификациясендә, модернизацияләнгән двигатель, самолёт, корал белән идарә итүнең, навигациянең яңартылган системаларын кулланып. Уникаль самолётлар җитештерүне торгызуда Казан авиация заводын модернизацияләү зур роль уйнады: цехлардагы җиһазлар, очу-сынау базасы яңартылды, дөньядагы иң эре электрон-нурлы эретеп ябыштыру һәм титанны вакуумда эшкәртү җайланмалары эшкә җигелде, – дип сөйләде РФ сәнәгать һәм сәүдә министры Денис Мантуров, бу вакыйганы шәрехләп.

Бер үк вакытта әлеге проект буенча безнең белән хезмәттәшлек итүче предприятиеләрнең җитештерүләре дә яңартылды. Берләштерелгән двигательләр төзү корпорациясе һәм «ОДК-Кузнецов» компаниясе реактив двигательләр җитештерүне торгыздылар һәм НК-32-02 яңартылган эшләнмәсен сериялап җитештерүне җайга салдылар.

– Ту-160 – авиация сәнәгатенең иң зур һәм югары технологияле проектларының берсе... Бүгенге вакыйганың принципиаль әһәмияте шунда: самолёт тулысынча яңадан, нульдән төзелде, – дип белдерде Берләштерелгән авиатөзелеш корпорациясе генераль директоры Юрий Слюсарь.

Яңадан ясалган беренче бомбардировщикны һавага уңышлы күтәрү шуны раслый: Казан авиация заводының замана таләпләренә җавап бирү өчен бөтен ресурслары да бар. Күпсанлы предприятиеләр өчен Ту-160ны торгызу илнең бәйсезлеген тәэмин итә торган үз эшләнмәләребезне, материалларны һәм чимелешләрне уйлап табарга этәргеч булды. Ниһаять, Ту-160М проекты – ерак авиациянең перспективалы авиация комплексын (ПАК ДА) булдыруның мөһим өлеше.

– «Туполев» өчен Ту-160ны яңадан җитештерү – зур әһәмияткә ия проект. Ул катлаулы һәм алдынгы авиация комплексларын проектлау һәм серияле җитештерүгә кертү мөмкинлекләрен яңа дәрәҗәгә күтәрүне аңлата, – дип саный «Туполев» ГАҖ идарәче директоры Вадим Королёв.

«Татарстан», 2022 ел.

1987 елның гыйнвар санында «Татарстан коммунисты» журналы ТАССР хезмәт ияләренең 12 нче бишьеллыкка социалистик йөкләмәләрен бастыра. Анда шул исәптән авиация транспорты тармагындагы бурычларга да басым ясала.

СОЦИАЛИСТИК ЙӨКЛӘМӘЛӘР

Фән-техника прогрессы казанышларын кертүне тизләтү, йөк ташуны планлаштыру һәм оештыруны яхшырту нигезендә транспорт средстволарын файдалануның нәтиҗәлелеген күтәрү исәбенә халык хуҗалыгының һәм халыкның йөк һәм пассажирлар ташуга булган ихтыяҗын үз вакытында, яхшы сыйфатлы итеп тулы канәгатьләндерүне тәэмин итәргә. Барлык төр транспорт белән планнан тыш кимендә 2 миллион тонна йөк, 1 миллион пассажир ташырга, заданиедән тыш, халыкка 730 мең сумлык түләүле хезмәт күрсәтергә.

Тимер юл транспортында, Белоруссия тимер юлы коллективы тәҗрибәсен куллану нигезендә, йөк ташу күләменең бөтен үсешен хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү исәбенә тәэмин итәргә. Йөк поездының уртача авырлыгын 510 тоннага арттырырга.

Гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында бишьеллыкка договорлар буенча йөк ташу күләмен 6,5 миллион тоннага арттырырга. Хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү заданиесен 8 процентка, доходларның һәр сумына чыгымнар тотуны 15 процентка киметү заданиесен арттырып үтәргә. Автопаркны дизельләштерү һәм автомобильләрне газсыман ягулыкка күчерү исәбенә 8 мең тонна бензин экономияләргә. Пассажир автотранспортының сыйдырышын 10 процентка арттырырга.

Авиация транспортында планга өстәмә рәвештә 35 мең пассажир ташуны тәэмин итәргә. 70 мең гектар авыл хуҗалыгы мәйданында авиация-химия эшләре башкарырга.

Элемтә средстволарын үстерә баруны тәэмин итәргә. Халыкка күрсәтелә торган хезмәтләр күләмен 1,5 тапкыр арттырырга.

Республикада юллар төзү һәм реконструкцияләүне унберенче бишьеллык белән чагыштырганда 30 процентка арттырырга, нигездә район үзәкләрен Казан шәһәренә асфальт юллар белән, колхоз һәм совхозларның үзәк усадьбаларын каты түшәмәле юллар белән тоташтырырга.

«Татарстан коммунисты», 1987 ел.

спорт феврале


2022

Данил Садриев. Protatarstan, 2022 ел.

Фото: Cameron Spencer/Getty Images

1925

«Причал», 1925 ел.

Татарстан спортчысы, трамплиннан сикерү буенча Россия җыелма командасы вәкиле Данил Садриев чыгышы 2022 елгы кышкы Олимпия уеннарында катнаш командалар ярышында чын сенсация булды. Protatarstan спортчының туган шәһәрендәге трамплиннардан сикерә-сикерә, ни рәвешле Олимпия уеннарының «көмешенә» кадәр сикерә алуы турында язды.

ОЛИМПИАДА КӨМЕШЕНӘ КАДӘР СИКЕРӘ АЛДЫ

Лениногорскидан 18 яшьлек спортчы, чаңгыда 107,5 метрга очып, Олимпиада трамплинында рекорд куйды.

– 107,5 метрлы Пекин рекорды – минем өчен максималь очыш түгел, Лениногорскида аннан да ерагракка сикергәнем бар иде, – дип белдерде Данил. – Минем шәхси рекордыма килгәндә исә, күптән түгел сборлар вакытында мин ераграк та сикердем – 111 метрга кадәр. Ә Казахстан Гран-прие ярышларында барысыннан да ераккарак очып, рекорд куйдым.

Трамплиннан сикерү белән Данил Садриев 5 яшеннән шөгыльләнә, ә үзенең беренче халыкара ярышына ул 10 яшендә бара.

Олимпия уеннары медале иясе Лениногорскида туа, анда Татарстанның трамплиннан сикерү үзәге бар. Данилның әлеге спорт төрен сайлавында абыйсы Марсның роле зур була.

– Хәтерлим әле, абыем Марс трамплиннан сикерү белән шөгыльләнә башлады, ул вакытта аңа – 7, ә миңа 5 яшь иде. Шуннан соң миңа еш кына өйдә ялгыз калырга туры килде. Өйдә үземә генә күңелсез була башлагач, аңа иярдем.

Данил үзенең беренче халыкара ярышына 10 яшендә бара. Германиядә узган балалар турнирында яшь спортчы 21 нче урынны ала, ә инде бер елдан соң, Казахстанда Гран-при ярышларында бронза медаль яулап, халыкара аренада беренче уңышына ирешә.

Олимпия җыелма командасы составына керүенә карамастан, Данил Лениногорскида үзенең беренче тренеры Николай Васильевич Герасимов белән эшләвен дәвам итә, әмма туган каласында һәм Татарстанда әлеге спорт төре белән шөгыльләнү өчен шартлар әллә ни мактанырлык түгел.

– Безнең трамплиннар чыннан да бик иске, без аларда инде биш еллап сикермибез, Лениногорскида бары җирдә генә шөгыльләнәбез. Ә сикерүләргә килгәндә, без даими рәвештә Түбән Тагил (Свердловск өлкәсе) яки Чайковскийга (Пермь крае), кайчагында Сочига сборларга йөрибез, – ди Олимпиада медале иясенең абыйсы Марс.

Садриевның Пекин Олимпиадасындагы уңышы – көмеш медаль яулавы Татарстандагы вазгыятьне үзгәртүгә этәргеч булыр, дип ышанасы килә. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Данил Садриевны дәрәҗәле медале белән котлап, трамплиннан сикерү спортына игътибар артачагына өметләнделәр.

Protatarstan, 2022 ел.

Совет власте тәүге еллардан ук физик культураны үстерүдә халык традицияләрен саклап калырга тырыша һәм һәрьяклап ярдәм күрсәтә. «Причал» журналы ТАССР спортчыларының ни рәвешле бөтенсоюз ярышларында җиңүләре турында яза.

СОВЕТ ТАТАРСТАНЫ СПОРТЧЫЛАРЫ БӨТЕНРОССИЯ МӘЙДАНЫНА ЧЫГА

Татария чаңгычылары белән генә дан тотмый! Чаңгы җәйдән әзерләнә! Безнең күркәм җиңүләрне искә төшерик!

Бу елларда Татария спортчылары Бөтенроссия мәйданына чыга. Тәүге уңышны 1922 елда Бөтенроссия футбол олимпиадасы дип аталган беренче рәсми ил беренчелегендә футболчылар яулый. Катнашучылар арасында Мәскәү, Харьков, Тверь, Калуга, шулай ук Балтыйк флоты, Идел буе, Украина хәрби округлары җыелма командалары була. Саратовтан өч уенчы белән көчәйтелгән Казан җыелма командасы Идел буе хәрби округы өчен чыгыш ясый.

1923 елның августында узган Икенче Идел буе олимпиадасы – Идел буе хәрби округы олимпиадасы Татарстан спортчылары казанышларын беренче тапкыр җитди бәяләү-сынау булды (Беренче Идел буе олимпиадасы Түбән Новгородта 1921 елның җәендә узды). Казанга 17 шәһәр – Царицын, Саратов, Екатеринбург, Чиләбе, Пенза, Оренбург, Пермь һәм башка калалардан спортчылар килгән иде. Олимпиадага Наркомздрав (хәзерге «Хезмәт резервлары») стадионы капиталь төзекләндерелде. Татария физкультурачылары, 9 спорт төрендә чыгыш ясап, җиңел атлетика, футбол ярышларында беренчелекне яулады. Баскетбол уенында Уфа командасы белән финал матчы Казан командасы файдасына 59:13 исәбе белән тәмамланды. Спортның күп төрләре буенча ярышларда беренче тапкыр хатын-кызлар да катнашты.

Өченче Идел буе олимпиадасы илнең 12 шәһәре катнашында 1924 елның августында узды. Идел буе хәрби округының беренче призын янә казанлылар алды. Ярышларда җиңел атлетлар иң зур уңышка ирешә. Ул елларда республика спортчылары Бөтенсоюз ярышларында да яхшы чыгыш ясады. 1924 елда җиңел атлетика буенча ил беренчелегендә Казаннан 11 спортчы катнашты. Мартен биеклеккә сикерүдә икенче урынны алды, Кедров – 400 метрга йөгерүдә өченче, Трубин – 200 метрга йөгерүдә дүртенче, ә Казаков ядрә ыргытуда дүртенче һәм диск атуда бишенче урынны яулады. Шулай итеп, 1924 елда Татарстан җиңел атлетлары Бөтенсоюз ярышларында да призёрлар булды...

«Причал», 1925 ел.

яшьләр марты

Ислам хезмәттәшлеге оешмасы илләре яшьләренең халыкара саммиты. Protatarstan, 2022 ел.



КОЛХОЗЛАРДА КОМСОМОЛ КӨЧЛӘРЕН ДӨРЕС УРНАШТЫРЫРГА

К. ХӘЙРУЛЛИН

ВЛКСМ Өлкә Комитетының крестьян яшьләре бүлеге мөдире

Сталинчыл өченче бишьеллык план буенча авыл хуҗалыгы алдына куелган бурычларны үтәүдә комсомол оешмаларыннан партиянең турылыклы ярдәмчесе булу таләп ителә. Бу таләпне комсомол, әлбәттә, начар үтәми. Моның шулай икәнлеген Татарстанда комсомолецлардан 23.522 кешенең турыдан-туры колхоз производствосында эшләве ачык күрсәтә.

ВКП(б) ның XVIII нче съездында ясаган докладында иптәш Жданов комсомолда яшьләрне политик тәрбияләүне производство эшенә нык бәйләп алып барырга кирәклекне күрсәтте. Бу күрсәтмәне дөрес итеп тормышка ашырган урыннарда комсомолецлар артель хуҗалыгының хәлиткеч тармакларында эшлиләр һәм хезмәткә социалистик караш үрнәкләре күрсәтәләр. Мәсәлән, Теләче районының „1 нче Май“ колхозында партиянең башлангыч оешмасы юк, партия һәм хөкүмәт директиваларын дөрес итеп тормышка ашыру бурычы монда комсомол оешмасына йөкләнә. Политик-хуҗалык кампанияләрен үткәрүдә комсомолецлар башлап йөриләр. Комсомол җыелышларында системалы рәвештә колхоз председателенең һәм бригадирларның информацияләре тыңланып, практик эшкә дөрес юнәлеш бирелә. Комсомолецлар, колхоз алдында тора торган конкрет бурычларны хәлитүгә бәйләп, политик агитация эшләре алып баралар. Бу оешмада 20 комсомолец бар, аларның 16 сы кырчылык бригадаларында һәм фермаларда, икесе ат караучы, икесе ферма мөдире булып эшли. Аларның күпчелеге стахановчылар һәм колхозчылар арасында авторитет белән файдаланалар. Ат караучы комсомолец Шакир Хәкимов тәрбияли торган атлар көр һәм чиста. Ул 1940 нчы елда 747 хезмәт көне эшләгән һәм берничә тапкыр бүләкләнгән.

Комсомол оешмасының колхоз правлениесенә даими ярдәм итүе нәтиҗәсендә „1 нче Май“ артеле политик-хуҗалык кампанияләрен уңышлы үти, язгы чәчүне дә районда алдынгы булып тәмамлады.

Кайбыч районының „Татарстан“ колхозындагы комсомол оешмасы да яхшы эшли. Монда 16 комсомолецның 9 ы кырчылык бригадаларына беркетелгән. Комсомолецлардан бригадирлар һәм звено җитәкчеләре бар. Чәчү машинасында эшләүче комсомолец иптәш

34

Хафизов нормасы 6,5 гектар урынына көн саен 8—9 гектар итеп үтәп килде.

Эшне тиешенчә оештырган комсомол оешмалары күп кенә. Ләкин, ВЛКСМ ның кайбер райкомнары иң яхшы комсомолецларны колхоз производствосында файдалану турында ВКП(б) Өлкә Комитетының II нче пленумы карарын канәгатьләнерлек үтәмиләр. Партия Өлкә Комитеты бюросы комсомол кадрлары белән эшләү турында ВЛКСМ Өлкә Комитеты докладын буенча шушы елның 21 нче апрелендә кабул иткән карарында болай дип күрсәтте:

„Комсомол Өлкә Комитеты авыл хуҗалыгындагы комсомол кадрларын урнаштыру мәсьәләләре белән чиктән тыш начар шөгыльләнгән. Шуның нәтиҗәсендә, колхозчы комсомолецларның күпчелеге колхоз производствосының хәлиткеч тармакларында эшләми. Терлекчелек работниклары арасында комсомолецлар 1,6 процент кына...“ Өлкә Комитеты бюросының бу күрсәтмәсе күп кенә комсомол оешмаларына кагыла. Бу кимчелекләр әле бүген дә бетерелмәгән. Мәсәлән, Тәмте районында 400 комсомолецтан 159 кеше генә турыдан-туры колхоз производствосында эшли. Юдино, Лаеш, Биектау, Югары Ослан һәм Алексеевский районнарында терлекчелек фермаларында эшләүче комсомолецлар саны 3—4 кешедән артмый.

Бондюг районында „Память Ленина“ колхозы каршындагы комсомол оешмасында (секретаре иптәш Боров) учетта торучы 13 комсомолецның күпчелеге икенче дәрәҗәдәге эшләргә беркетелгән. Язгы чәчү вакытында комсомолецлардан кырда эшләүче булмады.

Яңа чишмә районының „Горный луч“ колхозындагы оешмада колхоз производствосында 9 комсомолецтан бер генә кеше эшли.

Тымытык, Балтач, Лаеш, Олы Тархан һәм Буденный районнарында терлекчелек өлкәсендә эшләүче комсомолецлар бик аз. Ләкин комсомолның район комитетлары бу мәсьәләгә һич тә тиешенчә игътибар бирмиләр. Колхоз производствосында комсомол көчләрен дөрес урнаштырырга, комсомол оешмаларының төп көчләрен турыдан-туры колхоз производствосында даими эшләүгә юнәлдерергә кирәк. Төп участокларга даими эшкә куелган комсомолецларның квалификацияләрен күтәрүгә аеруча зур игътибар бирергә, моның өчен агрозоотехника укулары һәм стахановчылар мәктәпләре оештырырга, комсомолецларның авангардлык ролен күтәрүгә ирешергә кирәк.

Комсомол оешмалары бу бурычны ВКП(б) райкомнарының җитәкчелегеннән һәм көндәлек ярдәменнән башка үти алмыйлар, әлбәттә. Шунлыктан, ВКП(б) райкомнары һәм башлангыч партоешмалар бу эштә комсомол оешмаларына конкрет булышлык күрсәтергә тиешләр.

35

«Татарстан большевигы», 1941 ел.

2022 елның мартында Казанга «Казан – ИХО* яшьләр башкаласы 2022» статусы бирелде. Башкарма дирекциясе җитәкчесе, Яшьләр дипломатиясе академиясе рәисе Дилбәр Садыйкова Татарстанның яшь дипломатларны ничек үстерүе турында сөйләде.

ЯРТЫ ҖИҺАН БЕЗГӘ КУНАККА КИЛДЕ!

– Казан бу уникаль статуска тәүге тапкыр ия булды. Һәм ул – дөньяда әлеге оешма әгъзасы булмаган илдә** урнашкан беренче шәһәр. Бу республикабызның халыкара яшьләр хезмәттәшлеген үстерүдәге казанышларын тану күрсәткече булып тора.

ИХОның яшьләр башкаласы статусын алып, Казан халыкара саммит мәйданчыгына әйләнде. Анда без миграция, яшьләрне эш белән тәэмин итү, менталь үсеш мәсьәләләрен тикшердек. Безнең өчен үзебезгә очраган проблемаларны күтәреп чыгу һәм экспертлар белән аларны хәл итү юлларын табу мөһим.

Саммитны оештыручыларның берсе булган һәм ИХОның башка чараларында да катнашып килгән Яшьләр дипломатиясе академиясе инде сигез ел дәвамында Татарстанда яшәүче, укучы һәм эшләүче яшьләргә проектларын халыкара мәйданда гамәлгә кертергә булыша. Республикадан читкә китмичә, яшьләр халыкара аралашу, мәдәниятара диалог, үз инициативаларын үстерү тәҗрибәсен ала. Шул рәвешле Татарстан актив яшь һөнәрмәндләргә нәкъ менә бирелә аякка басу һәм үз киләчәкләрен төбәк киләчәге белән бәйләү өчен шартлар тудыра. Безнең портфолиода 90 нан артык проект бар, аларда дөньяның 80 иленнән 14 мең яшь кеше катнашкан.

Минем үз миссиям исә яшьләр өчен яңа мөмкинлекләр булдырудан да гыйбарәт. Үз урынын тапкан яшьләр өчен мин бик сөенәм. Дөньяның төрле почмакларында безнең республикабыз турында сөйлиләр икән, чит илдән килгән кунаклар Татарстанга килеп киткәннән соң, стереотиплардан арынып, социаль челтәрләрдә безнең турында уңай фикерләр яза икән, бу мине бик илһамландыра. Халыкара чараларда безнең хакта сөйлиләр, фикеребезгә колак салалар, безнең белән хезмәттәшлек итәргә телиләр. Яшьләрнең фикерләү юнәлешен дөньякүләм дәрәҗәдә үзгәртергә сәләтле булуыбызны аңлау искиткеч зур стимул бирә.

Protatarstan, 2022 ел.

* ИХО – Ислам хезмәттәшлеге оешмасы.
** Россия әлеге оешма әгъзасы түгел, әмма күзәтче ил статусына ия.

Фото: vk.com/kazanyouthcapital2022



1941 елның маенда «Татарстан большевигы» журналы битләрендә ВЛКСМ Өлкә комитетының крестьян яшьләре бүлеге мөдире К.Хәйруллин күмәк хуҗалыкларда идеология эшен ныгытуда, партия директиваларын дөрес итеп тормышка ашыруда комсомолларның роле турында сөйли.

КОЛХОЗЛАРДА КОМСОМОЛ КӨЧЛӘРЕН ДӨРЕС УРНАШТЫРЫРГА

Сталинчыл өченче бишьеллык план буенча авыл хуҗалыгы алдына куелган бурычларны үтәүдә комсомол оешмаларыннан партиянең тугрылыклы ярдәмчесе булу таләп ителә. ВКП (б) ның XVIII съездында ясаган докладында иптәш Жданов комсомолда яшьләрне политик тәрбияләүне производство эшенә нык бәйләп алып барырга кирәклекне күрсәтте. Бу күрсәтмәне дөрес итеп тормышка ашырган урыннарда комсомолецлар артель хуҗалыгының хәлиткеч тармакларында эшлиләр һәм хезмәткә социалистик караш үрнәкләре күрсәтәләр. Мәсәлән, Теләче районының «1 нче Май» колхозында партиянең башлангыч оешмасы юк, партия һәм хөкүмәт директиваларын дөрес итеп тормышка ашыру бурычы монда комсомол оешмасына йөкләнә. Политик-хуҗалык кампанияләрен үткәрүдә комсомолецлар башлап йөриләр. Бу оешмада 20 комсомолец бар. Аларның күпчелеге стахановчылар һәм колхозчылар арасында авторитет белән файдаланалар.

Кайбыч районының «Татарстан» колхозындагы комсомол оешмасы да яхшы эшли. Монда 16 комсомолецның 9 ы кырчылык бригадаларына беркетелгән. Комсомолецлардан бригадирлар һәм звено җитәкчеләре бар.

Эшне тиешенчә оештырган комсомол оешмалары күп кенә. Ләкин ВЛКСМ ның кайбер райкомнары иң яхшы комсомолецларны колхоз производствосында файдалану турында ВКП (б) Өлкә Комитетының II пленумы карарын канәгатьләнерлек үтәмиләр. Колхоз производствосында комсомол көчләрен дөрес урнаштырырга кирәк. Төп участокларга даими эшкә куелган комсомолецларның квалификацияләрен күтәрүгә аеруча зур игътибар бирергә, моның өчен агрозоотехника укулары һәм стахановчылар мәктәпләре оештырырга, комсомолецларның авангардлык ролен күтәрүгә ирешергә кирәк.

ВКП (б) райкомнары һәм башлангыч партоешмалар бу эштә комсомол оешмаларына конкрет булышлык күрсәтергә тиешләр.

«Татарстан большевигы», 1941 ел.

энергия саклаучан апрель

ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов Энергетика һәм энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге буенча Татарстан халыкара форумы-2022 (ТЭФ-2022) ачылышында.



Татарстанда энергетика көчле темплар белән үсә.
«Татарстан коммунисты», 1980 ел.

2022 елның апрелендә Казанда ТЭФ-2022 Энергетика һәм энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге буенча Татарстан халыкара форумы узды. Энергетика тармагы вәкилләре технологияләрнең тормышыбызны иминрәк, уңайлырак һәм экология ягыннан чистарак итү хакында фикер алышты.

ПРОЕКТЛАР ЯРМИНКӘСЕ: ЭЛЕКТРОМОБИЛЬЛӘРДӘН АЛЫП ТКХДАГЫ САКЧЫЛ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРГӘ КАДӘР

– Кешеләр өчен мөһим мәсьәлә – энергетика ресурсларыннан сакчыл файдалануга багышланган форумда катнашу сөендерә. Бу ТКХ хезмәтләре өчен түләүне киметү дә, йортлар төзелешендә яңа технологияләрдән файдалану да, – дип белдерде чара ачылышында РФ Президенты ярдәмчесе Игорь Левитин.

Ике дистә ел эчендә форум энергетика компанияләре һәм хакимият органнары вәкилләре, уйлап табучылар, эшкуарлар, галимнәрнең үзара нәтиҗәле фикер алмашу мәйданчыгына әйләнде. Гәрчә быел көнүзәк мәсьәләләрне сайлауга санкцияләр һәм импортны алыштыру трендлары йогынты ясаса да, форум эшенең төп темалары ышанычлы, нәтиҗәле, кулланучының тормышын җиңеләйтә торган технологияләр булды.

– Объектларыбызда үзебезнең җиһазлардан файдалану буенча планлы эшебез кысаларында без республиканы электр энергиясе белән өзеклекләрсез тәэмин итү максатында берничә проектны гамәлгә ашырдык: Казандагы 2 нче җылылык-электр үзәгендә өченче компрессор станциясен урнаштырдык, Кама аръягында Яр Чаллы җылылык-электр үзәгендә заманча электр-газ өзгечләре кую юлы аша яңадан техник кораллandыру проектын гамәлгә ашырдык, тагын күп нәрсәләр эшләдек. КОММод федераль программасы буенча Казандагы 2 нче җылылык-электр үзәгендә энергетика казанын яңарту һәм «Азино» пар казаннары бинасында өченче казанны төзү дәвам итә. Барлык эшләр дә сыйфаты ягыннан чит илнекеннән бер дә калышмый торган Россия җиһазларын кулланып башкарылды һәм башкарыла, – дип сөйләде «Татэнерго» АҖ генераль директорының стратегик үсеш буенча урынбасары Рим Галиәхмәтов.

Ә КДЭУ беренче тапкыр ScienceSlam – кыска чыгышлар сериясен оештырды. Аларда галимнәр трансформатор подстанцияләрендәге электр җиһазларын онлайн-мониторинглау, андагы изоляторларның һәм һава электр тапшыру линияләренең онлайн-диагностикасы кебек катлаулы мәсьәләләрне аңлатып бирде. Электромобильләр темасына да кагылып, электрокарны ялан кыр уртасында «кору» технологиясен тәкъдим иттеләр, шулай ук энергия һәм экологияне берләштерү ысулларына тукталдылар – мәсәлән, җылылык-электр үзәкләре сусаклагычларында сөләйман балыгы һәм башка затлы балык төрләрен үстерү хакында үз фикерләрен җиткерделәр.

Protatarstan, 2022 ел.

Фото: tatar-inform.ru

1980 ел үзенең энергетикадагы уңышлары белән мактана ала. «Татарстан коммунисты» басмасы битләрендә «Татэнерго»ның район энергетика идарәсе җитәкчесе Н.Баныкин ТАССРда ГОЭЛРО планының үтәлеше һәм электр энергиясенең 30 процентын илнең үзәк районнарына тапшыруы турында сөйли.

ЭНЕРГЕТИКА КУӘТЛӘРЕ

Советларның VIII Бөтенроссия съездында В.И.Ленин ГОЭЛРО планын партиянең икенче программасы дип атады һәм үзенең тарихи формуласын игълан итеп: «Коммунизм – Совет власте плюс бөтен илне электрлаштыру ул», – диде.

ТАССРда электр энергетикасы зур темплар белән үсә. Хәзерге вакытта аның энергосистемасы тугыз электр станциясен, җиде электр челтәре предприятиесен һәм бер җылылык челтәре предприятиесен берләштерә. Энергосистеманың куәте 5600 мең киловаттны тәшкил итә. 1979 елда республика электр станцияләрендә 30,5 миллиард киловатт-сәгать электр энергиясе җитештерелде һәм кулланучыларга 33,4 миллион гигакалория җылылык энергиясе тапшырылды.

Чагыштыру өчен: 1913 елда патша Россиясендәге барлык электр станцияләренең куәте нибары бер миллион киловатт, ә еллык җитештерү – ике миллиард киловатт-сәгатькә тәңгәл булган. Хәзер Татарстанда биш тәүлек эчендә 1940 елда ел буена эшләнгән кадәр электр энергиясе җитештерелә.

Республика энергетикасы бигрәк тә 7 нче, 8 нче һәм 9 нчы бишьеллыклар чорында көчле үсте. 1963 елда илдәге иң зур җылылык электр станцияләреннән берсе – Зәй ГРЭСы сафка басты, 9 нчы бишьеллык азагына ул үзенең проект куәтенә – 2400 мең киловатт энергия җитештерүгә иреште.

Европада иң зур Түбән Кама нефть химиясе комплексын төзү бу районда куәтле 1 нче һәм 2 нче җылылык-электр үзәкләрен салуга этәрде. Аларның беренчесе 1978 елда үзенең проект куәтенә – бер миллион киловатт энергия җитештерүгә иреште.

Хәзер тагын да куәтлерәк Түбән Кама 2 нче җылылык-электр үзәге җиһазландырыла. Узган ел азагында анда беренче җылылык җитештерү энергоблогы файдалануга тапшырылды.

КамАЗны электр һәм җылылык белән тәэмин итү өчен куәте 820 мең киловаттлы җылылык-электр үзәге төзелде.

Казандагы 2 нче һәм 3 нче җылылык-электр үзәкләрен реконструкцияләү һәм киңәйтү эшләре бара. Татарстанда гаять зур гидроэнергетика узелы – Кама аша салынган тимер юл һәм автомобиль юлы белән Түбән Кама ГЭСы төзелә, бу төбәкне Үзәк һәм Урал белән тоташтыру мөмкинлеген бирәчәк. Былтыр Түбән Кама ГЭСы сафка бастырылды, 1983 елда ул үзенең тулы проект куәтенә ирешәчәк.

1958 елда ук ТАССР Советлар Союзының Бердәм энергетика системасына керде һәм хәзер электр энергиясенең 30 процентын илнең үзәк районнарына тапшыра.

Киләсе бишьеллыкта исә республика энергетикасы тагын да югарырак темпта үсәчәк.

«Татарстан коммунисты», 1980 ел.

ислам рухындагы май

2022

Болгар. Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы. «Татарстан» журналы. 2022 ел.

1926



20 СПУТНИК ПАРТИЙНОГО АКТИВИСТА № 4—5

Гудошников.

Религиозное движение в Татарии

За последний год мы наблюдаем увеличение числа религиозных школ в пределах ТР. Значение этого факта преуменьшать нельзя. На нем надо сосредоточить внимание всей нашей партийной организации.

Какие же кадры имеет мусульманская религия в нашей республике?

Размеры движения

Общее количество мечетей по всем кантонам и г. Казани выражается в цифре 2220. Служителей религиозного культа—3999 чел.

Какое количество населения они обслуживают? По имеющимся сведениям, свыше $1^{1/2}$ миллиона человек „верующего мусульманского населения" (кто рискнет в деревне об'явить себя неверующим при имевшихся фактах регистрации верующих муллами?).

Армия мулл организована, активна, относительно культурна, имеет большую экономическтю силу, связана с нэпманами и кулачеством. Не подлежит ни малейшему сомнению, что вся их активность направлена против нас, против партии и советов. Они борются с нами за влияние на массы, захватывают позиции, укрепляют их, стараются расширить свои успехи. Факты подтверждают, что за „стихийностью тяги" к религиозному обучению лежит руководство духовенства. К концу истекшего учебного года количество официально разрешенных религиозных школ по ТР превысило 800 с 30.000 учащихся (безусловно существуют и нелегальные школы, о которых не сообщают), при чем значительная часть детей одновременно посещала и религиозные и советские школы. Некоторые перебои в работе религиозных школ общей картины не меняют. Тот „утешительный" факт, что в религиозные школы многие дети идут для приобретения грамотности должен быть отмечен, как наше бессилие обслужить всех детей школьного возраста.

Борьба внутри духовенства теряет свою остроту. Население поддерживает более консервативную часть, устраняет от работы „прогрессивных" мулл. Однако, отдельные реформы, которые расширяют базу влияния, укрепляют религию—допускаются, например: допущение

№ 4—5 СПУТНИК ПАРТИЙНОГО АКТИВИСТА 21

в мечеть женщин, курс на них—как на наиболее отсталую, консервативную часть населения и т. п. Отмечен факт в Арском кантоне, когда жена азанчея делала женщинам аборты, лечила болезни и об'ясняла их, как результат посещения общественных мест. Взят также курс на пополнение кадров вероучителей. В наказах делегатам на Всетатарский с'езд духовенства включался пункт о допущении в качестве вероучителей лиц обоего пола и не обязательно служителей культа.

Наступательная активность духовенства

Аппетиты духовенства растут и из области „чисто религиозных", „духовных" переходят в политическую. Районные мухтасибские с'езды в Челнинском, Бугульминском, Елабужском и Арском кантонах выражали в числе прочего следующие „пожелания к власти".

1. Не ограничивать вероучения только мечетью, а допускать его и в других помещениях, строить новые религиозные школы и т. п.
2. Не ограничивать состав учащихся возрастной нормой.
3. Запретить антирелигиозную пропаганду.
4. Разрешить организацию курсов по подготовке мулл (и не только в городах, но и в деревенских местностях).
5. Уравнить мулл в гражданских правах с крестьянами.
6. Устранить необходимость обращения в ЗАГС.
7. Делить наследство только по шариату.
8. При обсуждении религиозных вопросов должны быть вызываемы представители духовенства.

Часть этих же требований пред'являли женщины, участницы волконференции Буинского кантона.

Если до разрешения об открытии религиозных школ наблюдалась слабая активность татарского духовенства, а первое время после разрешения некоторое „подкрашивание" под советскую власть (теория о родстве марксизма и магометанства), то теперь перед нами факт наступательной активности духовенства, а за его спиной—национальной буржуазии. Эта активность не родилась из постановления ВЦИК от 19/V-23 г., мы наблюдаем общий рост активности как рабоче-крестьянской, так и мелко-буржуазной, антисоветской. Характерной особенностью этого наступления является попытка вовлечь в него крестьян.

В одной из волостей Арского кантона граждане составили петицию с требованием большей свободы вероучения. В Агрызе за подписью свыше 30 граждан в райком поступило заявление, в котором указывалось, что граждане добросовестно исполняют свои обязанности по отношению к совласти, а поэтому и совласть не должна вести

«Спутник партийного активиста». 1926 ел.

*«Татарстан» журналы шулай дип аталган һәм рус телендә чыккан.

2022 елның маенда Татарстан Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын бәйрәм итте. «Россия – Ислам дөньясы» Стратегик караш төркеме утырышында Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев Татарстанда ислам һәм православие диннәренең тарихи мирасын торгызу буенча барлык карарларның ни өчен бер үк вакытта кабул ителүе турында сөйләде.



БУ – КҮП КОНФЕССИЯЛЕ ИЛДӘ ДӨРЕС АДЫМ

– Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулган көн – бик мөһим бәйрәм көне, һәм әлеге вакыйганы билгеләп үтү мөмкинлеге өчен илебез җитәкчелегенә рәхмәтебезне белдерәбез. Бу – күпьеллык эш нәтиҗәсе. Без ислам дөньясы белән дуслык мөнәсәбәтләрен әкренләп җайга салдык, ә икенче яктан, 12 ел дәвамында өзлексез рәвештә археологик тикшеренүләр үткәрелде. Россия Ислам хезмәттәшлеге оешмасы белән нәтиҗәле мөнәсәбәтләр кора алды. 2006 елда «Россия – Ислам дөньясы» Стратегик караш төркемен оештыру турында карар кабул ителде, барыбыз да дуслык һәм партнёрлык нигезендә аралашу мөһим дигән фикер белән килештек. Көнбатыш цивилизацияләренең ислам проблематикасы белән бәйле төгәл ориентирлары юк. Бу исә республикабыз әлеге өлкәдә зур тәҗрибә туплаган дигән фикергә китерде. Төркем утырышлары Күвәйттә, Истанбулда, Җиддәдә һәм Казанда узды. Исламның башка диннәрне танып кына калмыйча, алар белән уңышлы хезмәттәшлек итүен ассызыклап, без башта ук динара татулык юлын сайладык. Мисалга 2010 елда төзелгән «Яңарыш» республика фондын китереп була. 2019 елда фонд ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелгән борынгы Болгар һәм Зөя шәһәрләрен торгызу эшен тәмамлады.

Ислам һәм православие диннәренең тарихи мирасын торгызу белән бәйле барлык карарлар да бер үк вакытта кабул ителә. Мондый гамәл исә тынычлык һәм тату күршелек мөнәсәбәтләре өчен нигез булып тора. Бу – күп конфессияле илдә дөрес адым.

Татарстан сәясәтенең нигезе мәдәниятләр һәм конфессияләр балансын саклау, иҗтимагый һәм милләтара тотрыклылыкны эзлекле рәвештә формалаштырудан гыйбарәт.

«Татарстан», 2022 ел.

Фото: Александр Ефремов

1926 елда «Спутник партийного активиста»* Татарстанда дини хәрәкәт һәм руханилар арасындагы көрәшнең ни өчен кискенләгән югалтуы турында язган.

ДИН ӘҺЕЛЛӘРЕНЕҢ АКТИВ ҺӨҖҮМГӘ КҮЧҮЕ

Руханиларның аппетиты үсә бара һәм, дин өлкәсеннән бигрәк, сәяси өлкәгә күчә. Чаллы, Бөгелмә, Алабуга һәм Арча кантоннарында район мөхтәсибләре съездлары «хакимияткә теләкләр» арасында шул исәптән түбәндәгеләрне дә белдерде:

1. Дини белем бирү эшен мәчет белән генә чикләмәскә, аны башка биналарда да алып баруны, яңа дини мәктәпләр һ.б.ш. төзүне рөхсәт итәргә.
2. Укучылар составын яшь белән чикләмәскә.
3. Дингә каршы пропаганданы тыярга.
4. Муллалар әзерләү курсларын оештырырга рөхсәт итәргә (һәм шәһәрләрдә генә түгел, авыл җирлекләрендә дә).
5. Муллаларны гражданлык хокуклары мәсьәләсендә крестьяннар белән тигезләргә.
6. ЗАГСларга мөрәҗәгать итү зарурияттен бетерергә.
7. Мирасны шәригать буенча гына бүләргә.
8. Дини мәсьәләләр буенча фикер алышканда, дин әһелләре чакырылырга тиеш.

Әгәр дини мәктәпләр ачарга рөхсәт бирелгәнче татар руханилары әллә ни активлык күрсәтмәсә, хәтта беренче мәлдә Совет власте белән «ярашырга омтылу» (марксизм белән мөселманлыкның туганлыгы турындагы теория) күзәтелсә, хәзер руханиларның актив һөҗүмгә күчүен күрәбез, ә дин әһелләре артында милли буржуазия тора... Бу активлык Бөтенсоюз үзәк башкарма комитетының 1923 елның 19 маендагы карары аркасында килеп чыкмады, без эшче-крестьян активлыгы кебек үк, вак буржуаз, советка каршы активлыкның да гомуми үсешен күзәтәбез. Бу һөҗүмнең үзенчәлеге аңа крестьяннарны да җәлеп итәргә омтылудан гыйбарәт.

Арча кантоны волостьларының берсендә гражданнар күбрәк дин иреге таләп ителгән петиция язган. Әгерҗедә район комитетына 30 дан артык кеше имзалаган гариза килгән, анда гражданнарның совет власте каршында үз вазифаларын намус белән үтәве әйтелгән, шуңа күрә совет власте дә, «халык белән яхшы мөнәсәбәтләрне бозмас өчен», дингә каршы пропаганда алып барырга тиеш түгел, дип күрсәтелгән. Бөгелмә кантоны Керкәле авылы хатын-кызлары җыелышында хакимияткә мөрәҗәгать кабул ителгән, анда «власть белән крестьяннар арасында аңлашылмаучанлыклар һ.б. килеп чыкмасын өчен, Аллаһ һәм Коръән турында бәхәсләргә юл куймау» турында сорала. Бу гаризага алтмыш кеше урынына берәү генә кул куюына да карамастан, ул типик мөрәҗәгать булып тора.

«Спутник партийного активиста», 1926 ел.

геймерлар июне

2022



«Киләчәк уеннары» спорт, киберспорт, виртуаль һәм тулыландырылган чынбарлык технологияләрен берләштерәчәк. Проект аудиториясе Олимпия уеннары аудиториясеннән җиде мәртәбәгә зуррак булырга мөмкин. Protatarstan, 2022 ел.

Фото: gamesofuture.com

1925

РЕБУС № 2.



«Причал»*, 1925 ел.

*1925 елда «Татарстан» журналы шулай дип аталган һәм рус телендә генә басылган.

2022 елның июнендә Татарстан башкаласы 2024 елда «Киләчәк уеннарын» үткәрү хокукын яулады. Проект авторлары спорт һәм технологияләрне берләштерүнең ни өчен нәкъ менә хәзер файдалы булуы хакында сөйли.

КИБЕРСПОРТ ТУРЫНДА

Проектның беренче тест ярышлары инде 2022 елның сентябрендә үк «Казан Экспо» территориясендә үткәрелгән иде. Фиджитал (физик уеннар + диджитал) форматы спорт, киберспорт, виртуаль һәм тулыландырылган чынбарлык технологияләрен фантастик шоуга берләштерде. Танылган офлайн һәм онлайн спортчылар дүрт дисциплинада көч сынашты: фиджитал-футбол, фиджитал-баскетбол, Beat Saber, дроннар узышы. Алай гына да түгел, футбол һәм баскетбол командалары башта виртуаль, аннары исә реаль мәйданчыкта уйнады.

– Гәрчә үзем 5 кә 5 баскетболы буенча Россия чемпионатында катнашсам да, киберспортка шикләнебрәк карый идем. Биредә фикерем тамырдан үзгәрде. Чөнки мондый оештыру дәрәҗәсе хәтта югары лигалардагы гади баскетболда да очрамый, – диде Мәскәү баскетболчысы Андрей Курченко.

– Классик спорт үсеше замана чынбарлыгы артыннан өлгерә алмый. Олимпия уеннарын телевизордан караучыларның уртача яше - 53. Ә менә киберспорт аудиториясенең 60 проценттан артыгы – 30 яшькә кадәрге яшьләр. «Киләчәк уеннары»ның спорт тирәсендәге аудиторияне җәлеп итү хисабына тамашачылары күп булыр, дип фаразлана, – дип билгеләп үтте Татарстандагы «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» АКБО генераль директоры урынбасары Ранко Тепавчевич, 2024 елда тулы форматлы «Киләчәк уеннары» үткәрү өчен сайлануның республикага нигә шулкадәр мөһим булуы хакында сөйләгәндә.

– Традицион Олимпия триадасы – тән, ихтыяр һәм гакылны инде хәзер үк тормышыбызның бер өлешенә әйләнгән дүртенче компонент – технологияләр белән тулыландыру тәкъдим ителә. Безнең илебез һәрвакыт өр-яңа технологияләрне үстерергә омтылды һәм дөнья спортын актив рәвештә алга этәрде, – дип сөйләде «Киләчәк уеннары» идеясе хакында проект авторларыннан берсе, РФ Хөкүмәте Рәисе урынбасары Дмитрий Чернышенко. – Бу хәрәкәт аудитория игътибарын җәлеп итә алыр, дип ышанам. Без аерым бер төркемнәрнең инертлыгын җиңеп чыга алырбыз, фән үсешенә булышырбыз, цифрлы казанышларны яхшыртырбыз, дип уйлыйм. Бу безнең традицион спорт төрләрендәге традицион алдынгылыгыбызга менә дигән өстәмә булачак!

Protatarstan, 2022 ел.

1925 елда басылган «Причал»* журналында спорт рубрикасын алып баручы М.Симский бүген һәм киләчәктә оештырылачак уеннар, шулай ук ребус чишү серләре, шахмат армиясен көрәшкә әзерләү һәм Мәскәүне «җиңү» хакында сөйли.

КАЗАН ӘЗЕРЛӘНӘ

Спорт сезоны әле рәсми рәвештә ачылмады, әмма кичләрен НКЗдрав стадионында инде кояшта каралып та өлгергән физкультурачылар мәш килә.

Билгеле ки, без – Мәскәү түгел. Һәм андагы 1 Май йөрешендә катнашкан егерме мең физкультурачы белән мактана алмыйбыз.

Әмма спортка җәлеп ителгән 1000нән артык яшь эшче сезон ачылышы ярышларында катнашырга җыена.

Ачылыш көне программасында җиңел атлетика да, ирекле уеннар да, спорт уеннары да бар.

Яшьләр әзерләнә...

Кичке сәгать 5 тә стадионга җан керә.

Кыска һәм ерак арага йөгерешчеләр аяк яза. Диск, ядрә яки зур чүкеч ыргытучылар көчен сыный.

Сәгать җиденче киткәч, кырда футболчылар пәйда була.

Алар да әзерләнә...

17 майда Казан җыелма командасы югары уку йортлары командасы белән очрашачак.

Аннары инде башка төбәк командалары белән матчлар башлана:

24 майда Сормово заводлары командасы белән,

31 ендә – Ульяновск яки Самара,

7 июньдә исә Мәскәү белән. Моңа кадәр казанлылар һич тә җиңә алмаган, әмма бик тә җиңәсе килгән Мәскәү белән!

М. Симский

ДЕБЮТЛАР

Шахмат уенын өйрәнгәндә дебют яки партиянең башлануы җиңүгә ирешү өчен искиткеч мөһим чара булып тора һәм еш кына партиянең ничек тәмамлануы нәкъ менә шуңа бәйле дә. Дебютның максаты – үзеңнең шахмат армияңне яуга әзерләү, фигураларны мөмкин кадәр уңышлы итеп тезеп кую.

Бары шуннан соң гына уенга, «партиянең уртасына», ягъни һөҗүм һәм саклануларга күчәргә була.

Аеруча мөһим булганга, дебютлар курсы аеруча яхшы эшләнелгән дә.

Партияне ничек башларга соң? Нинди йөреш иң яхшысы санала? Иң яхшы йөрешләрдән берсе – 1 е2-е4, ул шундук ферзьгә һәм филгә юл ача. Әлбәттә инде, бу йөреш һичшиксез отышка китерми, ул бары тик уенны җанландырып җибәрә һәм кызыклырак кына итә.

М. Симский

«Причал», 1925 ел.

транспортлы июль

«Пилотсыз» эшләү системасы җиһазлары тулысынча үзебездә җитештерелгән компонентлардан тора. Protatarstan, 2022 ел.

«Әмма әлегә бу эшләнмәгән икән, партия оешмаларына киләчәктә дә, билгеле бер кыска вакытка, бөтен вак-төяк мәшәкатьләрне дә кертеп, җир сөрү, чәчү, уңыш җыю һәм башка авыл хуҗалыгы эшләре белән шөгыльләнергә туры киләчәк».
И. Сталин



2022 елның июлендә КФУның Исәпләү математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты (ИМһМТИ) Екатеринбургта узган «Иннопром» халыкара сәнәгать күргәзмәсендә пилотсыз трактор прототибын тәкъдим итте. Проектта катнашкан Антон Егорчев механик нигездәге техниканы ничек итеп цифрлыга үзгәртүләре турында сөйләде.

ТРАКТОР ҮЗЙӨРЕШЛЕГӘ ӘЙЛӘНӘ

Ике дистә галим, программистлар, конструкторлар, шул исәптән институт студентлары һәм магистрлары, «МТЗ-Татарстан» компаниясе белән хезмәттәшлектә агрегатны берничә ай эчендә тулысынча диярлек үзгәртеп короалар.

– Тракторга электрон җиһазларны һәм сенсорика системасын көйләү өчен, без механика системасын бөтенләй үзгәртеп ясадык. Хәзер бу тулысынча автоматлаштырылган техника, моңа ясалма күрү, навигация һәм элемтә системалары, автопилот һәм читтән торып идарә итү системалары да керә, – ди ИМһМТИ директорының беренче урынбасары Антон Егорчев.

Трактор бензинда да, электрда да эшли ала: аңа аккумуляторлар көйләнгән, аларның запасы 4–5 сәгать эшләргә җитә. Трактор белән руль артына утырып та, куркыныч участокларда эшләгән вакытта кеше сәламәтлегенә зыян китерү куркынычын мөмкин кадәр киметергә сәләтле гаджетлар ярдәмендә читтән торып та идарә итәргә мөмкин.

«Пилотсыз» эшләү системасы җиһазлары тулысынча үзебездә җитештерелгән компонентлардан гыйбарәт.

– Эшебезнең асылы тракторны «А» ноктасыннан «Б» ноктасына барырга өйрәтүдән түгел, ә дөрес архитектура һәм программа белән тәэмин итүдән гыйбарәт, алар тракторга оператор тарафыннан куелган бурычларны – билгеле бер траектория буенча йөрүдән башлап иң яхшы юлны мөстәкыйль сайлап ала белүгә кадәр һәм башкаларны автоном рәвештә үтәргә мөмкинлек тудыра, – ди Антон Егорчев.

Институтның 2022–2023 елларга планында тагын да зуррак агрегат белән эшләү күздә тотыла. Мондый проектлар технологик үсеш өчен генә түгел, мәгариф өчен дә файда китерә. Студентларны реаль заказлар белән эшләргә җәлеп итү нәтиҗәсендә, 2022 елда ИМһМТИда «Махсус робот техникасында инфокоммуникацияләр» һәм «Ясалма интеллект һәм суперкомпьютер исәпләүләре» дип аталган ике яңа магистрлык программасы, берничә яңа лаборатория, компьютер класслары һәм фәнни-тикшеренү үзәкләре ачылды. Пилотсыз трактор ясау эше әнә шул үзәкләрнең берсендә алып барылды.

Protatarstan, 2022 ел.

Фото КФУның ИМһМТИ архивыннан

1941 елның май санында «Татарстан большевигы» журналында А. Харитонов һәм А. Владимиров республика оешуның 21 еллыгына багышланган күзәтү белән чыгыш ясый. Мәкаләдә ТАССРдагы социалистик тормышта ирешелгән казанышлар турында сөйләнә.

ДАНЛЫКЛЫ ЕЛЛЫК

Татарстан АССР оештырылуга 21 ел тулды. Бу еллар эчендә ТАССР, Советлар Союзының алдынгы социалистик республикасы әйләнеп, индустриаль республика булып үсте һәм СССР хөкүмәте тарафыннан Ленин ордены белән бүләкләнде. Совет власте елларында ТАССРның промышленносте өр-яңадан корылды, гаять зур завод-фабрикалар салынды. Социализмның җиңүе нигезендә илебездә эксплуататор сыйныфлар бетерелде, авылда колхоз строе тәмам җиңде.

Татарстан авылларында хәзер 15 меңнән артык кеше, катлаулы машина техникасын үзләштереп, тракторчы, комбайнчы, машинист һәм механик булдылар. ТАССР колхозларына хәзер 106 МТС хезмәт күрсәтә. Колхоз һәм совхоз кырларында 5752 трактор һәм 3054 комбайн эшли. Болар янына тагын меңнәрчә катлаулы сугу машиналары һ. б. бар.

Колхоз строен ныгыту һәм авыл хуҗалыгын катлаулы машиналар белән баету нәтиҗәсендә совет власте крестьяннарның хезмәтен җиңеләйтеп кенә калмады, бәлки иген уңышын елдан-ел күтәрә бару өчен бөтен мөмкинлекләрне тудырды. Үткән елны, һава шартларының иген уңышы өчен уңайсыз булуына карамастан, алдынгы колхозлар, стахановчылар югары уңыш алдылар.

Колхозлар җәмәгатьләштерелгән терлек үрчетү эшендә дә шактый уңышларга ирештеләр. Безнең бурыч социалистик игенчелекне һәм терлекчелекне тагын да үстерүдән гыйбарәт. Моның өчен 1941 елны югары иген уңышы алуга ирешергә, колхоз фермаларында терлекләр санын арттырырга, тракторлардан, комбайннардан һ.б. төрле авыл хуҗалыгы машиналарыннан тулысынча файдаланырга кирәк. Хәзер иң әһәмиятле бурыч игеннәрне тәрбияләп үстерүдән һәм урып-җыю эшләренә үрнәк булырлык итеп хәзерләнүдән гыйбарәт.

Авыл хуҗалыгы буенча да бик зур чаралар үткәрелә. Өченче бишьеллык план буенча Татарстанда 40 яңа МТС оештыру күздә тотыла. Боларның күбесе оештырылды инде. 1942 елга кыр эшләренең 81 проценты механикалаштырылачак.

Татарстан халкы үзенең 21 ел эчендә ирешкән җиңүләре белән бик хаклы рәвештә горурлана һәм киләчәккә шатлык һәм ышаныч белән карый. Орденлы Татарстан халкы киләчәктә Ленин – Сталин партиясе тирәсенә тагын да ныграк тупланыр. Коммунизм өчен, ватаныбызның данын, аның оборона куәтен тагын да күтәрү өчен, завод-фабрикаларыбызда һәм социалистик кырларда мул продукт җитештерү өчен, бөек Сталин җитәкчелегендә героик көрәштә алдынгылар сафында булыр.

«Татарстан большевигы», 1941 ел.

Фото: my-ussr.ru

цифрлы август

2022

Бәшир Рәмиев исемендәге IT-парк. Protatarstan, 2022 ел

1925


Татар балалар шәһәрчеге. «Причал», 1925 ел.



2022 елның августында башкала үзәгендә, элек «Спартак» фабрикасы торган урында, Казанның икенче ИТ-паркы ачылды. Аңа беренче совет электрон-исәпләү машиналарын ясаучы Бәшир Рәмиев исемен бирделәр. Парк – киләчәк турында хыялларның чынга ашуы ул: монда эш, ял һәм үсеш өчен бөтен нәрсә бар. «ИТ-парк» Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк» ДАУ директоры Руслан Власов паркның ни өчен ачылуы турында сөйләде.

ЦИФРЛЫ ПАРККА СӘЯХӘТ

– Кеше бу 50 мең кв. метрлык мини-шәһәрдән чыкмыйча да диярлек яшәргә мөмкин, дип шаярталар кайчак. Көндез син резидентлар өчен офиста эшлисең дә, төштән соң икенче катка төшеп, төрле митапларга һәм профиль чараларга йөрисең, кичен спорт залына яки киберспорт аренасына барасың, аннары беренче каттагы ресторан, гастробар яки пиццерияләргә кичке ашка юнәләсең. Берничә минутлык юл ераклыгында гына беренче ИТ-парк, «Сувар» һәм Urban бизнес үзәкләре, «Идея» технопаркы урнашкан. Без хәзерге һәм киләчәктәге цифрлы проектлар һәм аларның авторлары үссен, камилләшсен өчен, уңайлы синергетик мохит булдырырга омтылабыз.

Яңа ИТ-паркның профессиональ юнәлештәге үзенчәлекләреннән берсе – яңартылган стартап-хаб. Беренче ИТ-паркның башлангыч стадиядәге проектларны сыендырган бизнес-инкубаторыннан аермалы буларак, яңа хаб күпмедер дәрәҗәдә җитлеккән стартапларга йөз тота. Проект инде сатуга чыккан, аның расланган гипотезалары, формалашкан командасы булырга тиеш. Болар барысы да көндәшлек мохитен тудырачак.

Без үз алдыбызга колачлы максат һәм бурычлар куябыз: яңа парк резидентларының җитештергән продукциясе күләме инде 2023 елда ук 20 млрд сумнан артып китәчәк, 3 мең эш урыны булдырылачак. Вазгыятькә һәм сынауларга җайлашачакбыз, ни дисәк тә, ИТ-җәмгыятьне формалаштыру тәҗрибәбез бар.

Protatarstan, 2022 ел.

Фото: tatar-inform.ru


ПРИЧАЛ

1925 елның августында Казанда балалар шәһәрчеге барлыкка килә. «Причал» һәм А. Заволжский «Казан Онегиннары»ның йөрәкләрен яндырган урыннан ничек итеп 400 балалык «эш кайнап торган кырмыска оясы» ясарга һәм квалификацияле пролетарийлар тәрбияләргә икәнен бәян итә.

ТАТАР БАЛАЛАР ШӘҺӘРЧЕГЕ

Арча кыры артында матур яшел бакчалар җәелеп китә һәм шушы әрәмәлеккә Евгений Дебс исемендәге балалар шәһәрчеге сыенган. Кайчандыр биредә Казан Онегиннары мәхәббәтләрен юксынып йөргән, нәзакәтле, кыltык ханымнар күз сирпеп узган, бакчаның күләгәле аллеяларыннан хушбуй исләре килеп торган...

Хәзер ул – эш кайнап торган кырмыска оясы. Тәрбиячеләрнең кайгыртучан кулы астында 400 бала яңа тормыш-көнкүреш төзи. Балалар шәһәрчеге ике дистәгә якын бакча йортын биләп тора.

4 тән 8 яшькә кадәрге сабыйларның көн тәртибе план белән билгеләп куелган. Алар төп-төгәл сәгать сигездә тора һәм, иртәнге аштан соң, барысы бергә яшел мәйданчыкка тарала. Көн тәртибендә – саф һавада йөрү, уеннар, табигать белән танышу. Төшке аштан соң – эвәләү, рәсем ясау, кәгазь фигуралар кисү.

Мәктәп укучылары аерым урнаштырылган. Алар К.Маркс, Рыков һәм М.Вахитов исемендәге өч пионер отрядына һәм өч октябрят отрядына бүленгән. Аларның көне иртәнге 7 дә башлана. Сәгать 9 дан 12 гә кадәр төркемле дәресләр бара. Хезмәт тә, уку да, ял вакыты да төгәл чиратлаштырыла.

Бакчада эшләү, производство урыннарына, Идел буена экскурсияләр балалар тормышын төрлеләндерә.

Балалар үзидарәгә дә өйрәнә. Аларның оешмалары тулы бер челтәр хасил итә. Монда башкарма бюро һәм биш комиссия: мәдәни, агарту, контроль, хуҗалык һәм иптәшләр суды комиссияләре бар.

Яңа тормыш төзүчеләр революцион исемнәр йөртә: «Рим», «Ким», «Азат», «Ирек» һ.б. Балалар арасында искиткеч сәләтлеләр – җырчылар, декламаторлар һәм рәссамнар очрый. Татар балалар шәһәрчеге «руснык» белән бик якын элемтәдә тора. Балалар бер-берсен кунакка, спектакльләргә чакыра. Кыскасы, милли ызгыш-каршылыкның әсәре дә юк.

Дөрес, шәһәрчекнең хәл иту бик авыр булган ихтыяҗлары күп, әмма мәгариф халык комиссариаты аңа һәрьяклап булышлык күрсәтә. Биржа комитеты ай саен шәһәрчеккә 200 сумга якын акча җибәрә.

Шәһәрчек халкы чиста һәм сау-сәламәт. Авырулар 15 процент тан артмый. Корчаңгы авыруы – якынча 5%, трахома – 3-4%, туберкулез – 2% һәм 5% чамасы бизгәк авыруы күзәтелә.

Балалар шәһәрчеге – квалификацияле пролетарий һәм мәдәни хезмәткәрләр үстереп чыгара торган коммунизм бакчасы ул.

«Причал», 1925 ел.

шигъри сентябрь

2022



Олеся Балтусованың «Секретный чат» һәм Андрей Коровинның «Климэра» («Хәерле көн» – грекчадан тәрҗемә - ред. иск.) китапларын шигъри диалог формасында уртак презентацияләү вакытында.

1941

М. Ю. Лермонтовның үтерелүенә 100 ел тулуга карата

Рус халкының бөек шагыйре

> Хәзрәте Пушкин вә Лермонтов әгәр булса кояш,
> Ай кебек нуры алардан икътибас иткән бу баш.
>
> **Г. Тукай.**

„Безнең поэзиябезнең күгендә яңа якты йолдыз калыкты һәм, калку беләи үк, аның беренче дәрәҗәдәге зур бөек йолдызлардан икәнлеге беленде"—Лермонтов турындагы мәкаләсен Белинский әнә шулай башлый.

М. Ю. Лермонтов, 27 яшенә дә җитмәстән, 1841 нче елның июлендә һәлак булды. Аны патша реакциясе, царизм строе, Мартынов пулясы һәлак итте.

Гаять актив һәм гел алга омтылышлы характерда булган Лермонтов яшьтән үк царизмга каршы үзендә әче нәфрәт саклап үсә.

1825 нче елны декабристлар восстаниесе була. Канлы патша декабристларны җәзалау өчен мәйданга туплар китертә. Герцен бу турыда: „Сенат мәйданында туплар гөрселдәве бөтен бер буынны уятты" дип язды. Лермонтов та әнә шунда уянган яңа буынның бер вәкиле.

Ул, бала чагында ук Пушкинны яратып укый, ирек турында җырлаган бөек шагыйрьнең әсәрләрен аерым дәфтәргә күчерә, ятлый һәм үзе дә Пушкинга иярең яза башлый. Шул ук вакытта ул халык иҗатын да өйрәнә. „Әгәр дә халык поэзиясенә бирелергә теләсәм,—ди 15 яшьлек Лермонтов,—аны мин рус җырларыннан гына эзләрмен... аларда поэзия бөтен француз тел-әдәбиятында булганга караганда да күбрәк".

Лермонтовның политик карашы, политик аңы декабристлар башлап җибәргән революцион юлда, Москва студентлары даирәсендә яшерен түгәрәкләрдә үсә һәм ныгый. Мәгълүм ки, ул, Москва университетында Герцен, Белинский, Огарев кебек мәгърифәтчеләр белән бер вакытта укый. Герценның „Үткән заман һәм уйлар" дигән әсәре, Белинскийның студент чакта язган „Дмитрий Калинин" исемендәге драмасы, Лермонтовның шул чордагы шигырь-поэмалары—болар барысы да самодержавиегә һәм крепостнойлыкка каршы политик протест пафосы белән сугарылганнар. 30 нчы еллар башында Лермонтов революциянең Россиядә җиңәчәген алдан хәбәр итә һәм „Патшаларның таҗлары бәреп төшерелүгә" ышана, шул ук елларда ул француз революциясен котлап шигырь яза.

40

1837 нче елга кадәр Лермонтов, берничә әсәре басылып чыкса да, киң массага танылмый әле. Аның әдәби исеме үзенең танышларына гына һәм әдәбият сөюче кайбер укучыларга гына мәгълүм була. 1837 нче елда бөек Пушкин үтерелә. Шул заманның әдипләреннән В. А. Соллогуб „Пушкинның үлеме Россиягә яңа шагыйрьнең тууы турында хәбәр китерде" дип яза. Лермонтовның Пушкинга чиксез тирән мәхәббәт белән, Пушкинны үтерүче патша сараена, сарай ялчыларына әче нәфрәт һәм утлы нәләт белән тулган „Шагыйрьнең үлеме" дигән шигыре халык тавышы булып яңгырый. Ул елларны әле матбугатта чыкмаган бу шигырь кулдан кулга йөреп күчерелә, ун меңнәрчә данә таратыла. Шул заман әдәбиятчылары „Россиядә шигырьнең шундый көчле тәэсир ясаганын без моңарчы күргәнебез юк иде әле",—дип язалар.

Шигырь Лермонтов үтерелгәннән соң 15 ел үткәч кенә басыла. Аны 1856 нчы елны Герцен „Полярная звезда" да игълан итә.

Набатсыман яңгыраган бу шигырьнең кемгә караганын һәм нәрсәгә чакырганын сарайда бик тиз аңлыйлар. Кулъязма Николай I патшага да килеп җитә һәм патша бу шигырьне „Революциягә өндәү" дип карый. Әле генә бер шагыйрьне үтереп, халыкта нәфрәт тудырган царизм Лермонтовны да үтерергә курка. Ул аны Кавказга сөргенгә җибәрә.

„Миңа хәрәкәт итәргә кирәк, мин һәрбер көнне бөек герой күләгәседәй үлемсез итәргә теләр идем... Миңа тормыш ничектер һаман кыска булып тоела һәм мин нәрсәнедер эшләргә өлгермәм дип куркам"—ди Лермонтов. Һәм ул хәрәкәт итә, бер-берсеннән матур әсәрләр бирә.

Шагыйрьнең бай әбисе Лермонтовны башкалага кайтару өчен бөтен көчен куеп тырышып йөри башлый. Патша хөкүмәте Лермонтовны „акылга утыргандыр" дип өметләнә һәм кайтырга рөхсәт итә. Ләкин озакламый, укучылар „Безнең заман герое" романының журналда басылган искиткеч бүлекләрен укып ләззәт алган көннәрдә, Лермонтов яңадан сөргенгә озатыла. Бу юлы ул:

> Хуш, Россия, хуш, пычрак Россия,—
> Коллар һәм әфәнделәр илы,
> Һәм син дә хуш, зәңгәр полиция,
> Һәм син, шуңа буйсынган халык,
>
> Бәлки Кавказ таулары сыртында
> Сакланырмын патшаларыңнан,
> Барысын күрә һәм ишетә торган
> Күзләреңнән, колакларыңнан,—

дип саубуллашу шигырен яза. Ләкин бөтен политикасын халыкны изүгә, ирекне богаулауга корган царизмның „барысын күрә һәм ишетә торган" агентлары Кавказда да булалар. Ирек теләгән, „Ачыгыз минем төрмәмне" дип кычкырган Лермонтов алардан саклана алмый. Мартынов кебек вак кешеләр дуэль оештыралар. Лермонтов

41

«Татарстан большевигы», 1941 ел.

Шагыйрь, прозаик, Волошин фестивален оештыручы Алексей Коровин Татарстан шагыйрьләрен бергә җыю һәм ни өчен Коктебельне Алабугага охшатырга теләве турындагы фикерләре белән уртаклаша.

КЫРЫМ БЕЛӘН ТАТАРСТАН АРАСЫНДАГЫ ИҖАДИ КҮПЕР

– «Волошин сентябре» Халыкара фәнни-иҗади симпозиумы моннан 20 ел элек интернетта әдәби конкурс белән башланып китте. Волошин фестивале яңа проектлар ярдәмендә Кырымның төрле шәһәрләрен йөреп чыкты һәм менә Зур җиргә юл алды. 2022 елның ике юбилее – үзара дус булган Марина Цветаеваның 130 еллыгы һәм Волошинның 145 еллыгы, Алабуга белән Коктебельне, Кырым белән Татарстанны иҗади күпер аша тоташтырырга кирәк, дигән фикергә китерде. Идеяне Татарстан Президенты ярдәмчесе Олеся Балтусова һәм республиканың мәдәният министры Ирада Әюпова да хуплады.

Мин Татарстанда еш булам. Минемчә, республикада шагыйрьләр бердәм түгел. Аларны бергә тупларга кирәк дигән фикер туды. Фестивальдә бу бик уңышлы рәвештә тормышка ашырылды. Алабугада, «Заманча рус поэзиясендә Казан нотасы» кичәсендә, Татарстан шигърияте йолдызлары: Алексей Остудин, Глеб Михалев, Алена Кәримова, Нури Бурнаш, Алексей Кириллов, Олеся Балтусова катнашты. (Алабуга исә мине таң калдырды. Бу – тиңе булмаган музей-шәһәр. Без дә Коктебельне шундый итәргә хыялланабыз).

Икенче чара – «Казан әдәби берләшмәләре белән очрашу» кичәсе Казандагы Милли китапханәдә узды. Анда ARS POETICA, «Калитка», «Бутылка Клейна», «Белая ворона» әдәби берләшмәләре катнашты. Кунакка килгән шагыйрьләр белән мондый очрашулар зур иҗади дуслыкка нигез салыр, дип уйлыйм.

Волошин фестивале яңа шигърият формаларын даими эзләү юлында. «Любовь без парашюта» шигъри спектакле һәр шәһәрдә зур кызыксыну уятты.

«Шигърият театры» проекты кысаларында Казан театр училищесы белән хезмәттәшлек файдалы булды. Көмеш гасыр кагыйдәләре буенча шагыйрьләр турниры кызык үтте.

Волошин фестиваленең Россия буенча зур сәяхәте әле башланды гына, дип уйлыйм. Һәм аңа старт Татарстанда бирелде!

«Татарстан», 2022 ел.

Фото Андрей Коровиннан алынды

1941 елның маенда «Татарстан большевигы» журналында танылган татар шагыйре Гадел Кутуй рус шагыйре Михаил Лермонтовның үтерелүенә 100 ел тулу уңаеннан мәкалә бастыра. Анда ул шагыйрь иҗатының әһәмияте турында сөйли.

РУС ХАЛКЫНЫҢ БӨЕК ШАГЫЙРЕ

М. Ю. Лермонтов, 27 яшенә дә җитмәстән, 1841 нче елның июлендә һәлак булды. Аны патша реакциясе, царизм строе, Мартынов пулясы һәлак итте.

Гаять актив һәм гел алга омтылышлы характерда булган Лермонтов яшьтән үк царизмга каршы үзендә әче нәфрәт саклап үсә.

1825 елны декабристлар восстаниесе була. Канлы патша декабристларны җәзалау өчен мәйданга туплар китертә. Герцен бу турыда: «Сенат мәйданында туплар гөрселдәве бөтен бер буынны уятты», – дип язды. Лермонтов та әнә шунда уянган яңа буынның бер вәкиле.

Ул бала чагында ук Пушкинны яратып укый, ирек турында җырлаган бөек шагыйрьнең әсәрләрен аерым дәфтәргә күчерә, ятлый һәм үзе дә Пушкинга ияреп яза башлый.

Лермонтовның политик карашы, аңы декабристлар башлап җибәргән революцион юлда, Москва студентлары даирәсендә яшерен түгәрәкләрдә үсә. 30 нчы еллар башында Лермонтов революциянең Россиядә җиңәчәген алдан хәбәр итә...

1837 елга кадәр Лермонтов, берничә әсәре басылып чыкса да, киң массага танылмый әле. 1837 елда бөек Пушкин үтерелә. Лермонтовның «Шагыйрьнең үлеме» дигән шигыре халык тавышы булып яңгырый. Шигырь кулдан кулга йөреп күчерелә, ун меңнәрчә данә таратыла. Царизм Лермонтовны да үтерергә курка. Ул аны Кавказга сөргенгә җибәрә.

Социалистик Октябрь революциясенә кадәр буржуаз әдәбиятчылар Лермонтов иҗатын бозып күрсәтәләр иде. Аның иҗаты буржуаз әдәбиятчыларның ялган «анализ»ларыннан арчылды. Лермонтовны без хәзер рус халкының бөек политик шагыйре итеп аңлата алабыз.

Әйе, Лермонтов рус халкының бөек шагыйре. Ләкин аның иҗатындагы азатлык мотивлары, ватанны ярату тойгылары, якты киләчәк өчен көрәшкә чакыру көче – башка халыклар өчен дә уртак. Ул татар халык шагыйре Габдулла Тукайга да үз иҗатындагы җылылыкны бирә. Пушкин белән беррәттән, Лермонтовны да Тукай үзенә кояш итеп ала, аның әсәрләрен татарчага тәрҗемә итә.

Совет власте чорында Лермонтов әсәрләрен СССР халыклары телләренә тәрҗемә итү аеруча көчәйде. Татар телендә аның күп кенә лирик шигырьләре, «Безнең заман герое» романы, «Мцыри» поэмасы, «Купец Калашников турында җыр»ы һәм башка әсәрләре чыкты.

Лермонтовның үтерелүенә йөз ел тулу көннәрен үткәрүгә СССР ның барлык халыклары хәзерләнәләр.

Лермонтов әсәрләренең 1940-41 елларда рус телендә - алты миллион, СССР халыклары телләрендә ике миллион тираж белән чыгуы моңа бик ачык шаһит. Менә болар барысы да бөек шагыйрьгә совет халкының иң яхшы һәйкәле.

«Татарстан большевигы», 1941 ел.

юллар сузган октябрь

«Казан» халыкара аэропортына керү юлы. «Татарстан», 2022 ел.

Казан – Яр Чаллы юлы төзелеше. 1970 нче еллар.

2022 елның 14 октябрендә Татарстанда берьюлы ике мөһим объект — «Казан» халыкара аэропортына яңартылган керү юлы һәм «Салават Күпере» торак комплексын Горький шоссесы белән тоташтыру юлы сафка басты. «Татарстан» кешеләрнең тормыш сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән яңа юллар һәм проектлар турында сөйләде.

ЮЛЛАР — КИЛӘЧӘККӘ ТАБА БЕР АДЫМ

Ике магистральдә дә киң колачлы реконструкцияләрдән соң автомобиль хәрәкәтенә Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары Марат Хөснуллин һәм Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов старт бирде. Километраж ягыннан озын булмасалар да, юлларның барысы да территорияләрне алга таба үстерү өчен аерым әһәмияткә ия, дип белдерде Марат Хөснуллин. «Аэропортка керү юлы бөтен бер зонага үсеш бирә, бу системалы, комплекслы эш алып бару булып чыкты. Монда күргәзмә үзәге дә, торак йортлар да, аэропорт та бар. Кайчандыр Казан аэропорты ташыган пассажирлар саны миллионнан артмый иде, ә былтыр бу сан 3,8 миллионга җитте, бөтен авырлыкларга карамастан, быел да 3,8 миллион булды. Әлбәттә, мондый юллардан башка аэропорт алга таба үсә һәм эшли алмый иде. Өстәвенә, әлеге юл Европа–Көнбатыш Кытай трассасына карый», — диде РФ вице-премьеры.

«Аэропортка бара торган юлга төшкән йөкләнеш һәрвакыт зур иде, ә «Казан Экспо» күргәзмә комплексы төзелгәннән соң, биредә еш кына бөкеләр күзәтелде. Әмма реконструкция уздырып, юл киңәйтелде, нәтиҗәдә аның автомобильләр үткәрү сәләте ике тапкырга арттырылды», — дип билгеләп үтте Татарстан Президенты. «Салават Күпере» торак комплексын, Осиново бистәсен Горький шоссесы белән тоташтырган яңа юлга да ихтыяҗ бик зур иде.

«Татарстанда һәм гомумән ил күләмендә беркайчан да моның кадәр юл төзелгәне юк иде: М-12 дә, М-7 дә, Шәле–Баулы трассасы да. Бу ил һәм төбәкләрдәге җитәкчелек куйган барлык бурычларны төгәл үтәүче юл төзүчеләрнең фидакарь хезмәте нәтиҗәсендә чынга аша алды. Төзелеш темплары кимемәс, дип ышанабыз, без эшләргә әзер. Иң мөһиме – бу проектлар кешеләрнең тормыш сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән», – дип йомгаклады Рөстәм Миңнеханов.

«Татарстан», 2022 ел.

Фото: tatarstan.ru

Фото Валерий Барсуков архивыннан

«Татарстан коммунисты» басмасы битләрендә авторлар Ш.Мостаев, В.Хохлов һәм Р.Беляев 1971 елда 69 километр магистраль юлны ничек файдалануга тапшыру, 1975 елда Нократ елгасы аша ничек күпер салу һәм 1981 елда машина үз куәтенең өчтән бер өлешен начар юлларга сарыф итмәсен өчен нишләргә кирәклеге турында сөйли.

КИҢ ФРОНТ БУЛЫП

Ш. Мостаев,
Татарстан АССР финанс министры

...Быел «Каздорстрой» тресты коллективы 69 километр магистраль автомобиль юлларын файдалануга тапшырырга тиеш, шуларның 60 километры сәнәгать зонасына карый, калганнары — яңа шәһәрдә.

Февраль аенда юл төзүчеләр Орловка авылыннан яңа шәһәргә кадәр җир катламын салу эшен төгәлләде.

Бу участокта беренче тимербетон плитәләрне А. Сухов бригадасы салды. Апрель аенда участокны бетон белән түшәү эше тәмамланачак.

«Татарстан коммунисты», 1971 ел.

ВАКЫТЫНДА ҮТӘРБЕЗ

В. Хохлов,
КПСС өлкә комитетының төзелеш бүлеге мөдире урынбасары

...1975 ел төзелеш индустриясе базасы объектларын төзүне тәмамлау, Түбән Кама ГЭСында, Чаллы–Казан автоюлында, Нократ елгасы аша күпер салуда эшләрне киң җәелдерү елы булырга тиеш. 10 айлык эш нәтиҗәләре Кама автозаводы төзүчеләре һәм эксплуатацияләүчеләре коллективының әлеге бурычларны намус белән башкарып чыгу, социалистик йөкләмәләрне үтәү өчен бөтен мөмкинлекләргә ия икәнлеген күрсәтә.

«Татарстан коммунисты», 1975 ел.

ДАНЛЫ ТРАДИЦИЯЛӘРНЕ ҮСТЕРЕП

Р. Беляев,
КПССның Чаллы шәһәр комитеты беренче секретаре

...Машина үз егәрлегенең өчтән бер өлешен юллар белән көрәшкә сарыф итәргә тиеш түгел. Әлбәттә, илебез территориясенең зурлыгын, рельефының төрлелеген һәм сыйфатлы юлларның җитмәгәнлеген исәпкә алганда, бөтен җирдән үтә ала торган автомобильләр кирәк. Тик шунысы да ачык: төрле тармаклар өчен уртак проблемаларны тагын да активрак чишү зарур. Бу идея Илнең икътисади һәм социаль үсешенең төп юнәлешләрендә ачык чагылыш таба. Иң мөһиме – йөк автотранспортына үрнәк сыйфатта техник хезмәт күрсәтүне җайга салу һәм шуның хисабына «КамАЗ»ларның үтә алу сәләтен арттыру.

«Татарстан коммунисты», 1981 ел.

алдынгы рухлы ноябрь

Кунаклар Россия өчен махсус җыелган яңа автомобильдә йөреп карадылар.

Прокатка подошвенной кожи на фабрике „Спартак“.

«Татарстан большевигы», 1936 ел.

Юлсызлык шартларында йөри ала торган «люкс» классны беренче Россия машинасы Aurus Komendant булды. Аны күпләп җитештерү Татарстанда – «Алабуга» МИЗ мәйданчыгында 2022 елның ноябрендә башланды. РФ Хөкүмәте Рәисе урынбасары – сәнәгать һәм сәүдә министры Денис Мантуров проектның ил өчен әһәмиятен, әлеге вакыйгага ике ай кала, Көнчыгыш икътисади форумында бәяләгән иде.

Фото ТР Президентының матбугат хезмәтеннән алынды

AURUS KOMENDANT: РОССИЯДӘ ЭШЛӘНГӘН

«Aurus флагман проекты – безнең технологик дәрәҗәбезнең күрсәткече, без аңа соңгы 10 ел дәвамында ирештек. Мәсәлән, 2008 елда бу проектны тормышка ашыру авыр булыр иде, чөнки бездә бүген булган кайбер компетенцияләр әле юк иде». Шунда, Владивостокта ук, министр Komendant машинасын ноябрь ахыры – декабрь башында күпләп чыгара башлау мөмкин булачак, дип белдерде.

Татарстан автомобиль җитештерүчеләре сынатмады. 28 ноябрьдә Денис Мантуров һәм Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов тантаналы вакыйгада катнашты. Федераль министр Aurus җитештерүенең югары дәрәҗәдә локальләштерелүен билгеләп үтте: комплектлаучылар белән тәэмин итүчеләрнең 70%ы – Россия компанияләре. Көч җайланмасы да, трансмиссия дә, электроника да, интерьер да, бизәлеш тә – Россиянеке. «Киләчәктә Aurus бренды авиация проектларында һәм суднолар төзелешендә үсәчәк», – диде РФ сәнәгать һәм сәүдә министры.

Komendant – Алабуга заводында чыгарыла башлаган икенче модель. Әлеге автомобильне җыю өчен кирәк булган барлык технологик һәм җитештерү процессларын кыска гына вакыт эчендә эшләтеп җибәрү мөмкин булды.

Денис Мантуров та, Рөстәм Миңнеханов та яңа автомобильне сынап карадылар. Aurus Komendant махсус Россия шартларына җайлаштырылган. Ул юлсызлык шартларында йөрерлек егәргә, авыр юлларны үтә алу сәләтенә, шул ук вакытта седанның «люкс» классына хас комфортка ия. Заказлар 29 сентябрьдән - автомобиль Мәскәүдә киң җәмәгатьчелеккә рәсми рәвештә тәкъдим ителгәннән соң алына башлаган. Aurus – «люкс» классы автомобильләрнең беренче Россия бренды, аның линейкасында лимузин, седан, минивэн һәм внедорожник бар. Дәүләт проектка 12,4 миллиард сум акча керткән. Компаниянең акционерлары – «НАМИ» ФДУП (63,5%), БГӘ оборона, куркынычсызлык һәм үсеш фонды. Aurus автомобильләре Алабуга (Татарстан) заводында җитештерелә.

Protatarstan, 2022 год.

Кайчандыр икътисади ыргылышларның шактые стахановчылар хәрәкәтеннән башланган. «Татарстан большевигы» журналы һәм «СПАРТАК» комбинатының авыр аяк киемнәре цехы парторгы С.Бегун ничек стахановчы булырга һәм бу хәрәкәтне ни рәвешле үстеререргә кирәклеге турында сөйли.

МИН КОММУНИСТЛАРГА НИЧЕК СТАХАНОВЧЫ БУЛЫРГА БУЛЫШТЫМ

– 1935 елның 25 ноябрендә мине «Спартак» күн аяк киемнәре комбинатының авыр аяк киемнәре цехына парторг итеп куйдылар. Цехта – 400 эшче, шул исәптән 16 партия әгъзасы, 12 партия әгъзалыгына кандидат, 62 комсомол бар.

Эшли башлау вакыты илдә стахановчылар хәрәкәтенең оешып китүе, аны киң җәелдерү чорына туры килде.

Әгәр 25 ноябрьдә бездә бер генә стахановчы – партия әгъзалыгына кандидат иптәш Ильин булса, хәзер стахановчылар 17 кеше исәпләнә. Стахановчыларның саны безне һич тә канәгатьләндерми, чөнки һәр эшче, бигрәк тә һәр коммунист стахановчы була ала.

Безнең цехта яңа җиһазлар юк диярлек. Станоклар да, машиналар да иске. Шуңа күрә кайберәүләр бу шартларда стахановчы булу мөмкин түгел дигән шик таратты. Күн җитештерүе – үзенчәлекле, биредә ташкүмер чыгарыла торган шахталардагы кебек рекордлар куеп булмый дигән сөйләшүләр дә булды. Стахановчылар хәрәкәтен җәелдерүгә каршылык тудыра торган бу сөйләшүләргә каршы көрәш алып бардык.

Заводта 7 ел эшләү дәверендә мин авыр аяк киемнәре цехының җитештерү процессын өйрәндем. Бу белемнәр миңа стахановчылар хәрәкәтен җитәкләүдә файдалы булды.

Иптәш Карягина мисалын китерәм. Аның эшендә әкренлек шактый сизелә иде. Арткы каешны теккәндә ул җөйнең тигезлеген күп мәртәбәләр карый иде, шуңа күрә эше дә әкренәя. Мин Карягинага тегүне ахырга кадәр туктатмаска киңәш бирдем. Ә инде каешлар артыннан үзенә йөгермәс өчен, ярдәмче хезмәткәр алырга тәкъдим иттем. Нәтиҗәдә коммунист Карягина стахановчылар хәрәкәтенә кушылды һәм эш нормасын 208–210%ка үти башлады.

Партия әгъзалыгына кандидат Ибәтуллинага да итек тегүне туктаусыз башкарырга киңәш иттем. Станокның тизлеген көчәйтү өчен, трансмиссияне минутына 100 әйләнешкә арттырдык. Ибәтуллина да алдынгылар хәрәкәтенә кушылды. Карягина башкарган продукциянең дә, Ибәтуллинаныкының да сыйфаты яхшырды.

Карягина һәм Ибәтуллина артыннан Краснова һәм Әхмәтова (икесе дә комсомол) стахановкалар булды. Безнең цехта стахановчыларның аз булуы цех эшчеләрен коллектив тырышлык белән стахановчылар хәрәкәтенә җәлеп итүгә минем барлык коммунистларны да мобилизацияли алмавым белән аңлатыла. Эшемдәге зур кимчелегем – күп нәрсәне берүзем эшлим. Үз җитешсезлегемне аңладым һәм аны төзәтергә тырышачакмын.

«Татарстан большевигы», 1936 ел.

мәдәни декабрь

«Без бик яхшы эшләдек, – диде Минтимер Шәймиев. – Әгәр шундый мөһим конвенцияләрне билгеләп үтмәсәк, без үзебезнең хөрмәт итүдән туктар идек. Шундый катлаулы вакытта килүегез өчен рәхмәт!» Protatarstan, 2022 ел.

Фото: tatarstan.ru

Энгельгардт исемендәге Астрономия обсерваториясе. «Татарстан», 2017 ел.

Фото: Сергей Головкин

2022 елның 1–9 декабре көннәрендә Казанда һәм Санкт-Петербургта Бөтендөнья мирасын саклау турындагы конвенциясенең 50 еллыгына багышланган Халыкара форум үтте. Бирегә дөньяның 56 иленнән ЮНЕСКО белгечләре җыелды. Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе, «Яңарыш» республика фондының Попечительләр советы рәисе, ЮНЕСКОның Игелекле ихтыяр илчесе Минтимер Шәймиев үзгәрешләр кичерүче дөньяда мәдәни кыйммәтләрнең үзгәрешсез калуы турында сөйләде.

ШУНДЫЙ КАТЛАУЛЫ ВАКЫТТА КИЛҮЕГЕЗ ӨЧЕН РӘХМӘТ!

– Хәзер дөнья күз алдыбызда үзгәрә бара. Ләкин әлеге кыйммәтләр сугыштан соң ук билгеләнгән иде. ЮНЕСКО бу кыйммәтләрне һәм сугыштан соңгы карарларны кабул итте. Ватаннарының азатлыгын саклап кала алганнар турындагы хәтерне саклап. Хәзер гомумән канкоешка, низагларга юл куярга ярамый. Ләкин, кызганычка каршы, алар вакыт-вакыт чыгып тора. Шуңа күрә без әшебезне көчәйтергә тиеш. Без кемгәдер бәйле була алмыйбыз. ЮНЕСКО – ул Берләшкән Милләтләр Оешмасы.

...Күз алдыгызга китерегез: бу очрашуны булдырмаска күпме тырыштылар! Ләкин без алай эшли алмыйбыз. Республиканың төп шигаре: «Без булдырабыз!». Эшкә аяк чалучылар белән килешә алмыйбыз: «булдыра алмыйбыз» дигән сүзләрне без шул очракта гына кулланабыз. ЮНЕСКО кемнеңдер таләпләренә җайлаша алмый. Ул әйдәп баручы көчкә ия булырга тиеш.

ЮНЕСКО кысаларында берләшкән вакытта, без аның юбилеен билгеләп үтәр өчен кемнәндер рөхсәт сорыйкмы?! Без гамәлләр кылырга тиеш, һәм алар дөрес булырга тиеш…

...Быел Россия Президенты Владимир Путин ярдәме белән ЮНЕСКО аша аларның исемлегендә булган Болгарны өйрәнү кысаларында бөтен дөньяга бер нәрсәне исбатладык. Мин ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын иреклe бәйрәм итү турында әйтәм. Менә бит мәсьәләне ничек хәл итеп була!

Хәзер бездә өч Бөтендөнья мирасы объекты бар. Казан обсерваториясе дүртенчесе булырга әзерләнә. Беренче булып ясалма иярчен җибәргән, беренче булып кешене галәмгә очырган илдә бу әле үз бәясен алып бетермәгән. Бүген объектларны саклау проектларының барлыгы турында кычкырып сөйләү мөһим. Бу еллар эчендә без торгызган Зөя һәм Болгарда туристлар саны миллионлаган кешегә җитте.

Бөтендөнья мирасы объектлары белән кызыксыну арта бара. Алар укучыларның күңелендә калырга тиеш. Укучылар бу объектларда булырга, аларны яратырга тиеш. Бездә инде тәҗрибә бар. Безнең хыялланып кына торырга вакытыбыз юк. Хыяллар тормышка ашарга тиеш! Бүген уйлыйбыз һәм бүген үк эшлибез.

Бу бәйрәмне үткәрүебез белән горурланабыз! ...Без бик яхшы эшләдек. Әгәр шундый мөһим конвенцияләрне билгеләп үтмәсәк, без үзебезне хөрмәт итүдән туктар идек. Шундый катлаулы вакытта килүегез өчен рәхмәт!

Protatarstan, 2022 ел.

ТАТАРСТАННЫҢ ЙОЛДЫЗЛЫ КҮГЕ

ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасының булачак дүртенче объекты – Казан обсерваториясенә «Татарстан» ел саен бара.

КФУ Планетарие лекторы Сергей Головкин телескоп һәм фотокамераларның астрономнарга Галәм серләрен ачарга мөмкинлек бирүе, йолдызлы күкнең матурлыгы турында сөйләде.

– Мин астрономия белән мәктәптә кечкенә сыйныфларда укыганда ук кызыксына башладым. Ә менә фотография белән өлкән сыйныфларда мавыгып киттем. Шулчакта үз кулларым белән беренче телескобымны җыйдым... Миңа һәрвакыт пейзажлар төшерү ошый иде, ләкин барыннан да бигрәк караңгыда, бөтенләй яктылык юк кебек тоелган чакта фотога төшерергә яратам. Яктылык булмаса да, фотоаппарат кеше күзе күрә алмаган караңгылык серләрен ачарга мөмкинлек бирә. Йолдызлы күкне күрергә, мәсәлән. Безнең күзләрдән яшерелгән ерак йолдызлыкларны. Телескоп һәм фотокамералар астрономнарга – Галәм серләрен ачарга, ә калганнарга астрономия объектларының гаҗәеп матурлыгына сокланырга мөмкинлек бирә. Йолдызлы күкнең матурлыгы беркемне дә битараф калдыра алмыйдыр...

Энгельгардт исемендәге Астрономия обсерваториясе директоры Юрий Нефедьев үзе исемендәге обсерваториясендә Энгельгардтның ни өчен беркайчан да булмавы, нигә хатларга һәрвакыт җавап бирергә кирәклеге турында сөйләде.

– Сез гаҗәпләнерсез, әмма Василий Павлович Энгельгардт исән чагында монда беркайчан да булмаган. Шәхси обсерватория төзеп, аны астрономик күзәтүләр өчен иң яхшы җиһазлар белән тәэмин итеп, ул үз хыялын Дрезденда тормышка ашырган. Аның хезмәтләре бөтен фәнни җәмәгатьчелек тарафыннан танылган, ә ул үзе Россия Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы булган!

Бервакыт кометаларның берсен тикшергәндә, аның үз уйларын фикердәшләренә җиткерәсе килгән. Телләгe бик көчле булганга, ул хатлар юллый башлаган. Җавап бары тик Казаннан – Казан император университеты ректоры Дмитрий Иванович Дубяго дан гына килгән. Фәнни карашларның уртаклыгына нигезләнгән дуслык шул рәвешле башланган. Ә инде яше өлкәнәю сәбәпле, күзәтүләрен дәвам итә алмавын аңлагач, Василий Энгельгардт үзенең астрономия инструментларын Казан университетына тапшырырга карар кылган. Өстәвенә ул обсерватория төзелешен дә финанслаган. Казан университетын мондый игелекле гамәл битараф калдырмый. Үлеменнән соң йөз ел узгач, Василий Павловичның васыяте үтәлә: аны бирегә күчереп җирлиләр, кабер плитәсендә лампадканы мәңге яндырып торырга дигән карар язылган документ та бар.

«Татарстан», 2017 ел.

СТРАТЕГИК ӘҺӘМИЯТТӘГЕ КОРЫЛМА

Ак кроссовер Чаллыдагы КАМАЗ фәнни-техник үзәгенең карлы полигонында оста гына иттереп үз маневрын тәмамлый. Руль артында – Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов.

Бу – Чаллы автогиганты һәм Мәскәү автомобиль җитештерүчесенең уртак эшләнмәсе – электрга корылган «Москвич Зе» автомобилен сынау. Татарстан Президенты һәм «Ростех» җитәкчесе Сергей Чемезов КАМАЗ полигонында 2022 елның декабрь уртасында булды. Ә бераз алдарак Рөстәм Миңнеханов Төркиядә җитештерүгә әзерләнә торган TOGG электр машинасында йөреп карады. Республика башлыгының электромобильләр белән кызыксынуы юктан гына түгел. Соңгы елларда Татарстан электр транспортын һәм корылмалы инфраструктура темасын үстерү белән актив шөгыльләнә.

Республиканың яңа технологияләрне кертүгә традицион омтылышы федераль трендка яхшы туры килде. Электромобильләр булдыру хәрәкәте күптән инде уен эш түгел, ул 2035 елга кадәр Россия автомобиль сәнәгате үсешенең яңа стратегиясенең бер өлеше. Документка ярашлы рәвештә, 2030 елга электрокарлар сату барлык транспорт чаралары сатуның 15%н тәшкил итәчәк, ә илебездә җитештерелгән электр машиналарын чыгару күләме елына 217 меңгә җитәчәк. Илдә 70 меңнән артык корылма станциясе эшләячәк. Электрокарлар өчен компонентлар, шул исәптән төп элемент – батареялар җитештерүче заводлар ачылачак. Татарстанда моңа актив әзерләнәләр. 2022 елда республика электр корылмасы инфраструктурасын үстерүгә федераль субсидияләр алган сигез пилот төбәк исемлегенә керде.

– Менә өч ел инде мин электр машинасы хуҗасы. Тиз һәм бик экономияле машинада рәхәтләнеп йөрим һәм, дөресен генә әйткәндә, һаман да эчке янулы двигательле машина белән азапланган кешеләрне аңламыйм, – ди Чаллыда яшәүче ир. Алексей Nissan Leaf автомобилен 2019 елда сатып алган. Татарстанда әле электрга көйләнгән машиналар аз, булганнарын фатир тәрәзәсеннән озынайткыч аша чыгарылган электр белән коруның иң популяр чагы. Хәзер Алексей һәм аның электромобильле дуслары республика шәһәрләре буенча гына түгел, алар арасында да тыныч күңел белән йөри, хәтта күрше төбәкләргә дә барып кайта ала.

Татарстанлылар өчен корылмалы инфраструктураны булдыруда күпчелек эшне «Челтәр компаниясе» башкарды. Ләкин хәтта электр белән тәэмин итү төп эше саналган «Челтәр компаниясе» өчен дә, федераль субсидияләү программасы таләп иткәнчә, бер ел эчендә 95 корылма станциясе урнаштыру катлаулы бурыч булды.

Татарстанлылар өчен электромобиль нәрсә ул:

Электромобиль бурычка йөрү мөмкинлеге бирә!

Игорь Н.

Йөк ташу бизнесы һәм логистика турындагы күзаллауларны җимерә: башта йөртәсең, ә аннан соң түлисең (гадәттә ай ахырында счетчик буенча); ЯММ урлау мөмкинлеге юк; 30 мең км саен техосмотр өчен туктарга кирәкми.

Дмитрий М.

Электромобиль алгач, дусларым кимеде, чөнки алар сине бу җир кешесе дип санамый, аның каравы башкалары пәйда булды.

Георгий В.

Бизнес өчен бу ягулык һәм эксплуатация чыгымнарында экономия, ышанычлылык. Минем өчен шәхсән – тормышка яңача карашлы, бердәм булып электромобильләр инфраструктурасын (корылма алу, сервис, сатулар, фестивальләр һ.б.лар) үстерүче электромобиль хуҗалары мохите.

Андрей П.

Бу – транспортны бөтенләй башкача кабул итү. Экономия түгел, бу – автономиялелек, нәтиҗәлелек, экология һәм технологиялелек. Идарә итүнең бөтенләй башка дәрәҗәсе һәм гадәти автомобиль өчен хас булмаган гаять көчле динамика.

Дмитрий М

Фото: tatar-inform.ru, ТР Президентының матбугат хезмәте. РЕКЛАМА

АЛГАРЫШ ЮЛЫНДАГЫ СТАНЦИЯ

Электр корылмасы бирә торган өч яңа станциянең берсенә, Ямашев проспекты, 57а йортында урнашканына, Nissan Leaf автомобиле килеп туктый. Хуҗасы машинаны корылма алу җайланмасына тоташтыра, смартфондагы кушымтаны кабыза. Станцияләрне тоташтыру тантанасында ике дистә кеше аның гамәлләрен күзәтә. Автомобиль корылма җыя башлый! Хәзер инде Татарстанда бер көндә тантаналы рәвештә ачылган шушы һәм тагын 94 электр корылмасы станциясе файдалануга тапшырылган дип санала.

– Электр корылмасы станцияләре (ЭКС) федераль программаны гамәлгә ашыру кысаларында төзелде. Программа безнең инженерлар, станцияләрне уйлап табучы һәм җитештерүче Татарстан белгечләре тырышлыгы белән үтәлде. Проект кысаларында 500 млн сумга якын акча сарыф ителде, шуларның 175 млн сумын федераль субсидияләр тәшкил итә, – диде станцияләрне эшләтеп җибәрү тантанасында «Челтәр компаниясе» АҖ генераль директоры Илшат Фәрдиев.

Федераль программада катнашу электр челтәре компаниясенең 2021 елда Татарстанда электр корылмасы бирү инфраструктурасын үстерүгә юнәлдерелгән башлангычларының эзлекле дәвамы булды. Конкурска кадәр үк компания электр транспортын үстерүнең республика программасын эшләүдә актив катнашып килде, электр корылмасы станцияләре куйды һәм үз электромобильләр паркын булдырды. Нәкъ менә шуңа күрә дә «Челтәр компаниясе» үз ихтыяҗлары өчен станцияләр урнаштырды. Ике ел элек район филиаллары белгечләре дә электромобильләргә күчкән. Бүген компания паркында 23 электромобиль бар, шул исәптән базардагы яңа продуктлар – Кытайда җитештерелгән JAC һәм быел Россия – Кытай хезмәттәшлегендә чыгарылган Evolute машиналары да. Электрокарларны актив эксплуатацияләү «Челтәр компаниясе»нә ЭКСлар-

Фото «Челтәр компаниясе» АҖ матбугат хезмәте тарафыннан тәкъдим ителде. Реклама

ның тулы бер челтәрен эшләтеп җибәрү мизгеленә әзер булырга мөмкинлек бирде, шулай да төрле кыенлыклар очрамый калмады.

РЕСПУБЛИКА БУЙЛАП – КАРШЫЛЫКЛАРСЫЗ

– Безнең өчен бу – ил дәрәҗәсендәге яңа проект. Шунысы да әһәмиятле: монда импортны алыштыру эше дә гамәлгә ашырылган – без Татарстандагы ЭКС җитештерүчеләрнең продукциясен кулланабыз. Федераль программага кергән 12 пилот төбәктән 3 се ЭКС урнаштыру планын үти алмады. Максат итеп куелган күрсәткечкә ирешүебездә инде тәҗрибәбез булу һәм кызыксынучы якларның актив хезмәттәшлеге зур роль уйнады: проблемалар муниципалитетлар, дәүләт органнары, станцияләрне җитештерүчеләр белән берлектә хәл ителде, – ди компания эшчәнлегенең башка төрләрен үстерү бүлеге җитәкчесе Наил Сәләхетдинов. – Ләкин станцияне урнаштыру һәм тоташтыру – эшнең башы гына. Бу станцияләрне эксплуатацияләү, кулланучыга очрашырга туры килгән төрле каршылыклар, үзенчәлекләр – бу сораулар буенча эле эшлисе бар.

«Челтәр компаниясе» тарафыннан куелган яңа ЭКСлар быел Казанда, Чаллыда, Түбән Камада, Әлмәттә, Арча, Алабуга, Лаеш, Менделеевск, Нурлат һәм башка районнарда республиканы күрше төбәкләр белән бәйли торган юллар янында урын тапты. Башка оешмалар урнаштырган станцияләрне дә исәпкә алганда, хәзерге көндә Татарстанда 166 электр корылмасы станциясе эшли. Хәзер республика аша электромобильдә узып китү, хәтта батарея куәте әллә ни зур булмаса да, кыенлык тудырмый. – Шәһәрләрдә ЭКСларга ихтыяҗ хәл ителде, чиратта – станцияләрне федераль һәм төбәк юлларында ешрак урнаштыру, – дип билгеләп үтә Наил Сәләхетдинов.

ЭКС БИЗНЕСКА КӨЧ БИРӘ

Электр корылмасы бирү инфраструктурасын сатып алуга һәм үстерүгә ташламалар – шушы ике кызыксындыру чарасын 2022 елда электромобильләр сатып алган россиялеләр төрле сораштыруларда аеруча еш телгә ала. Былтыр Татарстанда электрмобильләр саны 304 тән 400 гә кадәр артты. ЭКС челтәренең алга таба үсеше электромобиль йөртүчеләр санының да артуына китерәчәк.

– Электромобильләр экономиялелеге белән җәлеп итә. Өйдә аккумуляторны корып, сез акчаны берничә тапкыр янга калдырасыз, өстәвенә бензин двигателенә хезмәт күрсәтү дә таләп ителми. Хәзер «Челтәр компаниясе» станцияләре бушлай корылма бирә. Киләчәктә түләүле режим эшли башлаячак – бер киловатт өчен 15 сум. Бәя Мәскәүгә, Мәскәү өлкәсенә, Санкт-Петербургка караганда шактый түбән һәм ул нәкъ менә электромобильнең экономиялелеген саклый торган дәрәҗәдә, – ди «Идел буе электр челтәрләре» филиалының мәгълүмати технологияләр хезмәте башлыгы Равил Бәхтиев. Ул үзе дә ел ярым электромобильдә йөри һәм андый машиналарның тизләре (егәрлеге 50 кВт тан зуррак, батарея сыйдырышлыгына карап, корылма җыюның якынча вакыты – 0,5–1 сәгать), акрын эшли торганнары да (егәрлеге 50 кВт тан кимрәк, корылма җыюның якынча вакыты – 1,5 сәгатьтән озаграк) булырга тиеш, дип саный.

– Акрын корылма җыю бизнесны үстерү өчен өстәмә этәргеч булып тора. Ял көннәрендә шәһәргә чыкканда, корылма җыярга кирәк икән, машинаны станциягә куям да балалар белән якындагы кафега яки сәүдә үзәгенә барам. Киләчәктә сәүдә яки сервис объектлары өчен бу өстәмә керем чыганагы булырга мөмкин, – ди Равил Бәхтиев.

«ХЕЙТЕРЛАР, МИН СЕЗНЕ ЯРАТАМ!»

Һәр яңа күренеш кебек, электромобильләр тармагының да җитешсезлекләре бар, аларны үтәргә, җиңәргә өйрәнергә кирәк. «Рестарт» автоном коммерциячел булмаган оешмасы бу мәсьәләләрдә ЭКС челтәрләренә дә, станцияләрне җитештерүчеләргә дә, электромобиль йөртүчеләргә дә актив ярдәм итә.

– «Телеграм»да үз чатыбыз бар, һәм аңа хәзер 360 кеше язылган. Болар – электрокар хуҗалары, станцияләр һәм кулланучылар өчен программалар яза торган компанияләр, «Челтәр компаниясе», Татарстан һәм күрше төбәкләрдән башка ЭКС операторлары вәкилләре. Мин: «Хейтерлар, мин сезне яратам!» – дип әйтергә телим. Безнең чатка язучы һәркем (шикаять язамы ул, мактаумы яки сорау бирәме – анысы мөһим түгел) электромобильләр темасын үстерергә бик булыша, – ди «Рестарт» АКБО энтузиасты һәм вәкиле Рөстәм Галимҗанов. – Килеп туган проблемаларны тиз арада хәл итеп, без «Челтәр компаниясе»нең берьюлы 100 гә якын ЭКС урнаштырудан гыйбарәт искиткеч зур адымының нәтиҗәлелеген арттырабыз. Бүген Татарстан – илдә электромобильләр тармагына җан өрүчеләрнең берсе. Безнең берләшмәбез никадәр зуррак булса, алгарыш та шулкадәр тизрәк барачак. Электромобильләр – декарбонлаштыруга таба зур адым ул. Ләкин монннан тыш, тамырдан яңа җитештерүләрне җәелдереп җибәрү һәм электромобильләр базары өчен кирәкле продуктларны үстерү мөмкинлеге дә. Бу юнәлештә дә Татарстан беренче була ала.

Сүз уңаеннан, бу беренчелеккә КАМАЗ белгечләре катнашында ясалган «Москвич 3е» нигез салды. Узган ел ахырында Мәскәүдә тәүге машиналар инде сатуга да чыкты.

PRESSA

Ихтимал булган электромобильле киләчәктә машинаны уңайлы урында кору кайда да булса туктау кебек табигый булачак. UD Group компаниясе мондый киләчәкнең нигезен бүген үк сала.

«ЯШЕЛ ЭНЕРГИЯ» ТАМГАСЫ АСТЫНДА

Девелопмент бүген күчемсез милек белән идарә итүдән җәйләп кына бу милек урнашкан мохит белән идарә итүгә күчә бара. Менә ни өчен UD Group яңа перспектив юнәлешләргә басым ясый: объектны дистәләрчә ел алга үстерү мөмкинлеген башлангыч стадиядә үк салып калдыруны күздә тоткан проектлау эшләреннән алып, корпоратив венчур-билдер ярдәмендә үсеш алган һәм, мәсәлән, аддитив технологияләр (3D-басма) ярдәмендә төзелеш конструкцияләре җитештерүнең роботлаштырылган челтәрен булдыру проекты өстендә эшләүче PropTech-стартапка кадәр.

Электр корылмасы станцияләре челтәрен булдыруны күздә тоткан Greengy проекты шул рәвешле пәйда була. Мондый амбициоз инициативага старт Казанда бирелә: чыннан да инфраструктуралы һәм электромобильләр ягыннан үсеш алган Татарстан – мондый башлангычлар өчен уңайлы төбәк.

– Без электрокарлар базарының һәм, димәк, электр корылмалары станцияләренең зур потенциалы бар, дип ышанабыз, шуңа күрә бу бизнесны технологик партнерыбыз – Touch компаниясе белән бергә үстерергә булдык, – ди Greengy директоры Роман Тюкалов.

Greengy станцияләре нәкъ менә Touch тарафыннан эшләнгән. Куәте 44 кВт булган җайланмаларның һәрберсе электромобильне, батареясының сыйдырышлыгына карап, 1,5-4 сәгать эчендә кора ала.

Бу процессның мөһим компоненты – станцияләргә хезмәт күрсәтү.

– UD Group үз клиентларына хезмәт күрсәтүне көйләү буенча зур тәҗрибәгә ия. Без бу тәҗрибәне Greengy сервис белгечләрен әзерләүдә максималь кулландык. Корылманы өзеклекләрсез һәм куркынычсыз итеп җыю – электромобиль хуҗалары электр корылмасы станцияләреннән шуны көтә. Бүген, электр белән корылу юнәлешенең барлыкка килү чорында, бу төп өстенлекләрнең берсе һәм ул бездә бар, – ди Роман Тюкалов.

Фото Greengy компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА

УҢАЙЛЫЛЫК СТРАТЕГИЯСЕ

Greengyның үсеш стратегиясе кирәк һәм уңайлы булган урыннарда электр корылмасы станцияләренең санын арттырудан гыйбарәт.

– Үзебезнең потенциаль мәйданчыкларыбыз картасын формалаштырганда, без аларны шәһәр халкы өчен уңайлылыгы ягыннан бәяләргә тырышабыз, – ди Роман Тюкалов.

Компанияне электромобиль хәрәкәте трендының акрын темплары һәм бу юлда пәйда булган киртәләр куркытмый.

– Электромобильләр базары бер ел элек фаразланган темпларда үсә алмый. Сәбәпләре, минемчә, бик ачык – бу сатып алудагы гап-гади кыенлыклар. Иң дөрес чишелеш – эчке җитештерүне үстерү һәм Кытай җитештерүчеләрен актив җәлеп итү, – дип аңлата Роман Тюкалов.

Greengy директоры сүзләренә караганда, станцияләрне технологик тоташтыру мәсьәләләре дә һәрвакытта да җиңел генә хәл ителми. Ләкин компания мәйданчыкларны эзли, өйрәнә, эшнең төрле форматларын сынап карый, чөнки киләчәк статик түгел, һәм бүген электромобиль хәрәкәтенең үсеш сценарийлары шактый.

– Безнең Татарстанда электр корылмалары бирү инфраструктурасын үстерүгә керткән өлешебез саллы булыр, дип ышанабыз, чөнки яңа электр корылмасы станцияләрен ачу буенча кыю планнарыбыз бар, – дип сөйли Роман.

– Иң беренче нәрсә: тавыкмы, әллә йомыркамы, электрокармы, әллә аның өчен инфраструктурамы дигәндә, без инфраструктураны булдыручылар ягын сайлыйбыз. Ансыз потенциаль электр машиналары хуҗаларын электр машинасына күчү өчен уңайлы мөмкинлекләр булыр, дип ышандыру кыен.

– Без сыйфатлы хезмәт күрсәтү юлыннан барабыз. Безнең бизнес-партнер заманча уңайлы платформа тәкъдим итә. Эштәге өзеклекләрне киметү өчен, үз станцияләребездә ике этаптан торган тест үткәрәбез. Беренчесе – аларга машинаны тоташтырганнан соң һәм турыдан-туры җитештерү мәйданында корылма алуны бәяләгәннән соң. Икенчесе – станцияне урнаштырган урында, аның дөрес эшләвенә тагын бер кат инану өчен, – дип сөйли Greengy компаниясе җитәкчесе.

Компания станцияләре Type 2 розеткалары белән тәэмин ителгән. Шулай ук Type 1 кабельләрен урнаштыру мөмкинлеге дә бар. Кытай электр машиналары хуҗаларына, электромобиль комплектациясенә кирә торган кабельне алып, аны ЭКС розеткасына тоташтыру да җитә. Станцияләргә һәм клиентларга хезмәт күрсәтү белән сервис белгечләре командасы шөгыльләнә. Болар барысы да алга таба бару – электромобильчеләрне каршы алуга әзерлек.

ЭКС ЧЕЛТӘРЕН ДИНАМИК ҮСТЕРҮ БУЕНЧА GREENGY КАГЫЙДӘЛӘРЕ:

- Теләсә нинди электрокарны тоташтырып була торган универсаль һәм куллануы җиңел җиһазлар.
- Онлайн режимда станцияне броньлау һәм чират булмаган станцияләр турында мәгълүмат бирү функцияләренә ия технологияле һәм уңайлы кушымта.
- Эштәге өзеклекләрне һәм тик тору вакытын киметү өчен вакытында профессиональ хезмәт күрсәтү.

ПАРТНЕРЛЫККА ЙӨЗ ТОТУЧЫЛАР

Компания тәкъдим иткән ноу-хау – станцияләрне арендага бирү. Гадәти автомобильләрдән аермалы буларак, электрокарлар «ягулыкны» шактый озак сала. Шуңа күрә дә Greengy техник тоташу мөмкинлеге булган хуҗалыкларда яшәүче электрокар хуҗаларына, станцияне тоташтыруда һәм хезмәт күрсәтүне оештыруда ярдәм кулы сузып, лицензияле станцияне вакытлыча куллануга алып торырга тәкъдим итә. Профессиональ җиһазлар урнаштыру үзең куйганда килеп чыгарга мөмкин булган куркынычларга юл калдырмый.

– Greengy – Green Energy – «яшел энергия» дигәннән алынган. Бик мөһим һәм дөрес гамәлләргә – зарарлы матдәләр чыгаруны киметүгә, экология һәм киләчәк буыннар өчен уңайлылыкларга өлеш кертү мөмкинлеге безне рухландыра. UD Group компаниясе ESG (экологик, социаль һәм корпоратив идарә итү – ред. иск.) принципларына тугры, һәм безнең Greengy проекты моңа бик яхшы туры килә, – ди Роман Тюкалов. – Без үзебезне чиста энергия партнерлары буларак күрсәтәбез. Без халык өчен сервислар үстерү белән кызыксынучы һәм үз торак комплексларында электр корылмасы җайланмаларын урнаштыручы төзүчеләр, кунакларына һәм арендаторларына корылма алу мөмкинлеген тәэмин итүче сәүдә һәм бизнес-үзәкләр хуҗалары белән хезмәттәшлек итәбез. Ләкин иң мөһиме – без теләсә нинди электромобиль хуҗасы өчен партнер булырга телибез, уңайлы һәм куркынычсыз хезмәт күрсәтелә торган киң электр корылмалары челтәрен тәкъдим итәбез, шулай ук мондый мөмкинлекне шәхси куллануга да тапшырабыз.

GREENGY – ЧИСТА ЭНЕРГИЯ БУЕНЧА ПАРТНЕРЫГЫЗ!

ХКҮ
Казан Экспо

ТАТ АГРО ЭКСПО 2023

20-21 февральдә
АСК казанышларының
V махсуслаштырылган
авыл хуҗалыгы күргәзмәсе

- ТЕХНИКА ҺӘМ ЗАПАС ЧАСТЬЛАР
- ҮСЕМЛЕКЧЕЛЕК
- ЦИФРЛАШТЫРУ
- АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ПРОДУКЦИЯСЕН САКЛАУ, ЭШКӘРТҮ ҺӘМ ТӨРҮ
- АГРОХОЛДИНГЛАР
- ТЕРЛЕКЧЕЛЕК
- ХУҖАЛЫК ИТҮНЕҢ КЕЧЕ ФОРМАЛАРЫ

Оештыручылар:

Татарстан Республикасы
Авыл хуҗалыгы
һәм азык-төлек
министрлыгы

«РАЦИН» АҖ

+7 (843) 221-77-95

expo.racin@tatar.ru

tatagroekspo.ru

Реклама

акыллы гамәлләр

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Татарстанның төзелеш отрядлары Әстерханда **күпме** помидор җыйган

Кулы оста **нинди** матурлыклар тудыра ала...

Ни өчен игезәкләр бер-берсен сүзсез аңлый

Фотолар проекта катнашучыларның архивыннан.

«Татарстан» журналының махсус проекты

ЗАРЛАНМЫЙЧА ЭШЛӘГӘН БУЫН

Авыр вакытларга, кырыс заманнарга, кайчак түзеп булмаслык тормыш шартларына да карамастан, зарланмый-сукранмый, үз юлларында очраган бөтен кыенлыкны җиңеп, бу буын кешеләре алга атлаган, дөньяны ямьлерәк, уңайлырак итәргә омтылган. Алар юллар төзегән, күперләр сузган, электростанцияләр, заводлар салган, яу кырларында ватанны саклаган, сугыштан соңгы хәрабәләрне күтәргән, студент елларында, төзелеш отрядларына берләшеп, шәһәр-авылларны төзекләндерергә, кырларда уңышны җыеп алырга булышкан.

«Татарстан», үзенең каһарман якташлары белән очрашып, сезне әлеге фидакарь буынның маҗаралар тулы тормыш юлы белән таныштыруны дәвам итә.

Моннан алдагы тарихларны басмабызның 10-12 нче саннарында укый аласыз.

10 нчы тарих

Татарстанның төзелеш отрядлары Әстерханда ничек помидор җыйган

PRESSA

ҺӘРКЕМГӘ ДӘ БИРЕЛМӘГӘНДЕР УЛ, ЯШЬНӘҮ-КҮКРӘҮЛӘРГӘ ТИҢ ГОМЕР.*

Анастасия Маркелова

Ярты гасыр элек Татарстан студентларыннан тупланган авыл хуҗалыгы отрядлары, уңыш җыюда булышу өчен, беренче тапкыр Әстерхан өлкәсенә юл тота. Безнең төзелеш отрядларының авыллар, бөтен ил үсешенә керткән өлешен сумнарда да, километрларда да, тонналарда да хисаплап бетерерлек түгел. Аларны яшь эшче көчләр буларак кына түгел, ә халыкка культура алып килүче көч буларак та югары бәялиләр. Студентлар авыл кешеләре өчен лекцияләр укый, үзешчән сәнгать концертлары, дискотекалар, җыр фестивальләре, төрле түгәрәкләр һәм спорт ярышлары оештыра – Әстерхан өлкәсе 18 еллык Татарстан сезоннарын беркайчан да онытмаячак.

Студент чорының романтикасы инде шактый еллар элек тәмамланса да, анда катнашучыларның күбесе өчен Түбән Иделгә ул сәяхәтләр студент чагындагы яшьлекнең иң якты һәм бәхетле хатирәләре булып кала.

Төзелеш отрядлары хәрәкәте яшьләр арасында хәзер дә популяр. Бүген «Россия студентлар отрядлары» оешмасы 240 меңгә якын егет-кызны берләштерә. 2023 елда республиканың студентлар төзелеш отрядлары хәрәкәте үзенең 60 еллыгын билгеләп үтәчәк. Авыл хуҗалыгы студент отрядлары да Яңа ел алдыннан бәйрәм итте, аларның ярты гасырлык юбилее булды. Казан дәүләт медицина университетында, яшьлек дуслары – студентлар төзелеш отрядлары ветераннары белән очрашу һәм «Татарстан» журналы белән үз хатирәләрен уртаклашу өчен, кайчандыр студент булган апа-абыйлар җыелды.

Фото: Алсу Шакирова

* *«Юкка түгел, юкка түгелдер», Нәҗәр Нәҗми шигыре.*

Фирая Фәсхетдинова, Казан дәүләт педагогика институты:

ТӨЗЕЛЕШ ОТРЯДЫ – ҺӘРКЕМ БЕР-БЕРСЕНӘ ЯРДӘМ ИТӘ ТОРГАН ЗУР ГАИЛӘ УЛ

– 19 яшемдә, әле япь-яшь кыз чагымда, эләктем мин төзелеш отрядына. Беренче сәфәрем Молдавиягә булды – төче чия, слива, алма, груша, шәфталу, виноград җыярга бардык, ә икенчесендә инде Әстерхан өлкәсенә юл тоттык. Төзелеш отряды – бер зур гаилә ул, анда барысы да тату яши һәм бер-берсенә булыша.

Безнең төркем составында педагогика институты кызлары гына иде. Әлбәттә, безгә көчле ир-ат куллары һәрвакыт җитмәде: нәрсәдер төзәтергә, эшләтеп җибәрергә, корырга кирәк була бит. Ярый әле якында КАИ егетләре бар иде, алар һәрвакыт ярдәмгә килде.

Һәр көнне мәзәк хәлләр булып тора иде. Мәсәлән, дымлы эссе климатта черкиләр интектерде, аларның безелдәвеннән беркая да качып котыла алмыйсың. Ул тавыш көндез дә, төнлә дә җәфалады. Ә ничектер йокларга кирәк бит. Монда да безне егетләр коткарды, алар, сменалар арасында ял итәр өчен, төрле җәймә һәм марлядан чыбылдыклар ясау җаен тапты. Хәтерлим, өйгә кайткач та, черки безелдәгән тавыш әле бик озак колакта зыңлап торды.

Әлбәттә, без басу-кырларда гына эшләмәдек. Мәсәлән, педагоглар буларак, сезон дәвамында без җирле мәктәп өчен дәресләргә кирәкле уку-укыту материаллары әзерләргә өлгердек, андагы халык моның өчен озак еллар безгә рәхмәтле булды.

Төзелеш отряды миңа хәзер дә иң авыр хәлләрдән чыгу юлын бик җиңел табарга булыша торган искиткеч тәҗрибә бирде. Студентлар отрядында чыныгу узганнарның барысында да җаваплылык тойгысы канына сеңгәндер, дип уйлыйм.

Сергей Большаков, Чаллы (Брежнев) сәнгать училищесы:

ТӨЗЕЛЕШ ОТРЯДЫ – ГОМЕР БУЕ СИНЕҢ БЕЛӘН КАЛАЧАК КЕШЕЛӘР УЛ

– Төрлесе булды, әмма без ул вакытның яхшы якларын гына хәтерлибез...

Беренче тапкыр студентлар отряды белән 21 яшемдә Әстерхан өлкәсенә помидор, кыяр уңышын җыярга бардым. Шул вакытта ук командир булдым.

Аннары инде «Татарстан» штабы составында Әстерхан өлкәсенең безнең студентлар эшләгән барлык территорияләрен тикшерергә бардым: пляжлар, коену урыннары ачтык, җиһазларны, янгын куркынычсызлыгын тикшердек.

Бу бик күңелле һәм иркәле чак иде!

Эштән соң учаклар ягып, гитара белән җырлашып утырдык, төрле бәйрәмнәр һәм футбол чемпионатлары үткәрдек, хәтта колхозларга барып, концертлар да куеп йөрдек.

Беркөнне бик кызык хәл булды. Лагерьда алты уку йортыннан студентлар яши иде, безнең төркемдә сәнгать училищесыннан музыкантлар булгач, берсен быргычы итеп билгеләделәр. Һәр иртә ул безне быргы кычкыртып уятырга тиеш. Ахыр чиктә кемнедер бу шулкадәр туйдырган ки, быргыны бәдрәфкә батырган. Әлбәттә, аны соңыннан табып алдылар, юдылар. Ләкин быргычы безне инде бүтән алай уятмады.

Төзелеш отрядлары – искиткеч тәҗрибә һәм гомер буе синең белән калачак кешеләр ул. Без әле дә дуслыкны өзмибез, бер-беребезгә ярдәм итәбез, хәтта башка шәһәрләргә күченеп киткәннәр белән дә очрашабыз, шалтыратышабыз.

Зиннур Гәрәев, КДМИ:

ТӨЗЕЛЕШ ОТРЯДЫ – МИҢА ҖИТӘКЧЕ БУЛАРАК ФОРМАЛАШЫРГА ЯРДӘМ ИТКӘН ТӘҖРИБӘ УЛ

– Студентлар хезмәт отрядында сәфәрләрем саны белән рекорд куйдым – 10 тапкыр бардым мин! 1977 елдан Казан медицина училищесының линияле студентлар отряды, аннары «Коминтерн» җыелма отряды командиры, аннары «Татарстан» Россия студентлар отрядлары командасының куркынычсызлык техникасы буенча инженеры, соңрак янә «Татарстан» күчмә отряды командиры булдым... Ул елларда башта Молдавиядә, аннары Әстерхан өлкәсендә помидор, алма, груша, виноград, кавын-карбыз уңышын җыйдык.

Бу тәҗрибә миңа җитәкче буларак формалашырга, зур төркем белән эшләргә һәм үз-үземне тота белергә өйрәтте.

Беренче тапкыр 18 яшемдә бардым. Иң якты хатирәләремнең берсе – Идел култыклары һәм кушылдыклары аша узарга туры килгән автомобильләребезнең паромда төнге кичүе. Линия отрядлары командирлары һәм комиссарларының эше шулхәтле төгәл оештырылган иде! Исең китәрлек!

Мин ул вакытны сагынам. Әмма без, әлеге төзелеш отрядлары әгъзалары, бер-беребезне онытмыйбыз, ешрак очрашырга, ул чакларда ничек рәхәт булганын тагын бер искә төшерү өчен, бәйрәм һәм истәлекле кичәләр оештырырга тырышабыз.

Рәшит Байбиков, КДМИ:

ТӨЗЕЛЕШ ОТРЯДЛАРЫ ИЛНЕҢ БАРЛЫК ПОЧМАКЛАРЫНДА ДУСЛАР ТАБАРГА МӨМКИНЛЕК БИРӘ

– Студентлар төзелеш отрядына мин 1981 елда Буа медицина училищесының 1 нче курсын тәмамлаганнан соң эләктем. Алты ел эчендә бик күп тәҗрибә һәм истәлек-тәэсирләр тупланды. Һәр проект үзенчә кызыклы булды.

Өч ел Молдавиягә помидор һәм ташкабак җыярга бардым, беренче елны отрядның гади бер әгъзасы, ә чираттагы ике елда бригадир булдым. Аннары 1987 елда «Эскулап» отряды командиры вазифасында Тәтеш районының Олы Әтрәч авылында – мәктәп, ә 1988 елда Алтай крае Поспелиха районының Поспелиха авылында Мәскәү энергетика институтының Казан филиалыннан «Энергия» отряды белән бергә тимер-бетон эшләнмәләр заводы төзедек.

Ләкин без эшләп кенә калмадык. Тормыш кайнап торды: һәр кич дискотекалар оештырдык, фестивальләр үткәрдек.

Без һаман да бер-беребез белән дуслыкны саклап, аралашып торабыз. Быел, мәсәлән, монысы – студентлар төзелеш отряды белән бәйле җиденче чара. Төзелеш отрядлары илнең барлык почмакларында дуслар табарга мөмкинлек бирә.

Рәшит Байбиков, КДМИ. 1987–1992 елларда төзелеш отрядларының иң яхшы командиры. ВЛКСМ өлкә комитеты аны Болгариягә туристлык юлламасы белән бүләкли (1988 ел).

- Һичшиксез, бу тәҗрибә һәм җылы хисләр безнең белән гомерлеккә калачак...
Алексей Созинов, студентлар төзелеш отрядлары ветераны, КДМУ ректоры.

Алия Адиева, «Россия студентлар отрядлары» Бөтенроссия яшьләр иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлеге комиссары:

ТӨЗЕЛЕШ ОТРЯДЫНА ЭЛӘГҮ ӨЧЕН ЯШЬ ҺӘМ АМБИЦИЯЛЕ БУЛУ ДА ҖИТӘ

– 2023 елда республикабызда зур һәм әһәмиятле вакыйга көтелә – Татарстанның студентлар төзелеш отрядларына 60 ел тула. Шуңа күрә хәзер актив рәвештә төрле чаралар – студентлар хезмәт отрядлары ветераннарының очрашулары үткәрелә. Бу бик сөендерә, без ул кешеләрнең ярдәмен, аларның хезмәтебезне хуплануын тоябыз, димәк, дөрес юнәлештә барабыз.

Без әүвәлге буыннарның традицияләрен хөрмәт итү һәм саклау гына түгел, аларны арттырабыз һәм яңартабыз, яхшыртабыз да.

Хәзер төзелеш отрядлары кеше тормышының барлык икътисади тармакларына өлеш кертә: төзелеш, мәгариф (лагерьларда вожатыйлар), медицина (табиблар), сервис хезмәте күрсәтү һәм кунаклар кабул итү өлкәсе (хостеслар, барменнар, ашчылар), җитештерү (республиканың эре-эре заводларында), тимер юл (проводниклар отрядлары).

Безгә ничек эләгеп була? Моның өчен яшь һәм амбицияле булу да җитә. Барыгызны да студент отрядларының республика штабында көтәбез, адресыбыз: Тукай урамы, 58 нче йорт.

ШАЯН-ШУКЛАР ХЫЯЛЫ – БЕЗНЕҢ КИЛӘЧӘК

Без югары тизлекләр һәм турбулентлык дөньясында яшибез. 10–20 елдан соң аның нинди булачагын күз алдына китерү дә кыен. Ләкин өлкәннәр бик сак фараз кылганда, «ДжуниорЛайф» кино сәнгате мәктәбендә белем алучы малай һәм кызларның хыялларына чикләр юк! Иҗат эше аларны нәкъ әнә шуңа өйрәтә бит.

Теге яки бу арага гына түгел, хәтта заманнар аша күчеп йөри торган дроннар, робот-андроидлар, иҗат итү сәләтенә ия нейрочелтәрләр... Без, фиджитал мохиттә яшәүче кешеләр, ике чынбарлык – физик һәм цифрлы галәм чатында торабыз. 2035 елга рәхим итегез! Яңа һөнәрләр атласын ясаучы футуролог галимнәр киләчәк кешесе ия булырга тиеш сыйфатларны аерып күрсәткән. Системалы фикерләү, мультикультуралылык һәм билгесезлек шартларында эшли белү сәләте белән бер баскычка алар сәнгати иҗат осталыгын да куя. Әйе, киң колачлы, кыю, иҗади фикер йөртә белмичә торып, уңыш казану авыр булачак. Моңа өйрәнергә мөмкинме соң? «Әлбәттә!» – дип саный «ДжуниорЛайф» кино сәнгате мәктәбе директоры Елена Вальцефер.

– Без балалар иҗатын үстерү белән ун ел шөгыльләнәбез. Актерлык осталыгы һәм режиссура ярдәмендә балаларыбызда күзаллау, фантазия, үзенчәлекле фикерләү сәләте, әйләнә-тирә дөньяга игътибар тәрбиялибез. Күз алдыгызга китерегез әле: балалар чын кино мәйданчыгына эләгә һәм кино төшерү процессының төп катнашучысына әйләнә! Ә «Камера! Мотор! Башладык!» дигән сихри сүзләрне ишеткәч, аларның күзләре бөтенләй ялтырып-янып китә.

Фото: Анна Арахамия

КАМИЛ МӨБӘРӘКШИН, 7 ЯШЬ:

– Мин әллә кемнәр булырга теләдем, ә хәзер хыялларым төгәлләште һәм киләчәктә үземне яңгын сүндерүче актер итеп күрәм. Әйе, мондый һөнәр булыр дип ышанам! Берьюлы ике яки хәтта өч һөнәрнең берләшүе гадәти күренеш булачак. Мин «ДжуниорЛайф» кино мәктәбендә төшәргә бик яратам, ә киләчәктә янгын сүндерүчеләр турында чын вакыйгаларга нигезләнгән фильмны үзем төшерергә хыялланам. Мин шулай ук гаиләм турында да кино төшерәчәкмен, аеруча сеңелем Диана турында, чөнки ул шундый кызык. Сүз уңаеннан, аның белән бергә эшләячәгебезгә ышанам һәм бу бик шәп булачак! Киләчәк якын, һәм андагы һәрнәрсә безнең үзебезгә бәйле.

ВЛАДИСЛАВА ИГНАТЬЕВА, 12 ЯШЬ:

– Кешеләрнең башка планеталарны үзләштерә башлавына ерак калмады. Галактикалар арасында сәяхәт – безне андый нәрсәләр инде якын киләчәктә көтә. Киләчәктә, һичшиксез, күп нәрсәне роботлар алыштырачак – алар безнең өчен бик күп эшләрне башкара башлаячак. Кешеләрнең гаджетларга һәм башка виртуаль уенчыкларга табынулары бераз моңсу да булып куя. Асыл кыйммәтләрнең алышынуы, чын тойгыларның, хис-кичерешләрнең җитешмәве кызганыч. Мин ясалма интеллектның безгә медицинада, сәнәгатьтә, фәндә ярдәм итүен телим... Ләкин ул барыбер дуслыкны, мәхәббәтне алыштыра алмый, чын җанлы кино һәм театрны, музыка һәм сынлы сәнгатьне дә. Киләчәктә игелекнең күбрәк булуын телим. Мин шулай булыр да дип ышанам!

ИЛЬВИНА МӘҖИТОВА, 7 ЯШЬ:

– Киләчәктә режиссер да, видеооператор да буласым килә. Динозаврлар, зур очар аждаһалар, чит планета роботлары һәм кылыч тешле металл юлбарыслары булган яңа эпоха турында фантастик фильм төшерергә хыялланам... Сюжеты бик мавыктыргыч булачак! Мәсәлән, бу затларның үзләренең гомер ташлары саклана торган сарайны ничек саклавы, аларның бер дөньядан икенчесенә күчеп йөри алуы турында.

ТИМУР ТАҖИЕВ, 11 ЯШЬ:

– Киләчәктә кешеләр берьюлы ике планетада яшәр, дип уйлыйм, аларның берсе колонизацияләнгән Марс булачак. Мин анда яңа дөнья коруда бик шатланып катнашыр идем! Ә кино сәнгате күләмле голографик яки виртуаль сурәтләр юнәлешендә үсеш алачак, бу очракта телевизор кирәк түгел, ә тамашачы турыдан-туры вакыйгаларның эчендә кайнаячак. Мин сюжет үсешенең төрле вариантлары булган фильмнар чыга башласын иде, дип хыялланам. Ул вакытта хәтта берничә тапкыр каралган фильм да көтелмәгәнчә тәмамланып, гаҗәпкә калдырырга мөмкин!

PRESSA

КАМИЛЛА КӘЛИМУЛЛИНА, 13 ЯШЬ:
– Мин танылган актриса яки җырчы булырга телим. Миңа Көньяк Корея мәдәнияте, аларның ризыклары һәм музыкасы ошый. Бу илдә бик матур, кешеләре игелекле, киләчәктә мин шунда яшәргә теләр идем. JYP Entertainment яки Big Hit Music кебек музыка компанияләрен күрергә хыялланам. Мин әкренләп үз максатыма таба барам, бу юлда туктамыйм һәм хыялымны, һичшиксез, чынга ашырырмын, дип ышанам.

АДИЛӘ ТӨХВӘТУЛЛИНА, 10 ЯШЬ:
– Киләчәкне болай күзаллыйм: ул чакта машиналар җирдән йөрмәячәк, ә күктән очачак. Театрлар – заманчарак, йортлар – күпкә биегрәк, ә мәктәпләр иркенрәк һәм матуррак булачак. Бөтенләй яңа кием стиле, башка гаджетлар һәм смартфоннар барлыкка киләчәк. Дөнья тулысынча үзгәрәчәк һәм ул алга киткән генә түгел, яхшырак та булачак.

АЛИНӘ ШӘРӘФЕТДИНОВА, 10 ЯШЬ:
– Беренче сыйныфтан ук мин француз һәм инглиз телләрен өйрәнәм, тел конкурсларында катнашам һәм алдынгы француз мода йортларында кием дизайнеры булырга хыялланам. Мин ясалма интеллект белән идарә ителәчәк кием ясарга телим. Күз алдыгызга китерегез: сез матур блузка киюгә, үз-үзегезне бөтен дөньяны ялап алырга әзер итеп тоясыз! Ясалма интеллект һәм кием эченә урнаштырылган чиплар ярдәмендә әйбер үз хуҗасы көткән сыйфатларны ала. Сатып алучылар мондый киемнең өстенлекләрен бәяләр, дип уйлыйм. Мин планетадагы барлык кешеләрнең бәхетле булып, уңайлы шартларда яшәвен телим.

ЭЛИНА ХӘМИТОВА, 10 ЯШЬ:
– Минем киләчәгем – елмаюлар яши торган дөнья. Җирдә матур шәһәрләр бик күп, ә андый гүзәл калалар башка планеталарда да төзеләчәк. Барысы да бәхетле булып, бер-берсенә шатлана-шатлана кунакка очып барачак!

СӘЙДӘ МОСТАФИНА, 7 ЯШЬ:
– Төймәгә басасың да кыштан җәйгә күчәсең һәм кире кайтасың! Бөтен кеше игелекле һәм бәхетле булган киләчәкне әнә шундый итеп күрәм. Транспорттан мини-самолетлар гына калачак. Кибетләр зур, матур булачак, ә аларның робот хезмәткәрләре табигый һәм файдалы ризык кына сатачак. Һәм безгә елмайган өчен бонуслар да язачаклар.

МАРИЯ ЧИНИЛКИНА, 10 ЯШЬ:
– Киләчәктә машиналар вертолетлар кебек очып йөриячәк, җирдә бөкеләр булмаячак. Экология яхшырачак, планетабыз химик пычранудан һәм калдыклардан иза чикми. Эштә кешеләргә роботлар ярдәм итәчәк. Ул яңа дөньяда мин табиб яки дизайнер булачакмын.

ТАИСИЯ ПСТЫГИНА, 10 ЯШЬ:
– Мин «Шкодники» киножурналында төшәргә бик яратам. Киләчәк киноиндустриясе тагын да серлерәк булыр, дип уйлыйм. Фильмнарны һич тә гадәти булмаган урыннарда төшерәчәкләр, чөнки кешеләр моның өчен инде хәзер үк космоска очты бит! Бәлки, кино төшерү вакытында режиссер артында очып йөреп, аның командасы буенча төшерә башлый торган очар видеокамера уйлап табарлар. Мин үземне актриса итеп күзаллыйм. Джунглида, ә бәлки Антарктидада да төшәргә хыялланам. Яисә тышкы яктан кечкенә йортка охшаган, ә эчтән биек түшәмле, бик иркен бина булган берәр серле бункерда.

ЕВГЕНИЙ ГЕРАСИМОВ, 2 ЯШЬ:
– Хыялланыр һәм ерак киләчәк турында сөйләр өчен, бик кечкенә әле мин. Тик шулай да инде ике тапкыр балалар киносында төштем!

НАДИЯ ГЫЙМАДИЕВА, 13 ЯШЬ:

– Мин «ДжуниорЛайф» кино сәнгате мәктәбен, уйнап, үз теләк-хыялларыңны чын кебек тоеп-яшәп карарга мөмкинлек биргәне өчен яратам. Хәтта иң фантастик киләчәкне дә! Ясалма интеллект – менә нәрсә 10–15 елдан соң иң кирәк һәм хәтта иң гадәти нәрсәгә әйләнәчәк. Минем медицина өлкәсендәге эшем дә шуның белән тыгыз бәйләнгән булачак.

АЛЕКСАНДР СӘИДОВ, 8 ЯШЬ:

– Киләчәкнең якты булыр, дип ышанам. Кешеләр бөтен ялыктыргыч эшне машиналарга тапшырачак, ерак космосны өйрәнү белән актив шөгыльләнәчәк, ә мин бик теләп төрле планеталар буйлап сәяхәт итәчәкмен. Минем атаклы футболчы булу хыялым бар. Һәм, бәлки, мин каядыр Марста уйнаганда, «Алтын туп» та алырмын. Кызганыч, әлегә вакытлар аралыгында күчеп йөреп булмый, һәм киләчәкнең нинди булачагын тикшерә алмыйсың. Ләкин алда мин чишәргә тиешле бик күп серләр булуы да бик шәп!

МАРИЯ ПОЛЯКОВА, 10 ЯШЬ:

– Мин әле киләчәк турында ныклап уйлаганым юк. Ләкин мин хәзер нәрсә теләгәнемне беләм. Дөньяда сугышлар булмасын. Кешеләр бер-берсе белән әрләшмәсен. Ә шәхсән үзем «Хыяллар утравы» дигән күңел ачу паркына бару турында хыялланам. Без җәен әни белән анда булдык инде, тик мин анда тагын бер тапкыр баруны зарыгып көтәм. Мин әле сеңелем булуын да телим. Минем ике апам бар, үземнең дә апа буласым килә.

РАНЕЛЬ ЛУКИН, 11 ЯШЬ:

– Үземне кораб капитаны итеп күзаллыйм. Ул кораб заманча һәм уңайлы итеп эшләнгән атом бозваткычы булачак. Киләчәктә Арктика аша зур диңгез юллары узачак. Минем корабта хайваннар турында документаль фильмнар төшерелəчәк. Бу исә Арктиканың табигый байлыкларын сакларга ярдәм итәчәк һәм хайваннарны юкка чыгудан, аларны кырып бетерүдән коткарып калачак. Мин ерак киләчәк турында уйларга яратмыйм, ләкин ул хәзерге көнгә караганда күпкә яхшырак булыр, дип уйлыйм.

ИНСАФ МИНГӘРӘЕВ, 9 ЯШЬ:
– Киләчәк миңа бик якты, рәхәт булып тоела – оча торган машиналар, йөртүчесез һәм иркен җәмәгать транспорты... Анда үземне уңышлы эшмәкәр итеп күрәм – минем бик зур уенчык кибетләре челтәре булачак!

АНАСТАСИЯ ГРЯЗНОВА, 14 ЯШЬ:
– Мин инде берничә ел «Оперение» театр студиясендә шөгыльләнәм, анда без курчаклар белән эшләргә өйрәнәбез һәм хәтта спектакльләр дә куябыз. Курчак йөртүче – авыр, әмма бик кызыклы һөнәр. Һәркем дә курчак театры остасы була алмый, тик күңел сәхнәгә тартылса, талант һәм хезмәт сөючәнлек булса, барысына да ирешергә мөмкин. Мин әле булачак һөнәремне сайламадым, ләкин курчаклар белән эшләү миңа бик ошый. Һәрхәлдә, тормышымның театр белән бәйле булуын телим.



АЛЬМИРА ШӘКҮРОВА, 9 ЯШЬ:
– Кешеләр бик күп яңа әйберләр уйлап табачак. Мәсәлән, программалаштырып була торган шәмнәр. Аларда ялкын хайваннар, чәчәкләр, фигуралар, кеше портретлары, хәтта төрле илләрнең һәм континентларның матур пейзажлары һәм истәлекле урыннары рәвешендә янып торачак. Мин уйлап табучы булырга һәм кешеләрнең тормышын кызыклырак, файдалырак һәм төсләргә байрак итәргә теләр идем!

АЛАНА ШӘКҮРОВА, 6 ЯШЬ:
– Кешеләр салават күперенә менәргә һәм аның буйлап сәяхәт итәргә өйрәнәчәк. Галимнәр хайваннарның яңа төрен – бермөгезләрне уйлап чыгарачак. Аларны йорт хайваннары кебек өйдә асрарга мөмкин булачак. Шулай ук һәр өйдә игелекле йорт ияләре дә яшәячәк һәм аларга ярдәм итәчәк. Киләчәк балалары яңа шәһәрләр төзиячәк: Шоколанджелес, Зефирест, Мармеланд, Карамелия. Анда бөтен йортлар да, әйберләр дә тәм-томнан торачак.

СОФИЯ ЕЛЕСИНА, 12 ЯШЬ:
– Театрлар бик үзгәрәчәк – алар тагын да матуррак һәм зуррак булачак. Спектакльләрдә гадәти булмаган һәм шәп эффектлар куллана башлаячаклар. Мин инде танылган актриса булам һәм сәхнәдә чыгыш ясыйм – киләчәгемне әнә шулай күзаллыйм. Күп эшләп, тәҗрибә туплап, хаталарны азрак җибәрергә тырышачакмын.

НУРИЯ ЕЛЕСИНА, ИНГЛИЗ ТЕЛЕ УКЫТУЧЫСЫ:
– Хәзер киләчәкне планлаштыру кыен, ләкин мин нәрсә теләгәнемне төгәл беләм: тулы метражлы фильмда яки сериалда төшәргә! Үз балаларыма якты киләчәк – сайлаган һөнәрләрендә үз-үзләрен табып, бәхетле озын гомер итүләрен телим.

«ДжуниорЛайф» мәктәбенең төп проекты – «Шкодники» (шук-шаяннар – ред. иск.) дип исемләнгән җылы рухтагы гаилә скетчкомы. Бу юмористик киножурнал кино сәнгате дөньясында чын эксклюзив булып тора, чөнки кыска метражлы балалар киносы – бүген бик сирәк күренеш.

Ике-өч минутлык сериянең нигезендә – төп геройлары балалар булган мәзәк хәлләр, шаяртулар. Һәм бу яшь актерлар «үзләре өчен генә» дип төшми, «Шкодники»нең серияләре киштәләрдә тузан җыеп ятмый, ә телевидениедә күрсәтелә, республика кинотеатрларында прокатта бара. Аларның даны Канныга кадәр барып җитте! «Уен фильмы» номинациясендә DREAM FILM FESTIVAL Халыкара балалар киносы һәм телевидениесе фестивале (Канны, Франция) лауреаты дипломы – «ДжуниорЛайф»ның берничә дистә бүләгеннән берсе генә әле. Мәктәпнең офыкта күренгән яңа максаты да бар – балалар киносы һәм телевидение өлкәсендә «ТЭФИ- KIDS» Россия милли премиясен алу.

Ун ел эчендә «Шкодники» ярдәмендә меңнән артык бала үз мөмкинлекләренең чикләрен киңәйтә алды. Алар актерлык осталыгын үзләштерүгә тәүге адымнарын ясады, үзләрен профессиональ кинода сынап карады, фантазиягә ирек бирде, кыенсынмаска, кыю булырга өйрәнде, үз-үзенә ышаныч тапты. Ә кем өчендер «ДжуниорЛайф» мәктәбе үз хыялын тормышка ашыру өчен төп нигез – актерлык карьерасындагы беренче баскычка әйләнде.

Бу «шук-шаяннар»ны яхшылап хәтердә калдырыгыз! Бәлки, әнә шул 2035 елда сез аларны атаклы сценарий осталары һәм интерактив кино актерлары, күренекле хисләр дизайнерлары һәм виртуаль дөнья архитекторлары арасында танып алырсыз. Даһи Айзек Азимов: «Бу мизгел – хәзерге заманның күз алдыбызда киләчәккә әверелеп барган вакыты ул», – дип бик дөрес әйткән бит.

ТАТМЕДИА

ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРГА ЯЗЫЛГАН ӨЧЕН КАР КӨРИ ТОРГАН ҖАЙЛАНМА, ТЕЛЕВИЗОР ҺӘМ БАШКА БҮЛӘКЛӘР

Бүләкләр 2023 елның 9 февралендә уйнатылачак

1 ЯЗЫЛ

«ТАТМЕДИА» АҖнең бер газета һәм бер журналына языл (акциядә катнашучы басмалар белән tatmedia.ru сайтында танышып була)

2 ҖИБӘР

«Акция» билгесен куеп, язылу квитанцияләренең копиясен безгә 21 гыйнварга кадәр җибәр (телефон номерыгызны язарга онытмагыз!). Адрес: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3 ОТ

телевизор, электр иттарткыч, электрогриль һәм башка бүләкләр от. Иң зур бүләк – кар көри торган җайланма!



Әлеге чараны оештыручы, кагыйдәләре, бүләкләр саны, уйнату вакыты һәм урыны буенча мәгълүматны tatmedia.ru. сайтында белә аласыз. Акция 2022 елның 22 октябреннән 2023 елның 20 мартына кадәр уздырыла.
Реклама. Яшь чикләве 16+

ӨЙ САЛУНЫҢ НИЕ БАР...

Руфия Фазылова

Фоат Закиров тудырган матурлыкны күргәч, мәгълүм шул гыйбарә искә төште. Бер йортны ул күп дигәндә бер айда җиткезә. Ә чана, арба, мотоцикл ясау өчен аңа берничә көн дә җитә. Әлбәттә, сүз бу әйберләрнең кечерәйтелгән күчермәләре турында бара. Останы теләсә нинди агач «тыңлый»...

БАЛАЧАКТАН ХИРЫС

Фоат абый агач сыннарны бүген фатирында ясый, ә чын остаханәсе җәйге бакчасында икән. Шуның өчен дә эшнең кызу вакытына туры килмәдек: оста шәһәр фатирына күченгән.

– Бакчада мин зур әйберләр эшлим: бизәкле эскәмияләр, өстәлләр, агач чатырлар, бакча фигуралары, – диде Фоат абый. – Анда станогым бар. Ә фатирда исә нигездә пычак белән генә эш итәм, шуның өчен кышын ваграк эшләнмәләргә алынам.

– Йорт, мәчет макетларын да пычак белән ясыйсызмы? – дим.

– Әйе, пычак белән. Ул бит вак детальләрдән җыела.

Фоат абый тумышы белән Саба районының Сабабаш авылыннан. 1977 елдан бирле Чаллыда яши. Җәмәгате Шәргыя апа белән Гөлнар һәм Рания исемле ике кыз тәрбияләп үстергәннәр. Бүген ул оныклар белән мәш килә: аларны мәктәптән алып кайта, төрле түгәрәкләргә илтә. Җитмеш бер яшендә дә шәһәр урамнарында йөрүне кыенлыкка санамый.

Оста хезмәт юлын Саба урман хуҗалыгында башлаган. Урман эше белән кечкенәдән таныш була ул.

– Агач эшенә мәхәббәт шул чагында барлыкка килдеме? – дим.

Фото: Юлия Кузнецова

– Юк, кечкенә чагында ук агач ышкылаганым истә. Мәрхүм этиебез бик оста иде, мин аннан күреп өйрәндем. Әлбәттә, ул мондый вак әйберләр белән утырмады: бура бурап өй салу, тәрәзә рамнары ясау – тормышны алып бару өчен эшләде. Ләкин пычкы, балта тотарга этидән өйрәндем дип әйтә алам. Аннары армиягә киткәч тә агачтан төрле әйберләр ясарга туры килде. Архангельск шәһәрендә – Плесецк космодромында хезмәт иттем. Шулай берсендә солдатларга инструктаж үткәрер өчен космодромның макеты кирәк булган. Командир миңа мөрәҗәгать итте. Һич авырсынмыйча макетны ясап бирдем. Аңа барысының да исе китте инде.

Фоат абыйның алтын куллы икәнен әнә шул чагында күреп алалар. Соңыннан нинди агач эше бар, барысын да аңа кушалар. (Сер итеп кенә әйтте: хәтта командир аны өенә дә эшләргә алып кайта.)

Фаот абый туган өенең макетын ясаган. Ул аны иң кадерле урында саклый. Макетның түбәсе алына да. Анда өстәл, карават, шкафлар – барысы да балачагындагы кебек.

– Без бәләкәй чакта өй каршында менә шундый сыерчык оясы бар иде, – дип күрсәтте Фоат абый эшен. – Безгә аны эти ясап биргән иде. Мин менә нәкъ шуның кечерәйтелгән вариантын эшләдем. Шуларга караган саен риясыз балачагым искә төшә...

ШАТЛЫКТАН ЕЛАУ РӘХӘТ

Фоат абый кул эшләрен сатмый. Дөресрәге, ул аларны сатуга дип ясамый. Әйе, заказ белән эшләгән йорт макетлары өчен акча бирәләр үзенә, анда да сорап алып түгел.

– Акчага эшли белмим, – дип елмайды оста.

Фоат абый эшләренең төгәл санын әйтә алмады, биш йөз, алты йөз, бәлки җиде йөзгә үк тулгандыр. Аларның бик күбесе бүләккә таралып беткән. Төрле күргәзмәләргә дип тә эшли, күбесе шуннан да кайтмый икән.

– Минем өчен үзем ясаган әйберләрне бүләк итүдән дә зур ләззәт юк, – ди Фоат Закиров. – Ул бит җан җылысы кертеп эшләнгән әйберләр. Кешеләрнең сөенгәнен күреп мин дә елмаям. Кайткач яңадан нинди дер җиһаз ясарга янә бер этәргеч була миңа.

Фоат абыйның күңелендә бер хатирә яши. Аны сөйләгәндә әле дә тамагына төер тыгылды. Чаллы шәһәрендә узган чираттагы бер күргәзмәгә Фоат абый бала арбасы алып бара. Имәннән ясалган, көпчәкләре дә булган чын арба. Күргәзмәгә килгән бик күп кеше аңа сокланып, гаҗәпләнеп карый. Шулар арасында бер ханым да була. Кыяр-кыймас кына ул остага: «Сатыгыз әле миңа, кызым бик ошатты», – ди. Фоат абый баш тарта: «Гафу итегез, мин бу әйберләрне сатмыйм», – ди. Шуннан теге ханым күңелсез генә китеп бара.

– Унбиш-егерме минут уздымы икән, теге ханымны күреп алдым, – диде Фаот абый. – Гарипләр арбасында бер кызны этеп бара. Йөрәгем жу итеп китте. Минем шунда гына башыма барып җитте – теге уенчык арбаны авыру кызы өчен сораган икән бит! Арбамны тоттым да артларыннан йөгердем. И-ии, теге кыз сөенде инде. Әни кеше исә шатлыгыннан елап ук җибәрде. Минем дә күзләр яшьләнде. Алдан ук ана кешенең шушы балага сорагаларын белсәмме...

ИМАНЛЫ ГОМЕР

Фоат абый эшләреннән тулы бер композиция ясый. Татар авылы ишегалдында ни булган, барысын да тәфсилләп сурәтли: уфалла арбасы, ат арбасы, ат чанасы һ.б. Тагын мотоцикл да матур килеп чыга: агач көпчәкләренә, вак детальләренә кадәр бар. Соңгысын ир-атлар аеруча ярата икән. Аларны ул бүләккә дип әллә ничә тапкыр ясаган.

Фоат абый намазда, мәчеткә йөри. Шуның өчендер дә Аллаһ йортларын аерым бер ләззәт белән ясый.

– Мәчетләрнең макетын бүләк итәргә ярата́м, – ди оста. – Чаллының «Нур-Ихлас», Аксубай районының Яңа Ибрай, Яшел Үзән районының Кече Шырдан, Теләче районының Җөри авыллары һәм туган авылымның ике мәчетен ясадым. Аның берсе Сабабашта, берсе үземдә саклана.

– Үземне белгәннән бирле, әти безгә агачтан төрле әйберләр ясап бирде, – дип сүзгә кушылды Фоат абыйның олы кызы Гөлнар. – Бакчада еш кына төрле бәйрәмнәр, конкурслар уза бит. Хәтерлим, агачтан төлке белән карга сыны ясап бирде. Аны лаклап, матурлап буяды да. Бакчага баргач, башта аны сатып алынган уенчык дип уйладылар. Әти ясап бирде дигәч барысы да шаккатты! Шуннан инде берәр бәйрәм, конкурс булса, әтине эшкә җигә идек. Мәктәптә укыганда да шулай булды.

Гөлнар белән Рания бүген Чаллы шәһәрендә балалар бакчасында эшли. Берсе психолог, икенчесе музыка җитәкчесе. Иң кызыгы, кызлар бүген дә әтиләреннән агач эшләнмәләр ясата, чөнки эш буенча кирәк икән.

– Әти безнең уң кулыбыз, – диде Гөлнар. – Берәр ачык дәрес оештырырга, семинарда катнашырга кирәк булса, заказ белән теге яки бу предметны эшләтәбез. Психолог буларак миңа аеруча андый әйберләр кирәк. Эш кабинетымда барысы да әти ясаган кирәк-яраклар дияргә мөмкин. Интернеттан карыйм да: «Әти, менә моны ясап буламы?» – дип сорыйм. «Була», – дип сабыр гына елмая ул. Әти гомергә сабыр булды. Ул безгә беркайчан кул күтәрмәде, хәтта кычкырып эндәшкәнен дә хәтерләмим. Бәхетле балалар булып үстек, Аллага шөкер. Бүген дә төп таянычыбыз әти. Ипле, нурлы кеше ул безнең.

ОСТАЗ

Балалар турында сүз чыккач, әйтми мөмкин түгел – Фоат абый шактый еллар Чаллы балаларын агач эшенә өйрәткән. Лаеклы ялга чыккач, Мулланур Вахитов исемендәге 2 нче татар гимназиясенә аны балта остасы итеп алалар. Мәктәп җиһазларын карап, төзәтеп торырга тиеш була ул. Озакламый аның сәләте турында мәктәп директоры белеп ала һәм остадан бизәкле сигез эскәмия ясап бирүен сорый. Фоат абый аны бер авырсынмыйча эшли. Шуннан исә белем йорты

каршында татар ишегалды пәйда була: ат арбасы-чанасы, уфалла арбалары, агач эш кораллары... Болар барысы да – Фоат абыйның хезмәт җимешләре.

– Ул ишегалдын чаллылылар бик яратты, – диде Фоат Закиров. – Балалары белән йөрергә чыккан яшь әниләр дә кереп фотога төште. Бүген дә ул әйберләрнең кайберләре исән әле. Ә иң мөһиме – мәктәп балаларында агач эшенә кызыксыну уянды. Мине күргәч: «Абый, безне дә өйрәт әле», – дип киләләр иде. Мин аларга барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп, эшләп күрсәтә идем.

Сигез ел шулай эшләгәннән соң, Фоат абый Чаллының 2 нче татар гимназиясеннән китә. Пандемия башлангач, берничә ай өйдә утырырга карар кыла. Аннан инде мәктәп җитәкчелеге үзгәрә. Ул бүген өендә генә иҗат итә.

...Оста эшеннән билгеле, ди халык. Фоат абый ясаган әйберләргә карыйсың да шаккатасың: бернинди махсус белеме булмаган, гомер буе башка юнәлештә хезмәт куйган кеше әнә шундый матурлык тудырсын әле! Күкләр биргән сәләт шушыдыр ул.

ТАТМЕДИА

ТАТМЕДИА ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРЫ ҺӘМ ОТКРЫТКАЛАРЫ — МАРКЕТПЛЕЙСЛАРДА

shop.tatmedia.ru

WILDBERRIES

KazanExpress

OZON

Я Маркет

«ТАТМЕДИА» АҖ. Адрес: 420066 Казан ш., Декабристлар ур., 2. ГРН 1071690057834

16+
Реклама

ИГЕЗӘКЛӘР СҮЗСЕЗ АҢЛАША

Руфия Фазылова

Лениногорск районының Яңа Иштирәк авылында сигез пар игезәк бар. Суы шундыймы, һавасымы, тәгаен генә әйтә алмадылар. Ә менә Нурсинә һәм Тәбрис Гаффановлар гаиләсендә бер-бер артлы ике тапкыр игезәкләр туа: Айрат белән Азат, Наил белән Наилә.

Туганнар бүген кайда, ничек яши? Бер-берсенә нинди мөнәсәбәттә? Яңа Иштирәккә баргач әнә шундый кызыклы язмышлар белән танышып кайттык.

АЙРАТ БЕЛӘН АЗАТ

Ни аяныч, Тәбрис абый белән Нурсинә апа исән түгел икән. Ике ел элек башта эти кеше, аннан Нурсинә апа бакыйлыкка күчкән. Авылның алдынгы уңган гаиләсе саналган алар. Гаилә башлыгы колхозда хисапчы, ә Нурсинә апа сыер савучы булып эшләгән. Гаффановлар җиде бала – дүрт кыз, өч малай тәрбияләп үстергән. Шуларның өчесе бүген Яңа Иштирәктә гомер итә.

Бу гаиләдә беренче пар игезәкләр 1972 елда туа. Аңа кадәр Тәбрис абый белән Нурсинә

Фото: Александр Ефремов

апаның өч кызы була. Берьюлы ике малай тугач, ата кешенең башы күккә тия – нәсел дәвамчылары бит! Әлбәттә, малайлар моны үзләре белми, үсә төшкәч апалары шулай сөйли.

– Хәтерлим, игезәкләрне карарга өйгә кем генә килмәде! Бер тамаша инде, – диде Гаффановлар гаиләсендә иң өлкән бала Гөлфия Зәйниева. – Аларның матурлыклары... Игезәк балаларын тапкач та, әни ике айдан эшкә чыкты. Йодрык кадәрле ике малай күбрәк минем җаваплылыкка калды. Аларга кемдер зур бишек ясап биргән иде. Әнә шул бишектә тирбәтеп үстердек. Аллаһның рәхмәте, энеләребез тыныч булды. Бер дә елап аптыратканнарын белмим.

Азат белән Айрат кечерәк чагында ике тамчы су кебек охшаш була. Еш кына аларны әниләре дә бутый. Шуның өчен ул аларга: «Азат, Айрат», – дип кенә эндәшкән.

– Мәктәптә укытучылар безне аермады, – дип көлде Айрат абый. – Мин математика, Азат гуманитар фәннәр буенча көчлерәк идек. Өй эшләрен эшләгәндә, җавап биргәндә укытучыларны еш кына алдадык.

– Ә телгә кайсыгыз үткенрәк? – дим.

– Алай аерып кына әйтә алмыйм инде, мине үткенрәк диләр...

– Айрат, Айрат, – дип сүзгә кушылды безнең әңгәмәне дикъкатъ белән тыңлап торган Гөлфия апа. – Кечкенә чагында бөтен серне ул чишә иде. Армиядән дә хатны бары Айрат язды.

– Красноярскида хезмәт иттек, – диде Айрат абый. – Игезәкләрне үзләре теләмәсә аермыйлар бит. Хәрби хезмәт юлын бергә уздык. Бер өйгә булгач, икебез дә хат язмадык инде. Азат янда утырып хатны тикшереп торды.

Бүген игезәк туганнар Яңа Иштирәктә гаиләләре белән яши. Берсе төп нигезгә, икенчесе бабасыннан калган җиргә йорт салган. Хуҗалыклар төрле булса да, бөтен эшләре уртак икән. Башта берсендә, аннары икенчесендә эшлиләр. Иң кызыгы – ике килен, игезәк туганнарның хатыннары да бик тату.

– Мин өйдә булмыйча, берәр эш килеп чыкса, җәмәгатем Азатка шалтырата, – диде Айрат абый. – Шалтыратмасалар да керәбез. Аларның өйдә түгеллеген белсәм, малларын карап чыгам. Азат безнекен шулай итә. Синеке, минеке юк инде бездә.

– Без аларга шаккатабыз: күз карашларыннан аңлашалар, – диде Гөлфия апа. – Ничек шулай ул, ис китә. Үскәндә дә мин аларның ызгышканнарын белмим, югыйсә малайлар бит. Сигез-тугыз яшьләрендә атка атланып көтү көттеләр. Ат иярләргә буйлары җитмәгәч, чиләк куялар иде. Аннары, энигә дә гаҗәпләнәм: шул зур көмәне белән дә фермада эшләп йөрде. Әле таналар өйрәтте. Ничек сыерлар сөзмәгән, типмәгәндер. Шулкадәр эшләп йөреп тә, малайларны вакыты җиткәч кенә тапты. Сәламәтлеге нык булган!

ХӘЙРУЛЛИНА ЛИЛИЯ ИЛСУР КЫЗЫ, РЕСПУБЛИКА КЛИНИК БАЛАЛАР ХАСТАХАНӘСЕ ОНКОЛОГЫ, ЮГАРЫ КАТЕГОРИЯЛЕ АКУШЕР-ГИНЕКОЛОГ:

– Игезәкләр (шул исәптән өч бала да) утыз йөклелекнең берсендә очрый. Соңгы елларда игезәкләр туу очрагы күзгә күренеп арта. Бу күбрәк ЭКО нәтиҗәсе дә. Әлбәттә, гадәти ысул белән дә дөньяга киләләр. Соңгысына нәселдәнлек факторына бәйле. Димәк, әти яки әни ягыннан игезәкләр булган. Шулай ук әнинең яше дә (өлкәнрәк булса) игезәкләр туу мөмкинлеген арттыра.

Хатын-кыз карынында ике йә өч бала йөртә икән, табиблар аларга тагын да игътибарлырак була, чөнки организмга авырлык бермә-бер арта. Гадәттә, андый очракларда балаларны ярып алалар. Карынында игезәк бала йөрткән ана күп очракта кырык атнага кадәр түзми, иртәрәк бәбили. Игезәкләр өчен 35-36, ә өч игезәк өчен 32 атна норма санала.

Әйе, бүген медицина көчле: бер килога кадәрле туган сабыйларны да аякка бастыралар. Ләкин бу бик четерекле эш. Җитлекмичә туган сабыйларның сулыш алу юллары, башка әгъзалары формалашып бетмәгән була. Шуның өчен булачак ана йөклелек чорына бик җитди карасын иде. Гомумән, бу барлык йөкле хатын-кызларга да кагыла.

НАИЛ БЕЛӘН НАИЛӘ

1978 елда Гаффановлар гаиләсендә тагын бер пар игезәк – малай белән кыз туа. Сабыйларга Наил һәм Наилә дип исем кушалар. Төпчекләрен алып кайтканда Нурсинә апага 35 яшь була. Игезәк малайларны күбрәк апалары үстерсә, малай белән кызны карау Айрат белән Азатка кала. Ни өчен дигәндә, гаиләдә алдан туган өч кыз инде буйга җитеп, әти-әни йортыннан чыгып китә.

Алда әйтелгәнчә, Айрат белән Азат тыныч холыклы, ә Наил белән Наилә шук бала булып чыга. Артларыннан карап кына өлгер! Әти-әни эштә чакта абыйлары энесе белән сеңлесен бер дә күздән ычкындырмый.

– Мәктәптә мин яхшырак укыдым, – дип балачагын искә алды Наилә. – Икенче класста безне Гөлфия апабыз укыта башлады. Диплом алып мәктәпкә эшкә генә кайткан иде. Апа Наил белән шактый чиләнде – укырга яратмый, шук. Аннары инде җайланды үзе.

– Игезәкләр бер-берсен тоя диләр, бу дөресме? – дим Наиләгә.

– Дөрес. Ике ел элек Наил җәмәгате белән юл һәлакәтенә эләкте. Шул көнне иртән үземне бик начар хис иттем. Бөтен гәүдәм яна, эч поша. Озакламый Наил шалтыратты. «Үлемнән калдык», – диде. Чир белән дә шул ук хәл. Беребез авырса, икенчебез дә авырый булып чыга. Арада мең чакрым ераклык, һәм менә шундый туры килү!

Наил бүген Себер якларында, Ханты-Манси автоном округының Покачи шәһәрендә гаиләсе белән яши, нефтьче. Наилә исә Лениногорск шәһәрендә төпләнеп калган, ашханәдә пешекчеләр бригадиры. Хисапчы дипломы булса да, Наилә икенче юлны сайлаган:

– Аралашырга яратам, – диде уңган ханым. – Кабинетта бикләнеп утыруны күз алдына да китермим. Ә монда мин көне буе халык арасында. Нефтьчеләрне ашатабыз. Көненә күпме кеше килә! Казанда узган Универсиадага, WorldSkills Russia эшче һөнәрләр чемпионатына барып, берәр ай эшләп кайттык. Килгән кунакларны сыйладык. Эшемне бик яратам инде.

– Игезәгең Наил белән сезнең дә мөнәсәбәтегез якынмы? – дим.

– Бик якын. Наилдән калышмаска тырышып, мин дә үткен булып үстем. Әлбәттә, еш күрешмибез, аралар бик ерак бит. Күбрәк шул телефон аша инде. Миңа калса, Айрат абый белән Азат абый бер-берсенә тагын да якынрак, алар гомерләре буена бер көн дә аерым яшәмәгән кешеләр. Аннары, алар бер карында яткан, игезәкләр, тоемлау тагын да көчлерәктер. Наил белән без ике карында үскәнбез. Шуның өчен дә беребез малай, беребез кыз. Апалар булгач, хатын-кыз серләрен хәзер күбрәк алар белән сөйләшәм. Ә кечкенә чакта Наил белән бөтен серләр уртак иде. Клубтан иртәрәк кайтсам, йокламыйча игезәгемне көттем. Әле аңа бәрәңге яки йомырка кыздырып тора идем. Аннары инде серләшәсең. Эх, кызык чаклар...

– Наиләбез – ут, бөтен эшне булдыра, – дип сеңлесен җөпләп куйды Гөлфия апа. – Ашсуга, җыр-моңга, оештыру эшләренә дә бик хирыс. Төпчек булгач, кияүләрне сыйлау аңа әләкте. Кайчан кайтсак та, өй җыештырылган, тәмле ризык пешкән булыр иде. Наил дә бик үткен безнең. Ул кечкенәдән атлар белән «җенләнде», Сабан туйларында ат ярышында беренчелекне бирмәде. Авылда калыр диген идек, шәһәрне сайлады.

Гаффановларның кайсы белән сөйләшсәң дә, әти-әниләрен телгә алмый калмый. Җиде балага гомер бүләк иткән Тәбрис абый белән Нурсинә апа ул-кызларын хезмәт белән тәрбияләгән. Нәтиҗәсе күз алдында – балалар тырыш, ә иң мөһиме туганлык җепләре нык бәйләнгән. Туган көннәр, бүтән бәйрәмнәр – барысы да җыелып кайта. Әти-әниләре бакыйлыкка күчсә дә, өйрәнелгән гадәт буенча бергә җыелалар...

P.S. Игезәк балалар үстерүнең рәхәте дә, михнәте дә зур. Моны үз башымнан кичкәнгә беләм: йоклап кына китәсең, берсе уяна, ашатып биләүгә саласың, икенчесе тавыш бирә... Нәтиҗәдә, төн буена ике-өч сәгать йокы кала. (Кайбер вакытта анысы да эләкми.) Ләкин иң гаҗәбе – ул авыр чаклар онытыла икән. Аннан инде игезәк балаларыңның ярыша-ярыша ашаганын күзәтергә, кочаклашып йоклауларын, бер-берсенә ярдәмләшеп дәрес әзерләгәнен күзәтеп ләззәтләнергә генә кала... Аның иң уңай ягы – әти-әнигә төрле җиргә йөгерергә кирәкми. Башта ике баланы җитәкләп бакчага, аннан мәктәпкә илтәсең. Өй эшләрен караганда да җиңел: берсе белмәсә, икенчесе ярдәмгә килә, бергә шунда аңлашалар. Теге мәгълүм мәкальдәгечә: «Бер баш яхшы, ике баш тагын да яхшырак».

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр /

акыллы гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Гаяз Исхакый **нинди** мирас калдырган

Чук һәм Гек исемнәре **нәрсәне** аңлата

Яңа елда **нинди** китаплар укырга була

Балтач авылында **нинди** музей ачылды

МИЛЛӘТ ЯЗУЧЫСЫ ГАЯЗ ИСХАКЫЙ

Илдус Заһидуллин

1904 елда фантастик эчтәлекле, ярым публицистик «200 елдан соң инкыйраз» китабы дөнья күрә һәм татар җәмгыятендә зур шау-шу уята. Китапның авторы татар дөньясында «беренче классик язучы-прозаик» буларак танылып килгән Гаяз Исхакый була. Әсәрдә тирән кризиска тарыган татар-мөселман җәмгыятенең ике йөз елдан бетүе тасвирлана.

Гаяз Исхакый 1878 елның 10 февралендә Казан губернасы Чистай өязенең Яуширмә авылында дөньяга килә. 5 яшьтән әнисеннән укырга өйрәнә, этисе мәктәбендә дин гыйлемен үзләштерә. 12 яшендә укуын Чистай мәдрәсәсендә дәвам итә, 1893 елда Казанның Күл буе мәдрәсәсенә күченә. Остазы Әхмәтһади Максуди биргән, Истанбулда нәшер ителгән китаплар аша төрек һәм Европа әдәбияты белән таныша башлый. Казан урамнарында элмә такталарны укып, үзлегеннән русча өйрәнә. Әхмәтһади Максуди белән Мөхәммәтзариф Әмирхан мәдрәсәсенә күчеп, мөгаллим булып эшли, аваз ысулы белән укыта.

Рус мәдәнияте белән кызыксынган 20 яшьлек егет 1898 елда Казан татар укытучылар мәктәбенә укырга керә. Аны тәмамлагач, Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә мөгаллим булып эшли. Яшь мөгаллимнең активлыгына түзә алмыйча, «Хөсәения» җитәкчелеге аны эштән җибәрә. Гаяз 1903 елның җәендә Казанга университетка укырга керергә дип кайта, ләкин этисе сүзен тыңлап, туган авылында мулла булып урнаша.

ИҖАДИ ЮЛ БАШЫ

Казанда ачлы-туклы яшәгән Гаяз, әдәби әсәрләргә гонорар яхшы түләнә дигән сүз ишетеп, иҗат белән шөгыльләнә башлый. Үзе беренче әсәрләренә төрек әдәбияты йогынтысы зур булуын билгеләп үтә. 1897 елны, нигездә, мәгърифәтчелек, үгет-нәсихәтчелек, мораль укуга корылган «Тәгаллемдә сәгадәт, яки Гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» хикәясен нәшер итә, «Бай угълы» повестен яза. 1900 елда «Кәләпүшче кыз» исемле хикәясе, «Өч хатын белән тормыш» повесте дөнья күрә. Аннан соң тәрҗемә итеп эшләнгән «Ике гашыйк» пьесасы (1902–1903) һәм «Очрашу, яки Гөлгыйзар» (1903) повесте дөнья күрә. Бу әсәрләр, кат-кат нәшер ителеп, Гаяз Исхакыйга мәшһүр «беренче классик язучы-прозаик» исемен алып килә.

1904 елда Исхакыйның фантастик эчтәлекле, ярым публицистик «200 елдан соң инкыйраз» китабы басыла. Бу әсәр татарлар арасында зур бәхәсләр уята. Китапта тирән кризис кичерүче татар-мөселман җәмгыятенең (текстта – болгарларның) ике йөз елдан бетүе тасвирлана. Анда милләт үсешен тоткарлый торган берничә сәбәп атала: искелеккә ябышып ятучы руханилар төркеменең халыкка көчле йогынтысы; алгарышка китерерлек мәктәп-мәдрәсәләрнең булмавы, булганнарында схоластиканың саклануы; милләткә хезмәт итә торган зыялыларның ярлы сыйныфтан чыгып, көчләрен күбрәк тамак туйдыруга сарыф итүләре; халыкның рус мәктәпләреннән йөз чөерүе, аларга шикләнеп каравы, балаларын аларда укытырга теләмәү; эшне башлап, ахырына кадәр җиткерә белмәү, буш эшләр белән йөрү. Исхакый юкка чыгу сәбәпләрен руслардан да «эйттерә». Ут күршеләр болгарларның аяныч хәлгә төшүләренең төп сәбәбе дип бик диндар булып, үз эчләренә йомылуларында, башка халыклардан тәҗрибә алырга теләмичә, башкаларга өстән карау аркасында һөнәрсез, гыйлемсез, дәүләтсез калып, тормышларын кара хезмәттә үткәрүдә күрәләр.

Фотолар автордан алынды

ТАТАР СОЦИАЛИСТЛАРЫ ӘЙДӘМАНЫ

Исхакыйның сәяси карашлары һәм иҗтимагый эшчәнлегенең төп юнәлеше укытучылар мәктәбендә укыганда формалаша. Бер яктан, егет рус классиклары әсәрләрен үзләштерә, хәтта А. Пушкинның «Капитанская дочка» һәм Н. Гогольнең «Старосветские помещики» повестьларын татарчага тәрҗемә итә. Икенче яктан, сәясәт белән кызысына. 1901 елда КТУМда «Шәкертлек» исемле яшерен оешмага нигез сала, радикаль революцион эчтәлекле «Тәрәккъый» («Прогресс») исемле газета бастыра башлый.

1904 елда Гаяз Исхакый авылыннан Казанга килә. Рус-япон сугышы башлангач, «Шәкертлек» түгәрәге радикаль-милли программалы «Хөррият» исемле яшерен сәяси оешма итеп үзгәртеп корыла, шушы исемдә яшерен газета бастырыла башлый. Оешма халык арасында күпсанлы листовкалар тарата. Аларда сүз, нигездә, илдә демократик ирекләр кертү һәм дини-мәдәни автономияне ныгыту һәм киңәйтү турында бара. Ләкин бу елларда хөрриятне яклаучылар күп булмый: аларның саны, нигездә, зыялылар, приказчиклар, һөнәрчеләр һәм укучылар белән чикләнә.

1905 елгы революция башлангач, «Хөррият» таркала. Аның составыннан Әхтәмов, Г. Терегулов һәм Х. Ямашев җитәкчелегендә – социал-демократлар, Г. Исхаков, Ф. Туктаров һәм Ш. Мөхәммәдьяров җитәкчелегендә – социалист революционерлар һәм Й. Акчура һәм С. Максуди җитәкчелегендә либераллар аерылып чыга.

Императорның «Дәүләттә идарә тәртибен камилләштерүгә юнәлтү» исемле 1904 елның 12 декабрендәге Указы хакимиятнең киң масштаблы реформалар үткәрергә әзер булуын белдерә. Шушы уңайдан Казан җәмгыяте мөселманнарның ихтыяҗлары турында петиция текстын әзерли. Гаяз Исхакый җитәкчелегендәге яшьләр нигездә дини хокуклар язылган петициягә гражданлык хокуклары турында маддәләр кертүгә ирешә. Аларда сүз татар телендә матбугат бастырырга, Шәрык телләрендәге матбугат белән илнең төрле төбәкләрендә сәүдә итәргә рөхсәт бирү; барлык фәннәр туган телдә укытыла торган уку йортлары ачарга рөхсәт итү; мөселман халыкларына руслар белән бер дәрәҗәдә илнең төрле төбәкләрендә күчемсез милеккә ия булу, иҗтимагый эшчәнлеккә һәм дәүләт хезмәтенә хокук бирү турында бара. Бу петиция тексты «Тәрҗеман»да (Бахчасарай), «Каспий»да (Баку) һәм рус матбугатында басылып, андагы тәкъдимнәр башка күмәк гаризаларда да урын ала. 1905 елның 9 мартында шәһәр мөселманнары җыелышында шулай ук «рухи-дини ихтыяҗлар» турында петиция тексты һәм Петербургка барачак депутация составы раслана. Депутация составына Гаяз Исхакый да кертелә.

Депутация вәкилләре 31 март көнне Министрлар кабинеты рәисе С.Ю. Витте кулына, «рухи-дини ихтыяҗлар» гаризасыннан тыш, «гражданлык ихтыяҗлары» исемле петиция дә тапшыралар. Соңгысында татар халкын кимсетә торган барлык кануннарны һәм министрлыклар карарларын юкка чыгару, илдә вөҗдан, сүз һәм матбугат ирекен кертү, кешеләрнең шәхси ирекен һәм күчемсез милеккә хокукларын гарантияләүче кануннар кабул итү, дәүләт белән идарә итүне кануннар нигезендә тормышка ашыру, авыл һәм шәһәр халкының тормыш-көнкүрешен яхшырту, уку-укыту өлкәсендә бушлай татарча һәм русча белем алуга мөмкинлек тудыру, барлык фәннәр дә татар телендә укытылачак уку йортлары ачу, рус телен татарларны руслаштыруда кулланмау таләпләре кискен рәвештә әйтелә. Матбугат өлкәсендә татарларга карата чикләүләрне бетереп, аларга рус матбугат чараларына кагылышлы таләпләрне таратып, газета-журналлар бастыру хокукы бирү кирәклеге көн тәртибенә куела.

Бу петиция татарлар биргән гаризалар арасында сәяси яктан иң көчлесе икәнен белгән хәлдә, Гаяз аның текстын башкалада нәшер ителә торган «Право» газетасында бастырып чыгаруга ирешә. Газетаның 16 апрель санын күпләп сатып алып, башкалар да шундый эчтәлекле петицияләр бирерләр дип өметләнеп, почта аша танышларына, фикердәшләренә җибәрә.

Гаяз Исхакый җитәкчелегендәге татар яшьләре төркеме 1905 елның 15 августында Россия мөселманнарының I корылтаенда катнаша. Исмәгыйль Гаспринский «Мөселман иттифакы» исемле партия төзергә җыенулары хакында әйткәч, Гаяз Исхакый, бәхәскә кереп, сыйныфларга бүленгән җәмгыятьнең мәнфәгатьләре капма-каршы, шуңа күрә бердәм мөселман партиясе була алмый, дип белдерә,

Гаяз Исхакый Казан төрмәсендә. 1907 ел.

Г. Исхакый, С. Максуди һәм Ф. Туктаров. 1920 ел.

Гаяз Исхакый Архангельск губернасында сөргендә.

Россия мөселманнарын мәдәни берлек нигезендә берләштерүне мәгъкуль дип сөйли. Корылтайда ясаган чыгышында Исхакый берләшүне ил мөселманнарының мәдәни-мәгърифәтчелеккә нигезләнгән төрки союзы рәвешендә корырга һәм сәяси көрәштә катнашмаска өнди.

1906 елның башында Казанда Исхакый җитәкчелегендә татар эсерларының оешмасы барлыкка килә һәм аның шәһәр комитеты сайлана. Аларның төп сәяси таләпләре самодержавиене бәреп төшереп, республика идарәсен урнаштыру; гражданнарга сәяси һәм демократик ирекләр, тигез сайлау хокукы, киң автономия бирү; җирне крестьяннар кулына тапшыру; эшчеләрнең эш көнен 8 сәгатькә кадәр кыскарту; милли төбәкләр белән идарә итүне федераль мөнәсәбәтләргә буйсындыру һәм халыкларның үзбилгеләнү хокукын тану һ.б.лардан гыйбарәт була.

Гаяз Исхакый редакторлыгында 1906 елның 18 маенда чыга башлаган «Таң йолдызы» газетасы халыкка: «берләшегез дә берләшеп тырышыгыз, чөнки тартышуда гына табарсыз сез үзегезнең хакыңызны» дип мөрәҗәгать итә. Шул ук елның августында Мәкәрҗә ярминкәсендә узган Россия мөселманнарының III корылтаенда Исхакый әлеге фикерне шигарь итеп күтәрә: «Тартышуда гына табарсың үз хакыңны!»

Хөкүмәтне тәнкыйтьләгән «Таң йолдызы» 16 ноябрьдә ябылгач, Исхакый редакторлык эшчәнлеген «Таң мәҗмугасы» журнал-җыентыгында (ике саны чыгып кала) һәм «Тавыш» газетасында (1907 елның апрель–август айлары) дәвам итә.

Россиядә яшәгәндә Гаяз Исхакый 18 тапкыр кулга алына. Беренче тапкыр 1906 елны Чистайда 43 көн тоткынлыкта вакытта төрмә хроникасы рәвешендә «Зиндан» исемле повесть яза.

Аның «Теләнче кызы» романында (1907) кечкенәдән ятим калган Сәгадәт исемле кызның, тормыш авырлыкларын җиңеп барып, милләткә хезмәт итүгә күчкән хатын-кызга әверелүе сурәтләнә.

Гаяз Исхакыйның көрәш еллары рухы белән сугарылган «Мөгаллим» (1906), «Тартышу» (1908) драмалары, «Алдым-бирдем» (1907), «Кыямәт» (1909–1910) һәм «Җәмгыять» (1909–1910) комедияләрендә татар җәмгыяте үсешенә каршы торучы көчләрне фаш итү аша тамашачыны милләт мәнфәгатьләрен кайгыртып көрәшкә чакыру, өндәү ачык күренә.

МИЛЛӘТ ЯЗУЧЫСЫ

Әдәбият фәне галимнәре исә 1909 елдан башлап Исхакыйның язу рәвеше үзгәрүгә игътибар итә. Язучының моңарчы язган публицистик, мәгърифәтчел һәм иҗтимагый-сәяси текстлары романтик характерлы милли-фәлсәфи әсәрләр белән алышына. Аларда татарны яшәтәчәк һәм үстерәчәк көч буларак халыкның әхлагы, гадәт-йоласы, акылы һәм дөньяга карашы билгеләнә.

Бу үзгәрешнең чалымнары язучының 1909 елда Төркиядә иҗат ителгән «Тормышмы бу?» исемле повестенда ачык чагыла. Әсәрдә татар шәкертенең, мулла булгач, тормышны үзгәртә алмыйча, халыкка хезмәт итү идеалын югалткан, вөҗдан газапларына дучар булган авыл руханиена әверелүе Беренче рус инкыйлабы тәэсирендә туган өметхыялларын югалткан татар яшьләре халәте буларак тасвирлана. Исхакый бер үк вакытта шул яшьләрдә тормышны үзгәртерлек көчне дә күрә.

СӨРГЕННӘН КАЧУ

Язучы 1908–1911 елларга Архангельск губернасына сөргенгә җибәрелә. Качып, ялган паспорт белән 1908 елны Санкт-Петербургта яши, 1909 елны Төркиягә сәяхәт кыла, шул елның көзендә янә Санкт-Петербургка кайта, 1910 елның җәендә Финляндиядәге татар җәмгыяте хозурында «Мулла бабай» романын, «Фамилия сәгадәте» исемле хикәяләр циклын кәгазьгә төшерә. «Мулла бабай» романында автор йомылып яшәүче татар авылының патриархаль тәртипләрен, шәкертләр һәм мулланың тормыш-көнкүрешен бик яратып һәм җентекләп сурәтли.

Язучы 1910 елның көзендә Истанбулга килә. Биредә иҗат иткән «Сөннәтче бабай», «Кияү», «Шәкерт абый» хикәяләрендә туган халкының матур гореф-гадәтләрен, йолаларын этнографик төгәллек белән тасвирлый. Истанбулда яза башлаган «Зөләйха» драмасын 1912 елда ялган паспорт белән Санкт-Петербургта кайткач тәмамлый. Ләкин кулга алына, тагын Архангельск губернасына сөрелә. Романовларның идарә итүләренә 300 ел тулу уңаеннан ирекккә чыгарыла. Башта – Санкт-Петербургта, аннары Мәскәүдә яши һәм «Ил» газетасын нәшер итә.

Реакция елларында Исхакыйның иҗтимагый-сәяси карашлары тирән фикер үзгәреше кичерә. Исхакый «Русия мөселманнары» исемле мәкаләсендә, «200 елдан соң инкыйраз» китабындагы сүзләренә капма-каршы килеп, туган халкы турында горурланып яза.

Ул сыйнфый көрәш концепциясеннән ваз кичеп, беренче планга милләт мәнфәгатьләрен үзәккә куеп эшли башлый. 1917 елда бу хакта болай дип белдерә: «Иҗади эш, мәдәни эш һичбер вакытта бер сыйныфның көче белән генә эшләнә алмый. Бөтен сыйныфларның көчләрен бергә кушып тотынганда гына бик таманга туры киләчәк».

1909–1918 елларда Исхакыйның вакытлы матбугатта дөнья күргән мәкаләләре үзәгендә милләт яшәеше, милли тәрбия һәм мәгариф, милли әдәбият һәм сәнгать, күренекле җәмәгать эшлеклеләре язмышлары кебек көнүзәк темалар тора.

РЕВОЛЮЦИОН ВАКЫЙГАЛАРДА КАТНАШУ

Гаяз Исхакый 1917 елгы Февраль революциясен шатланып каршылый. Ул 1–11 май көннәрендә Мәскәүдә узган Россия мөселманнарының I корылтаен оештыручыларның берсе була. Ул 900 дән артык делегатны Мәскәү комитеты исеменнән котлый, докладында төрки-татарның киләчәге милли-мәдәни автономия булырга тиеш дигән фикерне уздыра. Аны тормышка ашыру өчен, Россиянең киләчәген билгеләячәк Учредительное собрание җыелганчыга кадәр Милли шура сайларга тәкъдим итә. Корылтай Исхакый әзерләгән резолюцияне кабул итә.

Шул ук елның июль аенда Казанда үткәрелгән II корылтайда Казахстан, Урта Азия һәм Кырым вәкилләре катнашмый. Аның милли-мәдәни автономия игълан итү карары татар һәм башкортларга гына мөнәсәбәтле була. Корылтайда Милләт мәҗлесенә сайлана. Милләт мәҗлесенең 1917 елның 22 ноябреннән 1918 елның 11 гыйнварына кадәр Уфада булган утырышларында милләтнең киләчәге турында ике капма-каршы фикер калыплаша. Г. Исхакый, Һ. Максуди, Г. Терегулов, З. Кадыйри һ.б. милли-мәдәни автономияне яклый, «туфракчылар» территориаль автономияне алга сөрәләр. Исхакый Парижда Версаль солых конференциясенә барачак делегатларның берсе итеп сайлана.

Большевиклар Милли мәҗлесне һәм аның идарә органы булган Милли идарәне куып тараткач, бер төркем депутатлар һәм әгъзалар, Кызылъяр шәһәренә качып, шунда кече Милли мәҗлес, Милли идарәнең эшен тергезәләр. Гаяз Исхакый «Маяк» газетасын нәшер итә. Шулай ук Кызылъярда Россиядә яшәгән вакыттагы соңгы әсәрен – «Дулкын эчендә» исемле пьеса яза. Кызыл гаскәр Идел-Уралны яулап алгач, Исхакый 1919 елда Кызылъяр шәһәреннән Ерак Көнчыгыш аша чит илгә китә. Шул рәвешле, татар милли идеологы һәм язучысының тормышында мөһаҗирлек чоры башлана.

Гаяз Исхакый һәм «Аң» журналы мөхәррире Әхмәтгәрәй Хәсәни.

Гаяз Исхакый Мәскәү шәһәренең татар яшьләре белән. 1913 ел.

СССРНЫҢ ЧЫРШЫ УЕНЧЫКЛАРЫ ДӨНЬЯСЫ

Яшел чыршы Яңа елда да, Иске Яңа елда да бик матур! Ул иске «киемдә» дә, яңасында да балкып утыра. Безнең әби-бабайлардан калган ретроуенчыклар, бәйрәм көннәрендә бөтен гаиләне, нәсел-нәсәпне бергә туплап, безнең белән инде булмаган якыннарыбызны искә төшереп, күңелдә сагыну-сагыш хисләре уята.

Бу уенчыкларны озаклап карарга, андагы һәр бөтеркәгә, сызык, уемнарга сокланып, билгесез останың иҗатын бәяләргә, уенчыкта гәүдәләнгән һәр персонажны танырга мөмкин.

Сезнең чыршыгызны СССР чорына, тагын да элегрәк вакытка караган уенчыклар белән бизәгәнегез бармы? «Татарстан» журналының телеграм-каналында иске чыршы уенчыклары конкурсы үткәрелә. Сез аларны фотога төшереп безгә җибәрә аласыз, ә Иске Яңа елда конкурска йомгак ясаячакбыз. Иң кызыклы ретроуенчык хуҗасы ПРИЗ алачак!

Фото: Вероника Домрачева

Кыстыргычлы Куян


Ятьмә тоткан карт

Чук һәм Гек

Самолёт

Парашют

Хоттабыч

Кызылтүш

Үрдәк

– Чук һәм Гек – Гайдар повесте геройларын хәтерлисезме? - ди уенчыкларның хуҗасы, Татарстан Журналистлар берлеге әгъзасы Вероника Домрачева. - Чук – Частника Уничтожит Коммунизм дигәнне аңлата икән. Ә Гек – Героик Компартия. 1935 ел!

Абыем туган 1935 елгы уенчык самолёт һәм парашют, аннары беренче иярчен... Бүген бу уенчыклар – очучы абыем турында истәлек...

1950 нче елларга караган үрдәк, кызылтүш, «көмеш тояк»... Ә менә бу Ятьмә тоткан карт – сугышка кадәрге үк ясалган уенчык... Һәм инде быелгы ел символы Куян – СССРда кыстыргычлы беренче уенчык.

Сүз уңаеннан, монысы СССРда полиэтиленнан ясалган беренче ясалма чыршы, 1969 ел. Әлеге чыршыны сатып алыр өчен әнием, кулына номер тотып, көне буе Мәскәүнең «Балалар дөньясы»нда чират торды... Ә мин кеше арасында аны таба алмыйча куркып беттем! Ә ул, кош тоткандай шатланып, чыршы салынган тартмасын тотып, халык арасыннан килеп чыкты! И-и ул чактагы куанганнарым!

ПЫЯЛАДАН ТОРБА «ҮРГӘН» КЕШЕ

Космик технологияләр җирдә икеләтә нәтиҗәле, икеләтә файдалы. Якташыбыз Сергей Волков әнә шундый фикергә килә һәм үз компаниясен ача. Дөнья күләмендә аңа тиң компанияләрнең саны бер дистә чамасы гына.

1970 нче еллар ахыры. Куйбышевтагы Үзәк махсус конструкторлык бюросында (ЦСКБ) «Прогресс» ягулык корабын йөртүче ракета ясау белән мәшгульләр. Ягулык кызып китмәсен өчен, температураны төшерү мәсьәләсен хәл итәргә кирәк. СССР Оборона министрлыгы ягыннан бу процессны космонавт Герман Титов җитәкли.

– Ягулык ташу корабында коточкыч эссе. Ләкин Титов шунда сәгатьләр буе утырып, термометр мәгълүматларын язып бара. Ул Оборона министрлыгы вәкиле буларак, исәпләүләр нәтиҗәсендә алынган һәр күрсәткечне тикшерергә тиеш. Мин моңа бераз югарыданрак карадым: без, проектлаучылар, инде барысын да тикшердек һәм Титовның күзәтүләр аша берничә көннән соң нинди саннар күрәчәген генә түгел, ни өчен нәкъ менә шундый нәтиҗәләр булачагын да белә идем. Безнең Оборона министрлыгы өчен бу гадәти сыйфат контроле язмышымда нинди роль уйнаячагын гына белмәдем, – дип искә ала Сергей Волков.

Тиздән ЦСКБ техник яктан искиткеч катлаулы «Буран» проектына күчә, тик аның беренче очышы бердәнбер булып калачак. Аннары үзгәртеп кору җилләре космосны арткы планга этәрә. Ә Сергей Волков Әлмәткә күченеп, күпмедер вакытлар узгач, «Татнефтегазстройпроект» институтын җитәкли. Ләкин төзелеш һәм инфраструктура белән шөгыльләнгәндә дә, Волков космос турында, төгәлрәге космик технологияләр ача торган мөмкинлекләр турында уйлануын дәвам итә.

МАСКТАН ӨЛГЕРРӘКЛӘР

– Бала вакытта миңа авиация һәм этләр ошый иде. Ләкин ветеринар һөнәре әллә ни кызыктырмады, ә менә конструктор буласы килү теләге көчле иде, – дип искә ала Сергей Волков. Ул Красноуфимск шәһәрендә туып, Алапаевскида үсә. Урал төбәгенең кырыс шартлары әйберләргә практик күзлектән карарга, хисләрне тыярга өйрәтә. Сергей КАИның ракета төзелеше бүлегенә керә. Егетне очышлар түгел, ә физика белән идарә итү, бу фәнне яңа, ерак офыкларга илтә торган машиналар булдыруга хезмәт иттерү мөмкинлеге кызыктыра.

– ЦСКБда минем вазифага Американың «Шаттл» проектын күзәтеп тору да керә иде. Мин бүген дә кызыксынам-күзәтәм – Маскның нәрсә эшләгәнен карап барам. Аның проектларында бездәге бик күп эшләнмәләрне

Фотолар Пыялалы торбалар заводы матбугат хезмәтеннән алынды. РЕКЛАМА

Завод командасы Мисырда рекордлы кыска вакыт эчендә эшләтеп җибәргән газүткәргеч.

күрәм. Бу исә 1970-1980 нче елларда безнең алгы сафта барганыбызны раслый. Без булдырганның күбесе бүген дә гамәлдә, әйтик, «Союз» ракетасы, исән калдырыла торган кораб өлешләре. Мин бу мирасыбызның юкка чыгачагына ышанмыйм, – ди Волков.

Әңгәмәдәшебезнең бу хакта сөйләшүе табигый, чөнки ул үз тәҗрибәсен алга бару һәм югары күтәрелү өчен кулдана. «Татнефтестрой» җитештерү берләшмәсенең мәгълүмати исәпләү үзәгендә эшләү, «Оргтехстрой» тресты белән идарә итү, ТКХ министры урынбасары вазыйфасы, «Татнефтегазстройпроект» институты белән җитәкчелек, депутатлык эше – болар барысы да Сергей Алексеевичның киләчәк проекты өчен нигез өлгеләргә әйләнә.

ПЫЯЛА – «ЯҢА» МЕТАЛЛ УЛ

Болгавыр 1990 нчы еллар. Күпләр бу чорны иң романтик вакыт буларак хәтерли. Ирек-хөрлек, технологияләрдән файдалану, үз бизнесыңны булдыру мөмкинлеге... Дәүләт хезмәтендәге Сергей Волков әнә шул романтиканы татып карарга тели. Мәскәүдә өметле идарәчеләр өчен курслар оештырылган чак һәм ул, бу курсларны узып, халыкара менеджерлык дипломын ала. Бервакыт Волковка Татар инвестицияләр компаниясен (ТИК) оештырган мәскәүлеләр мөрәҗәгать итеп, директор булырга тәкъдим ясый. Ул ризалаша.

– Пыялалы пластикны бүген дә күпләр пыяла кебек ualучан, кагылуга ватыла торган нәрсә дип кабул итә. Ләкин бу композит материал – дөньяда иң чыдамнарның берсе. Ул чакта, утыз ел элек, безнең ил өчен пыялалы пластик ниндидер фантастика иде. Тик без тәвәккәлләргә булдык, – ди Сергей Волков.

Проектка «Татнефть» кушыла, предприятие «Татнефтеиндустрия» дип атала башлый. Җитештерү эшен кайчандыр Казан авиация конструкторлык бюросы булган мәйданчыкларда җәелдерелеп җибәрәләр. АКШтан җиһазлар сатып алып кайтып урнаштыралар. Тик илдә дефолт була.

Волковка үзе эшкә сайлап-сайлап кына алган белгечләрне таратырга туры килә. Коллектив моны аңлап кабул итә. Алай гына да түгел, кешеләр тиздән кайтачакларына чын күңелдән ышанып китә. Сергей Алексеевич җитәкчелегендә эшләгән кыска гына вакыт эчендә директорның һәрчак һәрнәрсәне аңлап, белеп эшләгәнлегенә хезмәткәрләрнең ышанычы какшамас була.

ОПТИМИЗМ ТЕХНОЛОГИЯСЕ

– Бер генә бизнес-план да гел уйлаганча гына килеп чыкмый. Әлмәттә объектны файдалануга тапшыру вакытын билгеләнгәндә, рәсми датага без күңелдән генә-өч ай, ә өлкә комитеты өчен ниндидер принципиаль проект булса, ярты ел өсти идек. Коммерциядә дә шулайрак. 90 нчы елларда да һәм хәзер дә без тәҗрибә, интуиция һәм оптимизмга таянабыз. Бу өч нәрсә беркайчан да сынатмый, – ди Сергей Алексеевич.

«Татнефтеиндустрия» 1998 елда ябыла. Ә 2002 елда гына кабат ачыла. Волков якындагы берничә елда табыш булмаячагы турында әйтеп торса да, коллектив тулы составта диярлек кире кайта. Россия базары әле һаман да композитлар турында бөтенләй белмәсә дә, «тимер җитештерүчеләр» яңа предприятиеләр рәвешендә үз ресурсларын үстерә барса да.

Пыялалы торбалар заводын төзү авантюрага тиң була. Сергей Волков командасы капшанып диярлек алга бара – фән дә, оборона сәнәгате дә кирәкле белемнәр бирә алмый. Американлылар предприятиегә станокларны сата, тик технология белән уртаклашмый. Компания ул технологияне берничә ел дәвамында яңадан булдыра. Пыяла сүсне урау процессы төп проблемага әйләнә. Волков бу мәсьәләне чишү юлын тәкъдим итә. Аны гамәлгә кертүгә, барысы да эшләп китә.

Завод командасы Коми Республикасындагы Маньпупунёр платосында.

МИН ЫШАНАМ ИКӘН, ДИМӘК, БЕЗ ЯШИБЕЗ

Бервакыт завод РФ Оборона министрлыгыннан заказ алуга ирешә. Тик хәрбиләр тарафыннан гамәлгә куелган кабул итү принциплары юлга аркылы төшә. Гражданлык стандартлары буенча торба барлык параметрларга туры килә. Ә хәрбиләрнекенә – юк: статик электрны бетерергә кирәк. Завод Мәскәү фәнни-тикшеренү институтына мөрәҗәгать итә. Анда ярдәм итә алмыйлар.

– Мин чишү юлы барлыгын беләм һәм без аны табачакбыз, – ди ул вакытта хезмәткәрләренә Волков.

Төне буе баш ваталар. Иртәнгә проблема хәл ителә. Берничә айдан соң Волковны коридорда урынбасары каршы ала:

– Яңалыкларны карамадыңмы? Репортаж күрсәтеләр – Мәскәү өлкәсендә янгыннар бара, МЧС хезмәткәрләре күтәреп йөгергән торбалар – безнеке.

Сергей Волковның үз коллективына, һәркемнең җаваплы һәм профессиональ эш йөртәчәгенә ышанычы – заводның Россия һәм чит ил базарларында күп еллар дәвамында алдынгылыкны тотуының төп сәбәбе. Утыз ел җитәкчелек итү дәверендә беркем дә, беркайчан да Волковның сүгенгәнен ишетмәгән, диләр. Аның абруе компания белән профессиональ идарә итә белүенә, һәркемнең имин-мул тормышы белән ихлас кызыксынуына, хезмәткәрләргә кирәкле ярдәм күрсәтергә әзерлегенә һәм үзен даими үстереп-камилләштереп торуына нигезләнә. Мондый кешенең ышанычына хыянәт итәргә ярамый.

НЕФТЬ ҺӘМ СУ ӨЧЕН «АРТЕРИЯЛӘР»

Сахара, 2020 ел. Мисырлы монтажчылар бригадасы заводтан ике вәкил күзәтүендә ком тавы аша торбалар сала.

һәм алар үзенчәлекле рекорд куярга җыена: 12 сәгатьлек смена дәвамында 2 км чамасы торба сузылган.

Пыялалы пластик торбалар заводының (ЗСТ) җиңел, чыдам, 60 еллык гарантияле торбалары бөтен дөнья буйлап – Төньяк Боз океаны ярыннан Мисыр чүлләренә кадәр салынган. Алардан газ, нефть, артезиан суы, хәтта тозлы су да ага. ЗСТ – Россиядә һәм БДБ илләрендә продукциясе Америка нефть институты таләпләре буенча тармакның «алтын стандарты»на туры килгән беренче, ә Европада бердәнбер җитештерүче булып тора. Былтыр завод Казахстанда үзенең икенче җитештерү урынын ачты. Аның нигезенә Сергей Волков һәм аның хезмәттәшләре 2000 нче еллар башында булдырган технологияләр салынган.

– Яшь менеджерларны, инженерларны, технологларны укыту өчен безнең үз системабыз бар. Бүген теге яки бу килешү турында карарны 30-40 яшьлек кешеләр кабул итә. Ә алар белән яшьтәшләре сөйләшергә тиеш, – ди ЗСТ башлыгы. – Чөнки эшлекле сөйләшүләр килешүнең шартлары турында фикер алышу гына түгел, аралашу да булып тора. Кешеләр бер-берсенең фикерен, хәзерге дөньяга карашларын белешә. Мин алар белән нәрсә хакында сөйләшә алам? Ярты гасыр элек булган хәлләр турындамы?

2023 елда Сергей Волков – 70 яшен, завод 30 еллыгын билгеләп үтә. Сергей Алексеевич һәм аның кулдашлары үзләренә лаеклы алмаш үстергән һәм хәзер төрле яраткан шөгыльләренә күбрәк вакыт бүлеп бирә ала. Хәер, бу хоббилар чынлыкта яңа проектларга әзерлек булып тоела.

– Элегрәк мин рәсем ясау белән мавыктым, майлы буяулар белән ясый идем. Хәзер санлы фотографияләр ошый. Алар ясалма интеллектның дөньяны ничек кабул итүен аңларга булыша, – дип аңлата Волков. – Нейрочелтәр сурәтләрне кабул итә һәм анализлый. Бу технологияне производстводагы проблемаларны читтән торып диагностикалау платформасы да куллана. Без аны берничә ел «Сколково»ның бер компаниясе белән ясап килдек. Бер-ике елдан соң эшләтеп җибәрәчәкбез.



Завод вәкилләре Абу-Дабидә (Берләшкән Гарәп Әмирлекләре) потенциаль партнёрлар белән очрашу вакытында.

УТОПИЯЛӘРДӘН СОҢ, ЯКИ БЕЗНЕ НӘРСӘ КЕШЕ ИТӘ?

Луиза Янсуар

2022 елда нәшриятларда басылган китаплар – гаять төрле һәм үзенчәлекле. Безнең аларны кабул итү һәм тоемлавыбыз да – яңача. Яңа елга кергәндә уйландыра да, юандыра да торган берничә китап тәкъдим итәбез сезгә.

АЗАР НАФИСИ, «ЧИТАЯ «ЛОЛИТУ» В ТЕГЕРАНЕ»
«Livebook/Гаятри» нәшрияты, 2022

«КИТАПЛАР БЕЗНЕ ҖИНАЯТЬТӘН КОТКАРДЫ...»

«Ә берәүнең дә хисләрен рәнҗетмичә, яхшы әсәр иҗат итеп буламы? – дип сорады көннәрдән бер көнне Нассрин. – Чын мәгънәсендә яхшы әсәр...» Әйдәгез, күз алдына китерик: яшь-яшь кызлар, университет студентлары. Күзләре янып тора, аларга бар да кызык, бөтен нәрсә мавыктыргыч. Алар үзләренең мөгаллимнәре фатирына китаплар укырга җыелалар. Чәй эчәләр, татлы-баллы тәм-томнардан авыз итәләр, кычкырып романнар укыйлар, аларны анализлыйлар, бер-берсе белән фикер алышалар, бәхәсләшәләр, көлешәләр... Һәм кинәт – баскычта гөрселдәгән аяк тавышлары, берничә минуттан ишек җимерелеп эчкә авып төшә, кызларның йөзләренә автоматлар төбәлә...

Китап битен ябып куярга һәм җиңел суларга мөмкин булыр иде. Әмма бу роман гына түгел шул. Ә Азар Нафиси һәм аның укучылары яшәгән чынбарлык. Фатирның тәрәзә һәм ишекләре артында исә – урта гасыр түгел, ә егерменче йөз Тәһраны.

Бу әсәрнең төп кыйммәте һәм дөньякүләм популярлыгы – документальлеккә нигезләнгән булуында. XXI гасырда яшәүче кешеләр өчен акылга сыймас кебек тоелган хәлләр асылда янәшәдә генә булып тора, кемнәрнеңдер акылына һәм мантыйгына гына түгел, ә иманына да сыя. Без моны, билгеле ки, бүгенге гаммәви мәгълүмат чаралары һәм социаль челтәрләр дөньясында азмы-күпме ишетеп-белеп торабыз. Әмма бу үзенә күрә бер «ак шау» сыман – бар да, юк та. Бимазалый да, түгел дә...

Ул арада сәясәтнең кеше тормышына ничек бәреп керә һәм аны имгәтә алуы хакында бик гади дә, үзәк өзгеч детальле итеп тә яза Азар Нафиси. Бу китап Көнбатышта басылып чыккач, әйтерсең бомба шартлый. Аны, Көнбатышның иң көтелгән традицияләре буенча, феминистик әдәбият өлгесе, шедевр дип таныйлар. Азар Нафиси бу сүзләрдән көлемсерәми калмагандыр, мөгаен... Никтер шулай тоела. Әлбәттә, китап бөтенләй феминизм турында түгел. Ә тоталитар система эчендә бикләнүгә дучар булып, исән калу, иманы белән дә, рухы белән дә иреклe булып калу өчен көрәшүче кешеләр турында. Кечкенә генә бер адымың да, башыңны борып каравың да үлемгә китерергә мөмкин булган дәүләт эчендә нишләргә була? Әгәр ул дәүләт газиз ватаның да булса?! Азар Нафиси һәм аның китап героинялары үзләре өчен юаныч һәм җавапны... китапларда таба.

«Баскычтан менгәндә, мин диварларга ябыштырылган плакатлар белән лозунгларга игътибар итмәскә тырышам. Нигездә, болар – Гыйрак сугышыннан аклы-каралы кадрлар. Шулай ук Бөек Иблис – Американы һәм аның тарафдарларын каһәрли торган лозунглар. Һәр фотография астында – олуг аятолла Хомәйни цитаталары: «Без үтерәчәкбезме, әллә алар безнеме – мөһим түгел, без инде барыбер – җиңүчеләр! Университетлар ислам кануннарына буйсынырга тиеш! Бу сугыш – барыбыз өчен дә изге сугыш, ул Аллаһ тарафыннан бирелгән фатиха буенча башкарыла!»

Миңа бик читен иде боларны күрү, әле дә читен. Бу менталь халәтнең безнең белән идарә итүен тоюдан ми чатный. Шул ук сүзләрне мин рәсми газета-журналлардан да укыйм, телевизордан да ишетәм, кафедралардагы руханилар авы-

Фотолар labirint.ru, goodfon.ru, litres.ru, livelib.ru, pinterest.com сайтларыннан алынды

зыннан да тыңлыйм. Алар барысы да, хәтәр дошманны табып, аны юкка чыгару турында сөйли. Һәм үзен шуңа багышлый. Кемнәрдер инана алды. Ә мин үземне очсызлы бер олтырак итеп хис итүдән нишләргә белмим, әйтерсең, яман бер уенда катнашучы булып калдым... Бу гаепләүләр нәтиҗәсендә кайсыдыр гаиләләрнең ачлы-туклы, мәсхәраләнгән халдә калганын белам... Ә бит алар бернинди дә җинаять эшламәде, бары тик җәмәгать урыннарында күләргә генә җөрьәт итте, йә булмаса үз җенесеннән булмаган дусларының кулын кысты...»

Нафиси ватанына «ислам революциясе» узганнан соң әйләнеп кайта. Хыялын чынга ашыру өчен, ул туган илендә яшәп, аның үзаңын һәм фикерләү колачын үстерергә тели. Университетта күнбатыш һәм бүгенге заман әдәбиятын укыта башлый. Ул өч университетта укытып карый. Шул рәвешле, ике цивилизация һәм ике дөнья арасында күпер сала алам, дип өмеләнә.

Тора-бара Нафиси үзенә карата булган азмы-күпме лояль мөнәсәбәтнең бары тик әти-әнисе аркасында гына икәнлеген ваемлап ала. Әмма йөзенә чадра киеп йөрүдән баш тартуга, әлеге мөнәсәбәттән җилләр исә.

1995–1997 елларда аның иң алдынгы карашлы һәм акыллы студентлары, Нафиси фатирына яшерен килеп йөреп, дөнья әдәбиятын өйрәнә. Әсәр аларның хәзерге дөнья, глобализм һәм тоталитар режим, кешеләр һәм аларның сәяси яссылыктагы язмышлары, кешелек тарихының барышы турындагы сөйләшүләренең квинтэссенциясе. Ул дүрт өлештән тора – «Лолита», «Гэтсби», «Джеймс», «Остин». Әмма ни өчен әсәрнең башисемендә «Лолита» чыгарылган соң? Нафиси моңа аңлатманы үзе үк бирә. Аның фикеренчә, балачагы урланган яшүсмер кыз язмышы белән кешелегә аяк астына салып тапталган Иран хатын-кызларының язмышы тәңгәл. Гумберт Лолитаның гаебе үзендә, ул мине ымсындырды, дип белдерсә, радикаль сәясәтчеләр һәм закон саклаучылар да шулай ук итә – хиҗаб эченнән таралып чыккан чәч бөтеркәсе, ялгыш кына карашыңны күтәреп күз ташлау да бозыклыкка сәбәпче булып, язмышыңны хәл итәргә мөмкин.

«Китаплар безне җинаятьтән коткарды...», – ди ахыр чиктә Азар Нафиси.

АЗАР НАФИСИ – иран язучысы һәм җәмәгать эшлеклесе. 1955 елның декабрендә туган. Әтисе – Тәһран мэры, әнисе Иран парламентына (мәҗлесенә) сайланган беренче хатын-кызлардан. 13 яшеннән Бөекбританиядә, Швейцариядә һәм АКШта укый, инглиз һәм Америка сүз белеме буенча дипломны Оклахома университетында яклый. 1979 елда ватанына әйләнеп кайта һәм Тәһран университетында инглиз әдәбиятын укыта. Университеттан куыла. 1995 елдан башлап, үз фатирында инглиз әдәбияты һәм сүз сәнгате турында семинарлар алып бара башлый (Эмили Бронте иҗатыннан Набоков иҗатына кадәрге чорны укыта). «Чтение «Лолиты» в Тегеране» романының нигезенә әнә шул семинарлар салынган. Китап 2003 елда – Франциядә, аннан АКШта бестселлер була, Сьюзан Зонтаг, Маргарет Этвуд кебек атаклы язучыларның югары бәясен ала. 30 дан артык телгә, шул исәптән кытай һәм япон телләренә дә тәрҗемә ителә.
1997 елдан Азар Нафиси кабат АКШта яши, Принстон университетында укыта.

ДМИТРИЙ ДАНИЛОВ, «САША, ПРИВЕТ!»
АСТ нәшрияты, 2022

ЧЫНЛАП ШУЛАЙМЫ СОҢ?!

Елена Шубина редакциясендә басылып чыккан әлеге китап быелгы фаворитлар исемлегендә булды. Популярлыгына «Большая книга» һәм «Ясная Поляна» премияләре дә үз өлешен өстәгәндер, билгеле. «Человек из Подольска» белән Россия әдәбият һәм театр дөньясына яхшы таныш Данилов үзенең абсурд жанрына, кырыс, хәтта ки кара ирониягә йөз тотуы белән дә билгеле. Әмма «Саша, привет!» романы Кафка белән Ионеско, Хаксли белән Замятин рухындагы антиутопия традицияләрен дәвам итсә дә, үзенең гуманлыгы һәм хәтта... нәфислеге, йомшаклыгы белән аерылып тора, дияр идем. Шулай ук бик стериль, минималистик алымнарга корылган, акрынайтылган режимга куелган кинематографик материал рухында да ул.

Төп каһарман – Сережа – яшь галим, филолог, университетта 20–30 нчы еллар рус әдәбияты буенча курс алып бара, мәртәбәле Мәскәү дәүләт университетында укыта. Һәм менә аны яшь студент кыз белән җенси мөнәсәбәтләр өчен үлем җәзасына хөкем итәләр. Яңа гуманлы җәмгыятьтә төрмәгә (ул Комбинат дип атала һәм Мәскәү уртасында урнашкан бу бина өч йолдызлы кунакханәне хәтерләтә) кешеләр үз теләге белән бара, аларны беркем дә көчләми. Монда кеше яшәеше өчен бөтен уңайлыклар да тудырылган: уңай бүлмәләр, душ, лимитсыз интернет, менә дигән ашау, китереп бирүләр дә исәпкә алынган, ял итәр һәм һава сулар өчен бакча... Бердәнбер уңайсызлык – ул да булса «Саша», ягъни тоткыннар һәр көнне бакчага чыгар алдыннан узарга тиешле коридорның түшәменә элеп куелган пулемёт. Аның кайчан кайсы тоткынны чәрдәкләп ташлаячагын берәү дә белми. Хәтта сакчылар үзләре дә. «Сез монда бөтен гомерегезне уздырырга мөмкинсез, Сашаның кайчан кемгә атасы билгесез, бәлки, картайганчы ул сезгә атмас та...», – дип юата алар тоткыннарны. Баштарак куркудан тәмам тораташ булып каткан адәм балалары тора-бара Сашага сәлам биреп узарга, аның турында ирония белән сөйләргә дә күнегә...

Әсәрнең тагын бер тетрәндергеч үзенчәлеге – без бередә гүяки... кешеләр белән бөтенләй очрашмыйбыз. Чөнки, кайчандыр Музиль романының башисеменә чыгаргандай, аларның монда «сыйфатлары җуелган». Әсәрнең герое хатынына хыянәт итеп, студент кыз белән чуалышканга хөкем ителсә дә, җанны кузгатырдай бернинди тәенләнеш тә күзәтелми. Хатын-кызлар бу әсәрдә гомумән үзләрен кулда тотуның, ваемсызлыкның соң дәрәҗәсендә күрсәтелә. Бәлки, бу табигый да – режим сине «гуманлы иттарткыч» әченә китереп тыкса, үз-үзеңне саклау инстинкты иң беренче чиратта ана инстинкты белән керешеп китә. Ләкин бередә нәсел, дәвам турында сүз дә була алмый, бу стериль дөньяда киләчәккә тамчы да ишарә сизелми.

Кинематографик, сценарий рухындагы берелеш безгә инде бу тере мәетләр дөньясы икәнлекне раслый. Автор бик коры һәм эмоциясезләрсез сурәтләүне куллана: менә Сережа сукмактан атлый, менә чатта борылды, менә ул ашый, менә ул бәдрәфкә кереп чыкты, менә ул социаль челтәрдә пост элде, менә ул йокларга ятты, менә ул уянды... һәм шул бәжра буйлап әйләнә дә әйләнә. Нәрсәсе белән безнең тормыштан аерыла? Ә, әйе, безгә һәр иртәне «Саша» исемле пулемёт эленеп торган коридор аша үтәргә кирәкми.

Романны укыр өчен 5 сәбәп:

1. Дмитрий Данилов – атаклы язучы, драматург, «Алтын битлек» Милли театраль премиясе, Андрей Белый исемендәге премия, «Большая книга» һәм «НОС» премияләре лауреаты.

2. Язучының пьесалары Россиянең барлык әйдәп баручы театрларында сәхнәләштерелгән һәм аның әсәрләре буенча фильмнар төшерелгән. Ул берничә Европа иле теленә дә тәрҗемә ителгән.

3. «Саша, привет!» әсәре кеше тормышының 82 эпизодына корылган үзенчәлекле заманча антиутопия, әмма бу әсәрдә фантастика бөтенләй юк диярлек, ул нәкъ менә үзенең коточкыч реальлеге белән җәлеп итә.

4. Китапның төп каһарманы Сережа без белгән барлык сыйфатлы һәм күренекле антиутопияләрнең дә каһарманнары җыелмасы диярсең. Әмма аның иң аваздаш герое шулай да – Кафканың Йозеф К. образы. Хәер, тәнкыйтьчеләр бертавыштан әйткәнчә, романдагы шартларга әле бер генә әсәрнең каһарманы да куелганы юк иде. Бу китапны, әлбәттә, уникаль итә.

5. Роман быелгы мөмкин булган барлык премияләргә дә тәкъдим ителде һәм барлык кыска исемлекләрнең башында торды.

ИСЛАМ ХАНИПАЕВ, «ТИПА Я. ДНЕВНИК СУПЕРКРУТОГО ВОИНА»
«Альпина Диджитал» нәшрияты, 2022

«БУ – УНИВЕРСАЛЬ ТАРИХ»

Россия китап дөньясының быелгы ачышы һәм чын-чынлап каһарманы – Дагыстанда туып үскән һәм шунда яшәүче яшь сценарист, режиссер Ислам Ханипаев. Аның «Типа я» повесте «Лицей», «НОС» премияләренең финалына чыкты, шулай ук «Ясная Поляна» премиясендә укучылар призына лаек булды. Һәм бу – уникаль очрак, беренчедән, автор – яшь һәм яңа, әле исеме дә, үзе дә беркемгә билгеле түгел. Икенчедән, бу автор – Дагыстаннан, әмма рус телендә яза, һәм көтмәгәндә-уйламаганда аңа мөнәсәбәт үтә дә хуплаулы булып чыга. Өченчедән, «Типа я» повесте асылда... балалар әдәбиятына якынрак тора, ләкин шуңа да карамастан бу аңа барлык шорт-исемлекләргә керергә комачауламый.

Әйе, уңыш картинасын гына күргән очракта, бу гаҗәеп күренеш булып тоелачак. Әмма бу уңышка кадәр Ислам әдәбиятка шактый четерекле юл уза. Аның повестен берничә нәшрият кире кага, кыйммәтен танымый, ә менә «Лицей» премиясенә җибәргән кулъязма кызыксыну уяткач, бар да үзгәрә. «Россиядә гаптади бер Дагыстан малае турындагы тарих кемгә кызык була алсын инде, дип уйладым мин. Ул Дагыстанда да беркемгә кирәк түгел. Шулай да, тәвәккәлләргә булдым...», – ди Ханипаев.

Ни гаҗәп, нәкъ менә бәләкәй генә Дагыстан малае турындагы әсәр жюри әгъзаларының, ә аннан соң меңләгән китап сөючеләрнең дә йөрәген яулап ала. Басылып чыкканнан соң да китапның язмышы үзенчәлекле: ул күпсанлы бәхәсләр дә уятты, аңа сокланучылар саны да көннән-көн арта гына бара. Ислам Ханипаевны ватанында инде, «Дагыстанда ятимнәр темасы юк, син шуны күтәреп, безне мәсхәрә итәсең» дип, гаепләргә дә өлгерделәр. Ә язучы үзе шул арада башлап ташлаган ике романын тәмамлап, бастырып чыгарырга өлгерә. Бу яшь кенә егетнең үзенә карата да, әдәби язмышына карата да җиңел, үзиронияле мөнәсәбәте сокландыра. Саклап кала алырмы ул аны алга таба да... – вакыт күрсәтер.

«Бүлмәгә типа әни килеп кергәндә, мин өй эшен эшләп бетереп утыра идем.

– Нәрсә эшлисең, куянкай? – дип сорады ул, яныма утырып.

Мин «Яугир көндәлеген» ябып куярга чак өлгердем.

– Миңа алай дип әйтмә, – дидем, кырт кисеп.

– Гафу ит, мин әле синең үскәнеңә ияләшә алмыйм.

«Әйтерсең, син минем үскәнемне күрдең! Без синең белән ике ел гына таныш, син мине тапкан кебек кыланма!» – дип уйладым

мин әчтән генә, әмма... бу сүзләрне кычкырып әйтмәдем.

– Карале, куянкай, ой, гафу, Артур, миңа моны соравы читен... шулай да...

– Әйе, мин сугыштым. Мин бер кызны якладым һәм җиңдем, – дидем мин көн дә шулай иткән шикелле итеп тыныч кына.

Текә Али миңа тәрәзә ягыннан «класс» дигәндәй бармагын тырпайтты.

– Кара син аны, кызларны яклап сугышкансың, – дип елмайды типа әни. Бу шулкадәр зур эш һәм инде түйгә галстук сайларга вакыт, диярсең.

– Әмма мин өйләнмәскә дип ант иттем, – дип кырт кистем мин тагын.

– Әйе, әйе, хәтеремдә, – диде типа әни. – Минем моны һич онытасым юк – 8 яшендә һәркем дә болай ант итә алмый, син генә булдырасың, минем бәләкәй исемсез яугирем! Әмма халык әйтеменә ышансак, һәр бөек эш алдыннан мәктәпне тәмамларга, БДИны уңышлы тапшырырга кирәк. Ярый, мин йокларга ятам, яме!

– Текә Али! – дип дәштем мин.

– Чё? – диде ул җавапка.

– Чыннан да шундый әйтем бармы?

– Юк, билгеле, алдый ул.

Өлкәннәр гел алдый – мин инде моны белә идем. Алар алдаганда безне белми дип уйлыйлар. Ә менә мин үзем үскәч, балаларыма беркайчан да алдашмаячакмын. Кыш бабай турында да, Гарри Поттер турында да, ләкләк белән кәбестәне әйтмим дә инде. Мин аларга баштан ук нәрсәнең каян килгәнен әйтәчәкмен...»

Шулай итеп, 8 яшьлек Артур белән бергә без бүгенге Махачкала тормышына, үсмерлек чорына кереп барган баланың куркулары, хыяллары, өметләре, сагышлары дөньясына кереп чумабыз. Аның үзе уйлап чыгарган күзгә күренмәс дусты – Текә Али белән танышабыз. Ул Артурга бу катлаулы дөньяда барган хәлләргә бәя бирергә, яшәргә булыша.

Һәм әсәрнең уңышы һәм күпләр өчен кызыклы булуы менә шушында аңлашыла да. Бу беренче карашка гына Дагыстанда яшәүче бәләкәй малай турындагы повесть. Асылда ул – безнең барыбыз турында да. «Типа я» гаҗәеп рәвештә без кичкенәдән укып үскән балалар тарихларын хәтерләтә, ул безне өлкәннәр дөньясында ничек яшәргә һәм үз-үзеңә хыянәт итмәскә өйрәтә. 8 яшьлек малайның өлкәннәргә караганда күпкә акыллырак, ихласрак һәм умырткалырак булуын аңлыйбыз. Азакта без әле аның чыннан да яугир һәм рыцарь булуына ук инанабыз. Әсәрнең башыннан ахырына кадәр Крапивин каһарманнары, бигрәк тә «Журавлёнок и молнии» китабындагы Журка күз алдымда торды.

Китапның иллюстрацияләре – искиткеч! «Менә бездә дә яшүсмерләр өчен шундый китаплар булса иде!» – дип укыдым. Һәм әле тагын Исламның интервьюларындагы җаваплары да күңелгә бик якын булып тоелды: «Үзем дә сизмәстән, хәзерге Дагыстанда хәлләр ничек икәнен күрсәтергә омтылганмындыр, бәлки. Россия күләмендә бу тарихның шундый күпләргә якын булуына сөендем. Чөнки асылда бу – универсаль тарих, ә Артур – архетип. Ул Махачкалада гына түгел, Ульяндa да, башка бик күп шәһәрләрдә дә яшәргә мөмкин иде... Бу китап мине тамырларыма кайтарды. Миңа, үсеп килә торган улымның этисе буларак, бүгенге җәмгыятьтә ата роленә никадәр ихтыяҗ булганын аңларга кирәк иде. Кавказ гаиләсе өчен, Дагыстан кешесе өчен ата ул – бөтен нәрсәнең нигезе...»

...Бу сүзләрдән соң инде өстәп берни дә әйтәсе килми.

ИСЛАМ ХАНИПАЕВ – режиссер, сценарист, язучы. ДДТУны тәмамлый, белгечлеге – «Нефть-газ эшчәнлеге». Университетта укыганда кинематограф белән мавыга, киностудия булдыра һәм кыскаметражлы фильмнар төшерергә керешә. Кинофестивальләрдә катнаша, 15 тән артык бүләге бар. Сценарийлар яза.
2016 елда Чечняга китә һәм дәүләт киностудиясендә режиссер булып эшли. 2017 елда Дагыстанга әйләнеп кайта һәм «Система 05» дигән беренче тулыметражлы нәфис фильм төшерә.
2014 елдан проза яза башлый. 2021 елда «Лицей» әдәби премиясенә ия булган «Типа я» – аның алтынчы зур күләмле әсәре. 2022 елда тагын ике әсәре дөнья күрде – «Холодные глаза» триллеры һәм «Большая суета» романы.

PRESSA

Татарстан авыллары

БАЛТАЧ, ЮЛСУБИНО – БЕР АВЫЛНЫҢ ИКЕ ИСЕМЕ



БАЛТАЧ

Яңа елда да татар авыллары буенча сәяхәтләребезне дәвам итәбез. Бу юлы без Балтачны сайладык. Юк, Балтач районын түгел, ә Балык Бистәсе районында шундый исемле авыл бар. Дөрес, аны Юлсубино дип тә атыйлар. Ник алай бер авылга ике исем бирелгән? Бирелә халык ничек яши?

Руфия Фазылова

Фото: Александр Ефремов

РАВИЛ АБЫЙ – БЕЗНЕКЕ!

Без барган көнне Балтачта зур бәйрәм иде – Халык шагыйре Равил Фәйзуллин хөрмәтенә музей-салон ачылды. Бер төркем татар язучылары, югары даирәдәге җитәкчеләр, татар зыялылары – авылга берьюлы моның кадәр атаклы кешеләрнең килгәне юк иде, диде җирле халык.

Музей-салон Балтач төп белем бирү мәктәбендә урнашкан. Белем йорты Равил Фәйзуллин исемен йөртә. Балтач мәктәбендә бүген 25 укучы белем ала, бу бер Балтач авылы балалары гына. Дөресен әйтим, беренче, икенче, өченче сыйныфларда берәр генә бала булуы күңелгә шом салды. Ләкин мәктәп директоры Нияз Гарипов оптимистик караштa – белем йорты тагын күп еллар авылның күрке булыр, дип уйлый.

Мәктәптә Равил Фәйзуллинның музей-салоны булу, әлбәттә, әлеге теләкне куәтли. Шуның өчен дә Нияз Гарипов мәктәп укытучылары белән шагыйрьгә мөрәҗәгать иткән.

– Бер очрашуда сезнең иҗатка багышланган музей булдырасыбыз килә дигәч, хөрмәтле авылдашыбыз безнең ниятне хуплады, – диде Балтач мәктәбе директоры. – Ул сөйләшүдән соң ике еллап вакыт узды. Нәтиҗәдә, элеккеге технология кабинетын үзгәртеп, менә шундый заманча музей-салон оештырдык. Равил абыйны республикада нык хөрмәт итәләр, моңа янә бер кат инандык. Музей-салон тулысынча республика бюджеты акчасына, төгәлрәге, ТР Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов ярдәме белән эшләнде.

Музейда Равил Фәйзуллинның шәхси әйберләре, китаплары, фотосурәтләре, төрле документлар тәкъдим ителгән. Түрдә – язучының эш өстә-

Без барган көнне Балтачта зур бәйрәм иде – Халык шагыйре Равил Фәйзуллин хөрмәтенә музей-салон ачылды.

ле һәм урындыгы, өстәлдә – басма машинасы. Киштәләрдә – шәхси китаплары.

Тагын тәрәзәдәге язулы жалюзилар игътибарны җәлеп итте. Анда шагыйрьнең унбиш яшендә язылган «Вакыт» шигыре басылган. Үсмер малайның әлеге шигырен укыганнан соң, барысы да аңлашылды – ул чакта ук Равил Фәйзуллинның чын шагыйрь булачагы күренгән!

Халык шагыйренең ул көнне дулкынлануы, чиксез сөенүе дә күренде. Казаннан, районнан килгән зур кунаклар, авылдашлары каршында ул болай дип сөйләде:

– Мин бүген бик бәхетле. Өченче класста укыганда язылган беренче кульязма китабым монда тора. Мин анда үз биографиямне яздым. «Мин шагыйрь булырга телим», – дип язганмын. Шул вакытта ук хыялый булганмын. «Үзең язган китабыңны тотып, кайтсаң иде туган ягыңа», – дип тә куйганмын. Аллага шөкер, язмышыма рәхмәт – сабый вакытымдагы хыялым тормышка ашты. Киләчәк тормышыңны никадәр иртәрәк ачыклыйсың, үзеңне рухи яктан шулкадәр бәхетлерәк хис итәсең һәм җәмгыятькә дә файдалырак буласың икән. Музейга килгәндә исә, без аны «музей-салон» дип атадык. Бу кечкенә генә булса да зал. Ул үле булмасын иде. Җанлы булсын иде! Бирегә фикердәшләр җыелып, рухи байлыгыбыз, киләчәгебез, әдәбиятыбыз турында сөйләшүләр үтсен иде. Шулай булыр, дип ышанам. Бәлки, туристларны да кертеп чыгарырга мөмкин булыр. Башка районнарда да музейлар бар: Аксубай районында – Хәсән Туфан музее, Арчада Мөхәммәт Мәһдиев музее эшли. Мәктәптә туган телнең авыр хәлдә икәнлеген беләбез. Авыр вакытларда кечкенә генә мәктәп музее да безне саклауның бер урыны, мәгърифәт учагы булсын иде. Мин шуны телим. Үз җирендә танылу алу һәм зур шәхесләрнең сиңа бәя бирүе, әлбәттә, уен эш түгел. Без бу дөньяга килгәч, эз калдырырга тиеш. Бәхетемнең шаһитлары булганыгыз өчен сезгә рәхмәт! Бу дөньяда кешенең беренче иң кадерле әйбере – саулыгы, икенчесе – вакыты.

КҮП БАЛАЛЫ УҢГАН ГАИЛӘ

Балтач кечкенә авыл түгел: биредә 399 кеше яши, 165 хуҗалык бар. Дөрес, әле бер 20–30 ел элек кенә бирედә 250 хуҗалык булган. Әмма яшьләр калмау, өлкәннәр вафат булу сәбәпле, дистәләгән йортның ишегенә йозак эленгән.

Мәдәният йорты, китапханә, фельдшер-акушерлык пункты, кибет – тормыш өчен барысы да бар. Ә менә балалар бакчасы юк һәм булмаган да! Кемнән генә сорасаң да: «Өйдә тәрбияләндек», – диләр.

Рәйзәлә һәм Илназ Гариповлар да дүрт баласын әнә шулай өйдә үстерә. Дөрес, ике кызлары хәзер Балтач мәктәбендә укый, Зәринә дүртенчедә, Инзилә беренче сыйныфта. Ә биш яшьлек Айназ белән әле яшь тә тулмаган Илгиз әниләре белән өйдә.

– Бакча булмагач, кыен түгелме? – дидем күп балалы әнигә.

– Юк, кыен түгел. Безнең бит дүрт ел саен гаиләдә яшь бала туып тора, эшкә чыгып тормыйм, – дип елмая ул.

Гариповларның эшләре өйдә – күп итеп малтуар асрыйлар. Өч сыер янына узган ел тагын берне алып кайтканнар. «Бала саен бер сыер кирәк инде», – диде ата кеше. Үгезләр, бозаулар, кош-корт, җәен утыз биш сутый бакча – күп балалы гаиләне туендырыр өчен җитә.

– Җәен гел төзелеш эшендә йөрим, – диде Илназ. – Шул акчага әнә йортны яңарттык. Бу – эби-бабайдан калган нигез. Рәйзәлә белән өйләнешкәч тә, йортка янкорма салдык, тышладык, түбәсен алмаштырдык. Ә узган ел яңа каралты эшләдек.

Төзелеш дигәннән, ир белән хатын каралтыларын икәү генә салган! Әйе, әйе, Рәйзәлә дә түбә башына менеп калай япкан. Югыйсә ханымның ул көнгә кадәр чүкеч тотып кадак какканы булмаган.

Рәйзәлә һәм Илназ Гариповлар гаиләсендә дүрт ел саен бала туа.

– Илназ башта ярдәм итеп кенә торырсың дигән иде. Аннары түбәгә үк менәргә туры килде. «Астан калайны бир», – дия-дия, тәки миннән төзүче ясады. Курыкмаска гына кирәк, бөтен эшкә дә өйрәнеп була икән.

Балалар белән танышам: берсеннән-берсе үткеннәр. Олы кызлары Зәринә – әти-әнисенең уң кулы. Сеңел, энеләренә күз-колак та ул. Җәй буе төпчек энесен ул караган. Әти белән әни, һич икеләнмичә, бер айлык баланы калдырып, бакча эшләренә чыгып киткән. Энесен ашату, йоклату тулысынча аның өстендә булган. Зәринәдән бигрәк, биш яшьлек Айназ шаккатырды: узган ел ул бер бакча (!) кабакны пычак белән малларга турап ашаткан. Башта бу хәлгә бик ышанмыйчарак торган идем, ләкин соңрак Балтач мәктәбе укытучылары да раслады. Малайның кабак турап утырганнарын әллә ничә тапкыр күргәннәр.

– Айназ салат ясаганда дә булыша, ул тураган бәрәңге, кишерләр бик матур була, – диде әни кеше. – Әле кайчакта миңа да кисәтү ясый: «Әни, син эре турыйсың», – ди.

– Ә ничек шундый кечкенә балага пычак бирергә курыкмадыгыз? – дим.

– Ул инде өч яшьтән пычак тотарга өйрәнде. Әйтмәгәнем булсын, бик сак эш итә. Гомумән, Айназыбыз эшкә бик батыр. Кырдан печән дә җыя, җәй буе әтисенә ярдәм итте. Хәзер исә маллар карашырга чыга. Сыерларга печәнен, онын бирә, асларын җыя.

Бу гаиләдә тәпи киткәч тә, балалар эшкә өйрәнә. Гариповлар белән аралашкач, әнә шундый фикер туды. Хәер, алма алмагачыннан ерак төшми шул – эти белән әни үзләре дә бер хезмәттән дә курыкмый. Рәйзәлә Питрәч районы кызы. Илназ белән танышканда эти-әнисе белән яшәгән.

– Булачак ирем безнең авылга эшкә килгән иде, шунда аралашып киттек, – диде. – Илназ телгә бик оста, әнә шуңа бер-беребезгә тиз ияләндек. Танышкач та, уйларының җитди булуын, гаилә кору теләген әйтте. Аңа утыз яшь тулып киткән, мин исә әле күпкә яшьрәк идем. Шулай да эти-әнием каршы килмәде. Бүтән район дип тә тормадылар, кияүгә биреп җибәрделәр. Аллага шөкер, матур яшибез.

Балалы гаиләдә фәрештәләр яши, ди халык. Һичшиксез, Гариповлар йортында рәхәт бер җылылык бар. Сөйкемле, акыллы (Зәринә мәктәптә биш билгеләренә генә укый) балалар эти-әниләренә охшап телгә дә үткен. Безнең алда кыенсынып утырмадылар. Шуның өчен дә балаларга сокланып кайттык.

УМАРТАЧЫДАН – ТЕРЛЕКЧЕГӘ...

Балтачта халык күпләп мал асрый. Авылда ике йөздән артык сыер гына бар. Кәтү дә ел саен чыга. Үзе өчен – ике, өч баш сыер асраучылар байтак. Ә менә Рөстәм Мостафин 2019 елда крестьян-фермер хуҗалыгы ачып җибәргән. Бүген аның карамагында 60 баш Герефорд токымлы сыер исәпләнә. Моннан тыш, тагын ун баш савым сыеры бар. Һәм тагын 100 баш умарта тота!

– Гомер буе диярлек мал асрадык, – диде Рөстәм абый. – Ә менә умартачылык белән очраклы гына шөгыльләнә башладым. Колхоз умарталарын караучы апа олыгайгач, мине чакырдылар. Шул ападан эш тәртибен өйрәндем. Аннан махсус курсларда укып кайттым. Шулай итеп бал кортлары белән аралашырга өйрәндем. Ләкин аннан колхоз таралды, умарталыкны бетерәсем килмичә, барыбер эшне дәвам иттем. Өч елдан соң аны үз исемемә рәсмиләштердем. Нәтиҗәдә, умартачы булуыма өч дистә елдан артык вакыт узган инде.

– Яңадан фермерлык эшенә ничек кереп киттегез?

– Грант алырга шактый озак кызыгып йөрдем, ләкин җай чыкмады. 2019 елда исә документларны җыеп тапшырып, терлек үрчетү өчен 3 миллион сум грант оттым. Ул акчага терлек, тегермән, чапкыч, тыгызлау (пресслау) җайланмасы сатып алдым. Ә ферма биналарын үз акчама кордым.

Рөстәм абый карамагында 200 гектар җир исәпләнә. Нигездә бу – авылдашларының пай җирләре. Хуҗа җир эшкәртү өчен бөтен техникасын булдырган: өч МТЗ, бер ДТ-75 тракторы, бер комбайн сатып алган. (Аларны инде берничә ел дәвамында булдырган.) Сезон вакытында эшкә бер кеше ала. Ә ел дәвамында эшләүче бер ир-ат бар. Ул малларны да карый, каравылчы ролен дә үти. Рөстәм абый эшче өчен ферма янында гына зур булмаган өй салган. Каравылчы шунда эшләп, шунда яши икән.

– Герефорд токымлы сыерларны савасы юк, – диде хуҗа кеше. – Бозаулары сигез айга кадәр имә. Аннары сыер янә буазлана. Гади сыерлардан аермалы буларак, алар мөгезсез, сабыр, салкынга чыдам. Шуның өчен дә кыш буе урамда яшиләр. Йокларга гына эчкә керәләр. Ә менә өйдәге гади сыерларны хәләл җефетем сава. Көндәлек чыгымнарны каплар өчен, сөт акчасын тотабыз.

Фермер Герефорд токымлы сыерларның бозауларын яшь ярымлык итеп үстерә, аннан иткә озата. Ихтыяҗ һәрвакыт бар икән.

Хуҗа кеше бу сыерлар турында кызык кына факт әйтте: баксаң, алар башка бозауларны да имезә икән.

Рөстәм Мостафин 2019 елда крестьян-фермер хуҗалыгы ачып җибәргән.

– Рөстәм абый, умартачы җәй буе бал кортлары янында була, – дим. – Ә сезнең нәкъ шул вакытта печән өсте, кыр эшләре. Ничек өлгерәсез?

– Аның сере бар: балны мин күп аермыйм. Йөз оядан бер тонна бал алам да – җитте, калганы – бал кортларына. Шуңа күрә кортлар кышка ач керми. Язын өстәмә ашатасы да булмый. Кар эрегәч, ояларны тышка чыгарып куям да – бетте, тыныч кына кырга, чәчүчәчәргә китәм. Балның артыгын барыбер алучы булмый, шуның өчен кортлар ашасын дим. Заманында биш тонна бал алганым да булды. Аны урнаштыру – газап. Ә болай бер тонна тиз арада китеп бетә. Миңа да тыныч, кортлар да бәхетле.

Фермерның кортлары гына түгел, маллары да бәхетле – иген, печәнен дә сатмый ул. Рөстәм абый әйтмешли, ел әйләнәсе алларында ризык тора. «Зур үгезләргә көн саен бер чиләк он бирәм, нәтиҗәдә тиз өлгерәләр», – диде фермер.

Рөстәм абыйның гаиләсе ишле: тормыш иптәше белән ике кыз, бер малай үстергән. Кызлар инде үз тормышлары белән яшиләр. Ә төпчек уллары үз яннарында әле – Балтач мәктәбендә укый.

– Малай фермерлык эше белән бик кызыксынмый, – диде эти кеше. – Мин мәҗбүриләмим дә. Теләге булса эшләр, юк икән, читкә китә инде. Авылда көчләп калдырырга җыенмыйм. Әле безгә илле биш яшь тә юк, хәлдән килгәнчә тартырбыз.

100 еллык мәчет

Балтач – бик борынгы авыл. 1875 елда авылда мәчет булуы мәгълүм. Ә 1916 елда биредә яңа таш мәчет салына. Иң мөһиме – ул бүген дә сакланып калган. Һәм көн саен аннан азан тавышы яңгырый.

– Әлеге иман йортыбызны Арча авылының Урта Аты авылы кешесе – Әхмәтҗан бай эшләткән, – диде Балтач мәчетенең бүгенге имамы Фирдинанд Хәкимов. – Ләкин ул аннан соң дистәләгән еллар үз ролен үтәмәгән. 1927 елда аны мәктәп итәләр. Ә 1936 елда мәчетнең манарасын кисәләр. Авыл картлары ул дәһшәтле көннәрне елап искә ала иде.

Балтач динле авыл. Шулай булмаса, әле дин ирегә кайта башлауга ук, таш мәчеткә манара ясап, ай куйдырмаслар иде. 1990 елның 13 апреле авыл тарихына зур хәрефләр белән язылган – айлы мәчет манарасыннан яңадан азан тавышы яңгырый. Җомга көн була ул. Халыкның күзендә – яшь... Ничә еллар кадерсезләнеп торган мәчет янәдән эшли башлый! Могҗиза...

Искиткеч, борынгы мәчет бик яхшы сакланган, кызыл кирпечләре яңа салынган кебек. 2018 елда иман йортын авыл халкы белән бергәләп төзекләндергәннәр. Капка, коймалар да яңартылган. Ике яклы мәчетнең түрендә намаз укысалар, икенче бүлмәсендә дин сабаклары өйрәнәләр. Укырга балалар, өлкәннәр дә йөри икән.

Балтачта эчкерсез, гади һәм бик тырыш халык яши. Әлеге сәфәрдән шуңа инанып кайттык. Бер генә теләк – авыл яшәсен. Яңа ачылган музейда балалар әдәбиятны яратырга өйрәнсен, ә мәктәбенең ишегенә беркайчан йозак элелмәсен. Т

1916 елда салынган мәчеттә бүген дә азан тавышы яңгырый.

Балтач авылы мәчетенең бүгенге имамы Фирдинанд Хәкимов.

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

Нурулла Гариф, тарихчы:

– Авылның элеккеге атамасы – Юлсубино. Археологик карталарда 1183 елда бу җирләрдә саба кабиләләре яшәве билгеләнгән. Авылның атамасы әнә шушы кабилә исеменә бәйле булырга тиеш. Авылның эчендә бик борынгы болгар кабиләләренә караган авыл урнашкан булган. Анда чишмә, авыл урыны бар. Димәк, бу урында XII гасырда ук кеше яшәгән дия алабыз.

Ә Балтач атамасы каян килеп чыккан соң? 1641 елда авылның старостасы Балтач исемле булган. Һәм шул рәвешле авылга исем тагылган. (Бу якларда күп авылларга староста исемнәре кушылган.)

«ИРА» ҺӘМ БАШКАЛАР (16+)

– Казан рок-сәхнәсенең барлык буыннарын да берләштереп, Казанда җанлы музыка бәйрәмен үткәрергә телибез, – ди Казандагы иң популяр бер музыка мәйданчыгы хуҗасы Григорий Корнилов. Шул рәвешле Big Twin Fest һәм Волга-Волга Fest уртак фестивален үткәрү идеясе туа. Махсус кунаклар исемлегендә карьераларын каеннан үзләре ясаган гитарадан һәм кулдан эшләнгән барабаннан башлаган кешеләр бар. Рокерлар дәртле яшьләр ярдәмендә бөтен Казанны шау-гөр китерергә вәгъдә итә.

9 февральдән 11 енә кадәр

BIG TWIN ARENA. Казан, Ямашев пр., 115А

ТОРФ ҺӘМ ЛӘМ ТАРИХЫ (6+)

Урта гасыр урамыннан бер кыз атлый, ялгыш торф пычрагына агач тарагы төшеп китә. Тарак җир катламына бата. Моннан соң бер, ике, ун ел, гасырлар уза. Тарак тирәнгәрәк бата бара. Аның тирәсендә булган башка металл предметлар – тәңкә, прәшкә, кадак, дага һ.б.лар шулай ук җир катламында югала. Ә тарак исән кала, археологларның тырышлыгы белән казып чыгарыла һәм үзе турында күп нәрсә сөйли ала. Татарстан Милли китапханәсендә «Зөя утрау-шәһәре» музейтыюлыгы оештырган күргәзмәдә менә шундый тарихлар белән танышырга була.

30 гыйнварга кадәр

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе. Казан, Пушкин ур., 86

ЙӨЗЕҢНЕ АЧ, ГӨЛЧӘҺРӘ (16+)

– Аршин мал алан! Аршинлап алыгыз! – дип өметләнеп кычкыра тукыма сатучы егет гүзәл Гөлчәһрә тәрәзәсе каршында. Чынлыкта ул монда тукыма сатарга дип түгел, кәләшенә бер генә тапкыр күз салу өчен килә, ә бу шәригатьтә тыелган гамәл. Әскәр Гөлчәһрәне күргәннән соң нәрсә булыр?

8 февраль, 19:00

Пушкин исем. Мәдәни үзәк. Казан, Карл Маркс ур., 26

афиша

Фото: tatar-inform.ru, culture.ru, peterhofmuseum.ru, izo-museum.ru, Константин Куликов, vk.com/bigtwin_volgafest2023

КАГЫЛЫРГА РӨХСӘТ! (6+)

Кыздырылган кош ите исе, XVIII гасыр тәмтомнары – яшел үлән, устрица, шикәр комы катырылган җиләк-җимеш, пешерелгән груша, аш-су рецептлары һәм табын бизәү әйберләре муляжлары – әлеге һәм башка «ингредиентлар» Петр I заманындагы күңел ачу тамашалары атмосферасын тудыра. Казанга турыдан-туры Петергофтан килгән «Күңел ачу өчен генә түгел, эш өчен дә» дип аталган күргәзмәдә император галиҗәнаплары мәҗлесе нечкәлекләре белән танышырга, анда катнашучыларны күрергә һәм хәтта экспонатларга кагылырга рөхсәт ителә.

30 гыйнварга кадәр

Татарстан Республикасы Милли музее.

Казан, Кремль ур., 2

КАЙСЫ БОЛАН СИНЕКЕ? (12+)

Бер-берсенә охшамаган ике хатын-кызны бер нәрсә – кайгы берләштерә. Аяз Гыйләҗев пьесасы аларның киләчәктә нәрсәне сайлавы турында сөйли. Төп геройларда калган курку, өмет, мәхәббәт һәм мөмкинлекләрнең гәүдәләнешен чагылдыручы сыйфатында сәхнәдә зур болан йөри. Ул игелекле затка әверелерме яисә гамьсез генә башкалар бәхетен үзенеке хакына корбан итәрме?

16 февраль, 19:00

А. Гыйләҗев исем. Яр Чаллы театрының гастроль спектакле.

Г.Камал исем. Татар дәүләт Академия театры. Казан, Татарстан ур., 1

«КИНО» КИНОДА ҺӘМ МАХСУС ЭФФЕКТЛАРДА (12+)

1980 нче елларның иң популяр төркеме тәэсирен үзендә тоясы килгән һәр кеше узганнарга сәяхәт кыла, мультимедиа шоуда булып, Цой тавышын ишетә ала. Музыка өчен коллективның оригиналь составы вәкилләре – Александр Титов, Игорь Тихомиров һәм Юрий Каспарян музыка өчен җавап бирә. Ике сәгатьлек концерт графикадан, анимациядән, яңа һәм архив фотосурәтләреннән торган тулыметражлы диярлек фильм белән бергә бара. Музыкаль композицияләрнең зур өлеше оригиналга мөмкин кадәр якын ясалды, әмма импровизация һәм яңача укылышлардан башка да булмый, дип ышандыра оештыручылар.

10 февраль, 19:00

«Татнефть Арена». Казан, Чистай ур., 42

ТАНЫШ СУРӘТЛӘР (16+)

Тондо – түгәрәк эчендәге рәсем. Мондый картиналар форматы антик рәссамнарда популяр була. Мең еллар дәвамында бернәрсә дә үзгәрмәде – без тондоны кулланабыз. Кайда дип уйлыйсыз? Петербург рәссамнары Екатерина Бородавченко һәм Алан Хагагты Казанга 70 әсәрдән торган «Көлке, күз яшьләре һәм хыяллар» күргәзмәсен алып килә, аларның һәркайсы – түгәрәккә язылган портрет. Сезгә алар арасында үзегезгә якын хисләрне табуы авыр булмастыр...

26 февральгә кадәр

ТР ДССМның Заманча сәнгать галереясы.

Казан, Карл Маркс ур., 57

ХУШ КИЛӘСЕҢ, ЯҢА ЕЛ!

Яңа елга аяк бастык. Куян елына. Гыйнвар ае Яңа ел бәйрәме рухында узды. Башкалабыз урамнарында да бәйрәм кәефе хөкем сөрде. Яңа ел чыршылары, төсле утлар яктырткан кыш бизәкләре урамнарга, парк-скверларга ямь биреп торды. Ял көннәрендә башкалабыз халкы, килгән кунаклар чыршы янында оештырылган бәйрәм чараларында катнашты. Шугалакларда олысы-кечесе тимераякта шуды. Аллы-гөлле утлар янган шәһәр урамнары гөрләп торды.

Фотохәбәрчебез төшергән сурәтләрдә дә бәйрәм рухы чагылыш тапты.

Фотолар: Анна Арахамия



shop.tatmedia.ru

Яндекс.Маркет

Ozon

Wildberries

«Татарстан» журналын биредә сатып алырга була

«Татарстан»лы Яңа ел белән!

«ТАТМЕДИА» АҖ. АДРЕСЫ: 420066 КАЗАН Ш., ДЕКАБРИСТЛАР УР., 2 ГРН 1071690057834 РЕКЛАМА 16+